# Туган телдә сөйләшәбез

5 – 7 яшьлек балаларны
туган телдә сөйләшергә өйрәтү
буенча методик ярдәмлек

Казан
«Фолиант»
2012

УДК 373.3/4:811.512.145*00
ББК 74.102:81.2 Тат
Т81

Комплектның авторлары:

Зифа Мирхәт кызы Зарипова, Лилия Наил кызы Вәҗиева,
Рәмзия Сәрвәр кызы Зөфәрова, Нина Антоновна Меньшова,
Зөлфия Җәүдәт кызы Минһаҗева, Ләйлә Гыйльмулла кызы Хәйретдинова,
Асия Тәлгат кызы Хуҗина

Рецензентлары:

С.М.Гаффарова
Казан педагогика көллияте директоры урынбасары, Россия Федерациясенең
Мактаулы урта һөнәри белем бирү хезмәткәре

М.Н.Курамшина
Яр Чаллы шәһәре 5 нче балалар бакчасының югары квалификацион
категорияле татар теле тәрбиячесе

Т81 Туган телдә сөйләшәбез: 5 – 7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек / Төз.: З.М.Зарипова, Л.Н.Вәҗиева, Р.С.Зөфәрова һ.б.- Казан: ФОЛИАНТ, 2012.- 304 б.

Бу укыту-методик комплектында мәктәпкә әзерлек һәм зурлар төркемнәре өчен федераль дәүләт таләпләре нигезендә төзелгән эшчәнлек конспектлары бирелә. Ул татар теле тәрбиячеләре, татар теле укытучылары, югары уку йортлары студентлары һәм педагоглары, методистлар, ата-аналар һәм татар теле белән кызыксынучыларга тәкъдим ителә.

ISBN 978-5-905576-19-5

© Фолиант, оригинал-макет, 2012
© ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, 2012

# Аңлатма язуы

**«Туган телдә сөйләшәбез» укыту-методик комплекты** Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына карата федераль дәүләт таләпләрен раслау һәм аларны гамәлгә кертү турында» 2009 ел, 23 ноябрь, 655 нче боерыгы белән расланган Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына карата федераль дәүләт таләпләре нигезендә балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелде. Ул түбәндәге бурычларны билгели:

- балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
- бәйләнешле сөйләм үстерү;
- тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау (тоемлау) сәләте булдыру.

Федераль дәүләт таләпләрендә билгеләнгән 4 төп тәрбия юнәлеше үсешенә («Физик үсеш», «Социаль-шәхси үсеш», «Танып белү – сөйләм үсеше», «Нәфис-нәфасәти үсеш») нигезләнеп, комплекслы-тематик план төзелде. Ул зурлар төркемендә 36 проектны, мәктәпкә әзерлек төркемендә 31 проектны һәм шул проектлар буенча төзелгән зурлар төркемендә 98, мәктәпкә әзерлек төркемендә 100 эшчәнлек конспектларын үз эченә ала.

«Минем бакчам», «Мин яратам сине, Татарстан», «Саулык – зур байлык», «Исеменә күрә – җисеме», «Кунак булсаң – тыйнак бул», «Исәнме, мәктәп», «Кояш системасы», «Дуслык белән көчле без», «Китап кайдан килә» һ.б. күп проектлар балалар һәм өлкәннәр тормышын чагылдыра, ана телен камил белергә, аның нечкәлекләренә төшенергә ярдәм итә, башка милләт халыклары белән дустанә мөнәсәбәттә яшәргә өйрәтә, балаларда әхлакый сыйфатлар формалаштыра.

Бу укыту-методик комплектында федераль дәүләт таләпләрендә күрсәтелгән өч белем бирү өлкәсе карала:

- **«Танып белү» белем бирү** өлкәсе табигать, аның үзенчәлекләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыру; балаларның ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү, системалаштыру; нәниләр белән экология бурычларын гамәлгә ашыруны, туган як, өлкәннәр хезмәте турында белемнәрен тирәнәйтүне максат итеп куя. Шушы максатларны тормышка ашыруга ярдәм итә торган зурлар төркемендә 31 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә 33 эшчәнлек каралган. Балалар белән эшчәнлек сәяхәт, күзәтү, тәҗрибәләр уздыру, төрле уеннар формасында уздырыла;

- **«Аралашу» белем бирү** өлкәсе нәниләрдә туган телгә мәхәббәт тәрбияләү, матур әдәбият әсәрләре белән кызыксыну, авазларны дөрес әйтү, бәйләнешле сөйләм культурасы булдыруга, сабыйларга кара-каршы сөйләшә белү (диалогик сөйләм) күнекмәләрен камилләштерү, сәнгатьле сөйләм чараларын үзләштерүгә булышлык итү бурычларын гамәлгә ашыра. Бу белем бирү өлкәсенә туры килгән зурлар төркемендә 35 эшчәнлек, мәктәпкә әзерлек төркемендә 36 эшчәнлек тәкъдим ителә. Авазларны кабатлау, калын һәм нечкә авазларның дифференциациясе һәр эшчәнлеккә өлеш итеп кертелде. Бу өлкәдәге эшчәнлек әңгәмә, үстерелешле диалог (балалар сорау бирә, сорауларга җавап кайтара), сәхнәләштерү, өстәл театры карау, рәсемнәр карау, алар буенча хикәя төзү, уен-викториналар үткәрү, тасвирлау, үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү, хикәяне дәвам итеп сөйләү кебек эш формаларын күздә тота;

- **«Матур әдәбият» белем бирү** өлкәсе кешеләрне һәрчак яхшыга гына өнди, акыллы, тапкыр булырга киңәш бирә, авыр вакытта югалып калмаска, нык ихтыярлы, батыр йөрәкле булырга өйрәтә торган, балаларның яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр белән таныштыруны, балаларны әдәби телдә сөйләшергә өйрәтүне максат итеп куя. Бу белем бирү өлкәсе зурлар төркемендә 32 эшчәнлекне, мәктәпкә әзерлек төркемендә 31 эшчәнлекне үз эченә ала. Эшчәнлек матур әдәбият әсәрләрен уку, эчтәлеген сөйләү, ятлау кебек эш формалары кулланып оештырыла.

Укыту-методик комплекты федераль дәүләт таләпләрендә күрсәтелгән 10 белем бирү өлкәсе («Сәламәтлек», «Физик

культура», «Социальләштерү», «Хезмәт», «Куркынычсызлык», «Танып-белү», «Аралашу», «Матур әдәбият уку», «Иҗат», «Музыка») буенча куелган бурычларны да күздә тотып эшләнде һәм алар турыдан-туры бердәм белем бирү эшчәнлеге структурасында интегральләштереп бирелде.

Укыту-методик комплектында тупланган материаллар балалар бакчасы педагогларына балаларның сөйләмен үстерү, тирә-юнь, матур әдәбият әсәрләре белән таныштыру максатында гына түгел, ә рәсем ясау, әвәләү, кул хезмәте, конструкцияләү, эксперимент эшләре, кисеп ябыштыру, музыка, физкультура эшчәнлекләрендә, иртән балаларны кабул итү, саф һавада булу, табигатьне күзәтү вакытында, әти-әниләр белән бердәм эшчәнлектә иҗади якын килеп кулланылыр һәм ныгытылыр дип өметләнәбез.

«Туган телдә сөйләшәбез» методик кулланмасы балаларга телебезнең матурлыгын, байлыгын аңларга, аны сиземләргә, үзләрендә күркәм сыйфатлар булдырырга, тел хәзинәсен тирәнтен аңларга, кеше өчен газиз булган туган җиргә, туган телебезгә мәхәббәт, әти-әниләргә, өлкәннәргә карата хөрмәт-итәгать тәрбияләргә, үзләрендә хезмәт сөю, тыйнаклык, шәфкатьлелек кебек күркәм сыйфатлар булдырырга ярдәм итәр дип ышанасы килә.

Шушы җирдән, шушы туфрактан без.
Китә калсак үзгә бер якка,
Өянкеләр җырлап, таллар елап,
Сандугачлар моңы озата.

– дип, шагыйрә К.Булатованың шигырен укыганда, балаларга туган җир, туган туфрак, туган телнең изгелеген, өянкеләрнең кайчан җырлаганын, талларның ничек итеп елаганын, сандугачларның моңы ничек итеп күңелне кузгалтканын аңлата алсак, без үз максатыбызга ирешкән булырбыз.

# Тәрбиячегә ярдәмлек йөзеннән сөйләм үстерү методикасы

**Матур әдәбият әсәрләрен уку методикасы:**

1. Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп уку.
2. Әдәби әсәрне максат куеп уку.
3. Әдәби әсәр эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.
4. Әдәби әсәрне кабатлап уку.

**Матур әдәбият әсәрләренең эчтәлеген сөйләү методикасы:**

1. Әдәби әсәрне сәнгатьле итеп уку.
2. Аңлашылмаган сүзләрне аңлату.
3. Әдәби әсәрне максат куеп уку.
4. Эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.
5. Әдәби әсәрне кабатлап уку.
6. Балалар тарафыннан әсәрнең эчтәлеген сөйләү (5 – 6 бала).

**Шигырь ятлау методикасы:**

1. Шигырьне сәнгатьле итеп уку.
2. Шигырьне максат куеп уку.
3. Шигырь эчтәлеге буенча әңгәмә уздыру.
4. Шигырьне кабатлап уку.
5. Балалар тарафыннан шигырьне яттан сөйләү (5 – 6 бала).

**Тасвирлау хикәяләре төзү планы:**

1. Бу нәрсә (кем)?
2. Нинди өлешләрдән тора?
3. Нәрсәдән ясалган? (нинди материал)
4. Ни өчен кирәк?

**Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләү**
(И.Н.Мурашковска методикасы):

**1 адым** – «бүл» (рәсемдә кем нәрсә күрә, һәрбер бала аерым-аерым әйтә; тәрбияче схематик рәвештә, балалар күргән һәм атаган рәсемнәрне түгәрәккә алып, тактага ясый);
**2 адым** – «әйдә» (балаларга эчтәлеге белән туры килгән ике

рәсемне кушарга тәкъдим ителәһәм ни өчен? дигән сорауга тулы җөмлә белән җавап бирүләре сорала);
**3 адым** – «нинди тавышлар ишетәсең?» (уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү);
**4 адым** – «нинди исләр тоясың?» (уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү);
**5 адым** – «рәсемдәге әйберләрнең сыйфатларын әйтү» (уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү);
**6 адым** – хикәя төзү (биш адымны берләштерү).

# Комплекслы-тематик план

## Зурлар төркеме

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| 1. Минем бакчам | Балалар бакчасы буйлап сәяхәт<br>Рәсем карау һәм хикәя төзү: «Балалар бакчасында»<br>Шигырь ятлау: М.Фәйзуллина. «Өлкән группага күчкәч» | 1<br>1<br><br>1 |
| 2. Мин яратам сине, Татарстан | Әңгәмә. «Туган ил кайдан башлана?»<br>«Башкалабыз – Казан»<br>Шигырь уку: Р.Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан» | 1<br><br>1<br>1 |
| 3. Яхшы сүз – җан азыгы | Өстәл театры. «Өч кыз». Татар халык әкияте<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү: Ә.Бикчәнтәева. «Тәмле сүз» | 1<br><br>1 |
| 4. Абдулла Алиш иҗаты | «А.Алиш – балалар язучысы»<br>Хикәя уку: А.Алиш. «Каз белән аккош» | 1<br>1 |
| 5. Хуш киләсең, ямьле көз! | Бакча тирәли сәяхәт. «Җәйләр үтте, көзләр җитте»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге табигать»<br>Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Көз» | 1<br><br>1<br><br>1 |
| 6. Көз күчтәнәчләре | Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт. «Көзге могҗиза»<br>Сәхнәләштерү: В.Хәйруллина. «Яшелчәләр бәхәсе»<br>Шигырь ятлау: Х.Гарданов. «Түтәлләрдә үсте яшелчә» | 1<br><br>1<br><br>1 |
| 7. Икмәк – яшәү терәге | «Игенче хезмәте белән танышу»<br>Әңгәмә. «Икмәк – тормышның нигезе»<br>Әкият уку: «Икмәк». Төрекмән халык әкияте | 1<br>1<br><br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 8. Минем гаиләм, өем, йорт җиһазлары | Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Безнең гаилә»<br>«Әби-бабайларны хөрмәтлик»<br>Шигырь ятлау: Ә.Бикчәнтәева. «Дәү әнием»<br>«Һәркемнең үз йорты бар»<br>Әңгәмә. «Йорт җиһазлары»<br>Шигырь уку: Ә.Ерикәй. «Әти йорт төзи» | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 9. Табын янында | Савыт-саба кибетенә сәяхәт<br>Чагыштырма хикәя төзү: «Чәйнек белән самавыр»<br>Әңгәмә. «Мин кунак яратам»<br>Хикәя сөйләү: «Тәлинкәнең төбе нинди?» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 10. Киемнәр дә безне бизиләр | Кием-салым кибетенә сәяхәт<br>Әңгәмә. «Милли киемнәр» | 1<br>1 |
| 11. Саулык – зур байлык | «Су, һава һәм кояш – безнең белән гел юлдаш!»<br>Сәхнәләштерү: А.Алиш. «Куян кызы» әкияте<br>Шигырь ятлау: Ә.Ерикәй. «Чисталык сөябез» | 1<br>1<br>1 |
| 12. Исеменә күрә – җисеме | Әңгәмә. «Исемең матур, кемнәр куйган?»<br>«Без дә хокуклы» | 1<br>1 |
| 13. Салкын кыш. Кышкы уеннар | Әңгәмә. «Без суыктан курыкмыйбыз»<br>Тәҗрибә. «Предметның бер хәлдән икенче хәлгә күчүе»<br>Рәсем буенча хикәя төзү: «Кышкы уеннар»<br>Хикәя уку: К.Ушинский. «Кыш әбинең шуклыгы» | 1<br>1<br>1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 14. Бездә кышлаучы кошлар | Балалар бакчасы тирәли экскурсия. «Җимнәр сибәм кошларга»<br>Рәсем карау. «Кошлар килгән җимлеккә»<br>Шигырь ятлау: Д.Гарифуллин. «Песнәк»<br>Шигырь уку: Г.Лотфи. «Балалар ярдәм итә» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 15. Кыргый хайваннар | Төркемдә уен оештыру. «Зоопаркка сәяхәт»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Куяннар»<br>Әкият уку, сәхнәләштерү: «Төлке белән бүре». Татар халык әкияте<br>Әкият уку: «Бүре аларны нигә ашаган». Болгар халык әкияте | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 16. Йорт хайваннары һәм кошлары | Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Ишегалдында»<br>Рәсем карау: «Песи һәм песи балалары»<br>Хикәянең эчтәлеген дәвам итеп сөйләү: Г.Мөхәммәтшин. «Ак песи» | 1<br>1<br>1 |
| 17. Транспорт | «Җир өсте, һава, су транспорты»<br>Чагыштырып тасвирлау хикәясе төзү. «Йөк машинасы һәм җиңел машина»<br>Хикәя уку: И.Дәүләтшин. «Алпамыш шәһәргә килде» | 1<br>1<br>1 |
| 18. Юл йөрү кагыйдәләре | «Машина йөртүче һәм җәяүлене кисәтүче куркынычсызлык билгеләре»<br>Әңгәмә. «Велосипед – минем дустым»<br>Шигырь ятлау: Ш.Галиев. «Светофорның өч күзе» | 1<br>1<br>1 |
| 19. Хезмәт төбе – хәзинә | Төзелеш булган җиргә сәяхәт яки рәсем карау. «Хезмәткә хөрмәт»<br>Әңгәмә. «Кем булырга?»<br>Хикәя уку: К.Ушинский. «Иртәнге нурлар» | 1<br>1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 20. Кунак булсаң – тыйнак бул! | Әңгәмә. «Сүз эчендә энҗе бар»<br>Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Табын кагыйдәләре» | 1<br>1 |
| 21. Россия – зур дәүләт | «Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел ...»<br>Әңгәмә: «Теле барның – иле бар» | 1<br><br>1 |
| 22. Батырлыкта – матурлык | «Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар»<br>Шигырь уку: Ж.Дәрзаман. «Солдат булдым» | 1<br><br>1 |
| 23. Заманча әкиятләр | «Винни-пух кунакка бара» – минем яраткан мультфильмым» | 1 |
| 24. Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа! | Әңгәмә. «Әни кирәк»<br>Шигырь ятлау: Н.Гайсин. «Әни гөлләре» | 1<br>1 |
| 25. Без язны яратабыз | Балалар бакчасы тирәли максатчыл күзәтү<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Яз»<br>Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау<br>Шигырь ятлау: М.Мазунов. «Яз килә»<br>Тәҗрибә үткәрү. «Суган утырту» | 1<br><br>1<br>1<br><br>1<br><br>1 |
| 26. Безнең канатлы дусларыбыз | Терәк сораулар буенча рәсемгә карап, чагыштырма хикәя төзү. «Сыерчык белән карга яз килүгә шатлана».<br>Уен-викторина. «Кошлар – безнең дусларыбыз!»<br>Шигырь уку: Г.Тукай. «Карлыгач» | 1<br><br><br><br>1<br><br>1 |
| 27. Хәрәкәттә – бәрәкәт | «Минем яраткан спорт төре»<br>Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Туплар» | 1<br>1 |
| 28. Су яшәү чыганагы | Әңгәмә: «Яңгыркаем, яу, яу!»<br>Тәҗрибә. «Суның үзенчәлекләре» | 1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 29. Уттан саклан! | Әңгәмә. «Янгын куркынычсызлыгы»<br>Шигырь уку: Г.Гыйльманов. «Ярый әле» | 1<br><br>1 |
| 30. Бүлмә гөлләре | «Хуш исле нәфис гөлләр»<br>Тәҗрибә. «Кояш, су һәм һаваның үсемлекләр өчен әһәмияте» | 1<br>1 |
| 31. Галәм киңлекләре | «Планетарийга сәяхәт» уены | 1 |
| 32. Г.Тукай иҗаты | «Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты»<br>Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Бала белән күбәләк»<br>Шигырь ятлау: З.Туфайлова. «Тукай абый» | 1<br>1<br><br>1 |
| 33 Урман – җиребезнең матурлыгы, байлыгы | Урман почмагына экскурсия<br>«Камканы күзәтү»<br>«Кызыл китап нәрсә ул?»<br>Әкият эчтәлеген сөйләү: Ф.Зариф. «Татлы җәй» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 34. Җиңү алып килде май | Сугыш ветераннары белән очрашу. «Бөек Җиңү»<br>Шигырь уку: Э.Шәрифуллина. «Минем бабай» | 1<br><br>1 |
| 35. Чәчәкләр – тормыш яме | Уен-викторина. «Чәчәкләр – тормыш яме» | 1 |
| 36. Алдакчы, саран булма | Хикәя уку: Н.Фәттах. «Велосипедлы Мөнир» | 1 |
| 37. | Хуш киләсең, ямьле җәй! | |

## Проект. Минем бакчам
### Тема. Балалар бакчасы буйлап сәяхәт

**Бурычлар:**

1. Балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү.

2. Балаларның игътибарлылыкларын, куелган максатны аңлый белү сәләтен үстерү.

3. «Минем бакчам» дигән темага хикәя төзеп сөйләргә өйрәтү.

**Сүзлек:** ашханә, су коену бүлмәсе, кышкы бакча, ике катлы, салганнар.

**Эшчәнлек барышы**

1. Бакча буйлап экскурсия (ашханә, музыка залы, спортзал, кышкы бакча, су коену бүлмәсе һ.б.).

2. Балаларга сораулар:

- Бакчабызның исеме ничек?
- Безнең төркемнең исеме ничек дип атала?
- Бакчада нинди бүлмәләр бар?
- Бүлмәләрнең үзенчәлекле яклары нинди?
- Бакчада кемнәр эшли?
- Иң «тәмле» бүлмә нинди һәм ни өчен?
- Сезгә нинди бүлмә ошады, ни өчен?

3. Хикәя төзү. «Минем бакчам» (әңгәмә сорауларына таянып).

4. Шигырь уку: Б.Рәхмәт. «Безнең бакчабыз».

Ямь-яшел бакчада
Бик матур бакча бар.
Чын бакча түгел тик, –
Ул ике катлы өй,
Салганнар безгә дип.
Эче дә, тышы да
Матур бик, чиста бик.
Шул өйне без инде
Йөртәбез «Бакча» дип.
Бик матур бакча шул –
Балалар бакчасы.

5. Җырлы уен «Күңелле бакчабыз» (балалар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр, сүзләр тәмамлануга, музыка астында төрле хәрәкәтләр ясап бииләр).

Без йөрибез бакчага,
Балалар бик күп анда.
Уйныйбыз да, җырлыйбыз,
Күңелле безгә монда.
Әйе шул, әйе шул,
Күңелле безгә монда.

## Тема. Рәсем карау һәм хикәя төзү.
## «Балалар бакчасында»

**Бурычлар:**

1. Тәрбияче хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү, тәрбияче хезмәтенә ихтирам хисләре тәрбияләү.

2. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.

3. Тәрбияче биргән план ярдәмендә рәсем буенча хикәя төзүләренә ирешү; дусларына һәрвакыт булышырга, ярдәмгә килергә кирәклеген төшендерү.

**Сүзлек:** «тәмле» бүлмә, «күңелле» бүлмә.

**Җиһазлар:** «Балалар бакчасында» дигән рәсем, туп.

### Эшчәнлек барышы

1. «Дөресен әйт» уены (туп ярдәмендә).

- Бакчабызның исеме – …
- Төркемнең исеме – …
- Иң «тәмле» бүлмә – …
- «Күңелле» бүлмә… һ.б.

2. Рәсем карау. «Балалар бакчасында».

- Бу рәсемдә кемнәрне (нәрсәләрне) күрәсез?
- Балалар кайда уйныйлар?
- Малай белән кыз нәрсә эшлиләр?
- Ике кыз нәрсә белән уйный?
- Тәрбияче апа нишли?
- Балаларның кәефе ничек?

3. Тәрбияче планы буенча хикәя төзү.

- Бүлмәне тасвирла.
- Балалар эшчәнлеген сөйлә.
- Зурлар эшчәнлеген сөйлә.
- Рәсемгә исем бир.

4. Балалар хикәясе (4 – 5 бала сөйли; әгәр дә хикәя сыйфатлы булмаса, тәрбияче үрнәк бирә).

5. Бармак уены. «Атна».

Бер-ике, бер-ике,
Өч, дүрт, биш, алты, җиде.
Дүшәмбе һәм сишәмбе,
Чәршәмбе, пәнҗешәмбе,
Аннары килә җомга.

Без йөрибез бакчага.
Шимбә һәм якшәмбедә
Бар да булабыз өйдә.
Әни бәлеш пешерә,
Канәгать барыбыз да.

## Тема. Шигырь ятлау:
## М.Фәйзуллина. «Өлкән группага күчкәч»

**Бурычлар:**

1. Балаларда балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү.
2. Балаларның хәтер сәләтен үстерү.
3. Шигырьгә кызыксыну уяту һәм ятлау теләге тудыру, һәр эшне вакытында эшләү кирәклеге турында аңлату.

**Сүзлек:** өлкән, оят, соңга калу.

**Җиһазлар:** эчтәлекле рәсемнәр сериясе «Иртә».

### Эшчәнлек барышы

1. Дидактик уен. «Дөрес итеп тез» (эчтәлекле рәсемнәр сериясе – «Иртә»; бала йокыдан уяна, урынын җыя, гимнастика ясый, юына, ашый, киенә, әнисе белән балалар бакчасына бара, тәрбияче каршы ала).

2. Шигырь уку: М.Фәйзуллина. «Өлкән группага күчкәч».

Ятканда әйттем әнигә:
- Мине иртәрәк уят!
Өлкән группага күчкәч,
Соңга калуы оят.

3. Балаларга сораулар:
- Ятканда әнигә бала нәрсә дип әйткән?
- Ул нинди төркемгә күчкән?
- Зур балалар нинди була, үзләрен ничек тоталар?
- Ни өчен бакчага соңга калырга ярамый?

4. Шигырьне яттан сөйләү (4 – 5 бала яттан сөйли).

5. Сүзле уен «Без инде хәзер зурлар» (балалар, сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар).

Без инде хәзер зурлар,
Күп эшли безнең куллар.
Без идән дә юабыз,
Без керләр дә уабыз,
Гөлләргә су сибәбез.
Менә шундый уңган без,
Менә шундый булган без.

## Проект. Мин яратам сине, Татарстан

### Тема. Әңгәмә: «Туган ил кайдан башлана?»

**Бурычлар:**

1. Балаларда туган якка карата ярату хисләре тәрбияләү.

2. Тирә-юнь турындагы белемнәрен киңәйтү исәбенә сүз байлыгын арттыру, активлаштыру, диалогик сөйләмне үстерү.

3. Балаларның туган ил турындагы күзаллауларын киңәйтү, «кече илгә» карата кызыксыну формалаштыру.

**Сүзлек:** инешләр, чишмәләр, балачак.

**Җиһазлар:** туган төбәккә кагылышлы булган слайдлар, фотографияләр, рәсемнәр.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Туган ил була бер генә, туган илнең кадерен бел генә.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2.Әңгәмә: «Туган ил кайдан башлана?» (әңгәмә барышында слайдлар күрсәтелә).

- Без нинди авылда (шәһәрдә) яшибез?
- Сезнең урамыгызның исеме ничек?
- Сез торган җирдә нинди истәлекле, үзенчәлекле урыннар бар?
- Безнең авылда (шәһәрдә) нинди танылган шәхесләр бар?
- Авылыбызны (шәһәребезне) матурлар өчен без нәрсә эшли алабыз?

3. Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Туган илем».

Туган илем басу, кырлар,
Урманнар, яшел юллар.
Инешләрем, чишмәләрем,
Туганнар, якын дуслар.

Шушы җирләрдә үтәләр
Балачак елларыбыз,
Шул чакларны олыгайгач
Сагынып искә алырбыз.

4. Дидактик уен «Фотоаппарат» (30 секунд туган якка бәйле рәсем күрсәтелә, аннан соң шундый ук рәсем үзгәрешләр белән бирелә; бала бу үзгәрешләрне сизәргә тиеш).

5. Җырлы-биюле уен «Куш кулым».

## Тема. «Башкалабыз – Казан»

**Бурычлар:**

1. Туган якка мәхәббәт тәрбияләү.
2. Балаларның диалогик сөйләмен, игътибарлылыгын үстерү.
3. Татарстан башкаласы Казан турында белемнәрен тирәнәйтү, Татарстан символикасы һәм аның мәгънәсе белән таныштыру.

**Сүзлек:** әләм, тугра, башкала.

**Җиһазлар:** Татарстан Республикасы картасы һәм символикасы (тугра, әләм), милли курчаклар, слайдлар, фоторәсемнәр, аудиоязмада җыр – «Туган җирем – Татарстан» (Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе).

### Эшчәнлек барышы

1. Татарстан картасын карау (Татарстан Республикасының урманнарга, суларга байлыгы; шәһәр, авылларының күплеге, матурлыгы; файдалы казылмалары турында кыскача мәгълүмат бирү).
2. Слайдлар яки рәсемнәр карау (республикабызның башкаласы Казан шәһәре исеменең мәгънәсе, Казанның истәлекле урыннары, Сөембикә манарасы, Казанда дөньякүләм чаралар, Татарстан Республикасы Президенты).
3. Татарстан Республикасы символикасы белән таныштыру.

Тәрбияче хикәясе: Татарстан әләме астан өскә таба өч өлешкә бүленгән. Өске өлеше яшел, аскы өлеше кызыл, ә уртада ак тар тасма. Һәр төс үзенә бер мәгънәгә ия. Кызыл төс – кешеләр яшәешендә бик әһәмиятле булган кояш төсе. Яшел төс ул – җанлы табигать төсе, яшәү билгесе. Уртадагы ак төс –

сафлык, тынычлык, иминлек билгесе.

Татарстан туграсында кызыл, түгәрәк кояш җирлегендә кодрәтле, канатлы ак барс сурәте төшерелгән. Барсның уң аягы бераз күтәрелгән, ул аның бөеклеген аңлата. Ул үзенең канаты астындагы барлык кешеләрне яклый ала. Барсның ян-ягында түгәрәк калкан. Аңа кашкарый (астра) рәсеме төшерелгән. Ул – озын гомер билгесе. Барс рәсемен башта ак, аннан яшел бөҗра урап алган. Ә яшел җирлектә алтын төсләр белән халкыбызның яраткан орнаменты-бизәге төшерелгән һәм аска «Татарстан» дип язылган. Бизәк илебезнең ямен, уңдырышлылыгын чагылдыра. Шундый җирне изге барс яклый.

Туган илнең нуры булып,
Зәңгәр күктә җилферди.
Яшел, кызыл, ак төсләре
Күз карашын иркәли.
(Татарстан флагы)

Ак барс безнең туграбызда,
Саклый ул халкыбызны.
Зур үрләргә, алга өнди
Гүзәл Татарстаныбызны!

4. Аудиоязма тыңлау: «Туган җирем – Татарстан» җыры (Г.Зәйнашева сүзләре, А.Ключарев көе).

5. Тизәйткеч ятлау. [к] авазы.

Кремль, Казансу, Кабан ...
Күкләргә ашкан Казан!
Төбәлгән карашыбыз
Гүзәл Казанга табан.

## Тема. Шигырь уку: Р.Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан»

**Бурычлар:**

1. Матур әдәбият әсәрләре аша балалар күңелендә туган илне сөю хисе тәрбияләү.

2. Балаларның тыңлый белү, үз фикерләрен башкаларга җиткерә белү сәләтен үстерү.

3. Туган як турында балаларның белемнәрен системалаштыру, сорауларга тулы итеп җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек:** горур, җан эретә торган, тугайлар.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Мин яратам сине, Татарстан»

җыры (Р.Рәкыйпов сүзләре), туп.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 374 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Мәкаль:

Туган җирдәй җир булмас, туган илдәй ил булмас.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. «Сорау – җавап» уены (туп белән).

- Нәрсә ул Туган ил?
- Безнең республикабыз ничек дип атала?
- Татарстан Республикасының башкаласы – …
- Татарстан Республикасының туграсында нәрсә сурәтләнгән?
- Татарстан әләмендә нинди төсләр бар?
- Бу төсләр нәрсәне аңлаталар?

3. Шигырь уку: Р.Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан».

4. Балаларга сораулар:

- Татарстанны ни өчен яратам, дигән шагыйрь?
- Шагыйрь Татарстан халкын нинди дип атаган?
- Әнкәм теле нинди тел ул?
- Бу шигырьдә нинди күренекле шәхесләрнең исемнәрен ишеттегез?

5. Аудиоязма тыңлау һәм кушылып җырлау («Мин яратам сине, Татарстан» җыры, С.Фәтхетдинов башкара).

## Проект. Яхшы сүз – җан азыгы

### Тема. Өстәл театры. «Өч кыз». Татар халык әкияте

**Бурычлар:**

1. Балаларда якыннарына, әти-әниләренә карата кайгыртучанлык, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.

2. Әкияттәге образларны дөрес итеп бирә белү, хәтер сәләтен үстерү.

3. Әдәби әсәрләр аша тирә-юньдәге вакыйгаларга дөрес бәя бирергә, үз фикерләрен башкаларга җиткерә белергә өйрәтү.

**Сүзлек:** гөберле бака, үрмәкүч, эрли.

**Җиһазлар:** туп, әкият өчен кирәк булган өстәл театры атри-

бутлары, «Өч кыз» мультфильмы.

**Эшчәнлек барышы**

1. Мәкаль:

Ата-анаңны тәрбия ит, үзең дә тәрбия күрерсең.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Балаларга сораулар:

- Безнең өчен бик якын, кадерле кешеләр кемнәр алар?
- Якын кешеләрегезне ничек сөендерәсез?
- Авырган чакларда сезнең турында алар ничек кайгырталар?
- Ә сез аларга карата нинди мөнәсәбәттә?

3. Мультфильм карау: «Өч кыз».

4. Әкият эчтәлеге буенча әңгәмә.

- Әни кызларын ничек тәрбияләп үстергән?
- Әнинең авырып киткәнен кем ничек итеп хәбәр иткән?
- Ни өчен олы кыз гөберле бакага әйләнгән?
- Уртанчы кызны тиен ни өчен үрмәкүчкә әйләндергән?
- Кече кызга тиен нинди ягымлы сүзләр әйткән? Кыз ничек гомер кичергән?

5. Үстерешле уен «Ягымлы сүзләр» (туп белән).

Балалар түгәрәктә бер-берсенә туп бирәләр, ягымлы сүзләр әйтәләр: акыллым, сөйкемлем, чибәрем һ.б.

6. Өстәл театры. «Өч кыз» (балалар эшчәнлеге).

## Тема. Хикәянең эчтәлеген сөйләү: Ә.Бикчәнтәева. «Тәмле сүз»

**Бурычлар:**

1. Балаларга әсәрнең эчтәлегенә төшенергә булышу, матур әдәбият геройлары аша төрле начар сыйфатларга: дорфалык, үзен генә яратучанлыкка карата тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү.

2. Үзе һәм яшьтәшләре кылган эшләргә дөрес бәя бирә белү, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен, монологик сөйләмне үстерү.

3. Проблемалы сораулар аша яхшылык, шәфкатьлелек, дуслык турында күзаллау бирү.

**Сүзлек:** тәмле телле, ефәк, юләр, тупас, тәмсез телле.
**Җиһазлар:** «Тылсымлы таяк».
**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 188 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Уен-күнегү «Тәмле сүз» («тылсымлы таяк» белән). Мәсәлән: рәхмәт, зинһар өчен, исәнмесез, хәерле көн һ.б.
2. Хикәя уку: Ә.Бикчәнтәева. «Тәмле сүз».
3. Әңгәмә:
- Әби нинди тәмле сүзләр белә?
- Кунак апа Гөлкәйгә нинди матур сүзләр әйткән? Ни өчен?
- Кемне тәмсез телле дип әйтергә була? Ни өчен?
- Гөлкәй хатасын ничек төзәткән?
4. Хикәянең эчтәлеген сөйләү (5 – 6 бала сөйли).
5. Хәрәкәтле уен «Капкалы».

Түгәрәктә балалар бию көенә биеп йөриләр, ә ике бала каршы-каршы басып, кулларын югары күтәреп, «капка» ясыйлар. Көй туктагач, алар кулларын төшерәләр. «Капка» эчендә калган бала «тәмле» сүз әйтә.

## Проект. Абдулла Алиш иҗаты

### Тема. «А.Алиш – балалар язучысы»

**Бурычлар:**

1. А.Алиш әсәрләренә кызыксыну уяту, язучы әкиятләре аша балаларда уңай сыйфатлар тәрбияләү.
2. Балаларның фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.
3. А.Алишның тормыш юлын, иҗатын өйрәнүне дәвам итү.

**Сүзлек:** батыр, көрәшче, талантлы язучы, әләкче.
**Җиһазлар:** А.Алиш портреты, рәсемнәр, әкият буенча иллюстрацияләр, «Чукмар белән Тукмар» мультфильмы.

**Эшчәнлек барышы**

1. А.Алиш портретын карау. Язучының тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат бирү.
2. А.Алиш әкиятләре буенча иллюстрацияләр карау.

3. Уен-табышмак «Бу кайсы әкияттән?»

а) Җәй буе бал җыя,
Кыш буе хәл җыя.
(Бал корты – «Нечкәбил»)

б) Соскы борын – бакылдык,
Күп сөйләшә – такылдык.
(Үрдәк – «Сертотмас үрдәк»)

в) Алгы тәпиләре кыска,
Чабарга ул бик оста.
Соры тунын сала да,
Ак тунын кия кышка.
(Куян – «Куян кызы»)

г) Башы – тарак,
Койрыгы – урак.
Кычкыртып быргысын,
Уята барысын.
(Әтәч – «Чукмар белән Тукмар»)

4. [У], [ү] авазларының дөрес әйтелешен ныгыту (калын һәм нечкә сузыклар).

Кикрик-ү-ү-үк!
Өс бөтен,
Тамак ту-у-у-ук!
Тавыгым кү-ү-ү-үп,
Баш астында мендәр юу-у-у-ук,
Ку-у-у-у-ук!

5. Мульфильм карау: «Чукмар белән Тукмар».

6. Балаларга сораулар:

- Әби әтәчләренә ни өчен Чукмар һәм Тукмар дип исем биргән?
- Аларның нинди начар гадәтләре булган?
- Әби Чукмар белән Тукмарны ничек тәрбияләгән?
- Алар ничек үзгәргәннәр?

## Тема. Хикәя уку: А.Алиш. «Каз белән Аккош»

**Бурычлар:**

1. А.Алишның әсәрләренә кызыксыну уяту һәм балаларда сәламәтлекне саклау, ныгыту кебек яхшы сыйфатларга карата уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.

2. Әсәрнең эчтәлеген аңларга булышу, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

3. Балаларның тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтаруларына, әсәрнең эчтәлегенә, геройларның эш-гамәленә

карата мөнәсәбәтен белдерү һәм аны үз сүзләре белән әйтүләренә ирешү.

**Сүзлек:** аккош, ябык, көчсез, таза, чак.

**Җиһазлар:** «Көчле һәм көчсез малай» рәсеме.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 160 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Рәсем карау: «Көчле һәм көчсез малай» (ике малайны чагыштыру).

- Бу ике малайга карагач, нәрсә әйтеп була?
- Беренче малай ни өчен таза, көчле булып үскән?
- Икенче малай үсмичә калган, бер көче дә булмаган. Ни өчен?
- Бу кечкенә калган малайга сез нинди киңәшләр бирер идегез?

2. Хикәя уку: А.Алиш. «Каз белән Аккош».

3. Балаларга сораулар:

- Аккош белән Казның әниләре нәрсә турында сөйләшкәннәр?
- Каз үзенең бәбкәсен ничек сыйлаган?
- Аккош баласы велосипедны ничек йөрткән?
- Ни өчен Киек Каз бәбкәсе велосипедта йөри алмаган?
- Көчле, сәламәт булыр өчен, нәрсәләр эшләргә кирәк?

4. Җырлы-биюле уен «Чума үрдәк, чума каз».

## Проект. Хуш киләсең, ямьле көз!

### Тема. Бакча тирәли сәяхәт. «Җәйләр үтте, көзләр җитте»

**Бурычлар:**

1. Балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксынучанлык сыйфатлары тәрбияләү.

2. Үзләштерелгән сүзлек запасына таянып, агач, яфрак, үләннәрне, һава торышын тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен үстерү.

3. Күзәтүләрдән чыгып нәтиҗә ясаганда, исем ясагыч һәм сыйфат дәрәҗәләрен белдерүче кушымчалардан файдаланырга өйрәтү (яшькелт, ямь-яшел, сап-сары, зәп-зәңгәр һ.б.).

**Сүзлек:** яшькелт, сап-сары, зәп-зәңгәр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак:

Һәр көн диярлек
Елап яшь коя.
Килгән кошларны
Көньякка куа. (Көз).

2. Бакча тирәли экскурсия (көзне чагылдырган барлык үзгәрешләрне күзәтү).

Балалар яфраклар җыялар, аларны саныйлар.

3. Үстерешле уен «Сүзләр ясау».

Мәсәлән: кызыл – кып-кызыл, яшел – яшькелт, ямь-яшел, сары – сап-сары һ.б.

4. Җырлы уен «Көз һәм яңгыр».

Балалар бер якка тезелеп басалар, алар каршында Көз басып тора.

Балалар: Исәнме, Көз, алтын көз!
Безне сагынып килдеңме?
Агачларга, куакларга
Сары чуклар элдеңме?
Көз: Саумы, нәни дусларым!
Сезне сагынып килдем мин,
Сезгә аяз көннәрдә
Яңгыр алып килдем мин.
Балалар: Яңгыр яу, яу, яу, яу!
Бар табигать юынсын,
Тирә-як көлеп торсын!
Көз: Яу-яу-яу!- дип яңгыр телисез,
Ә үзегез качып йөрисез.

Көз балаларны куа башлый. Берничә бала тотылгач, рольләр алышына һәм уен шулай дәвам итә.

5. Көз турында сынамышлар.

а) Миләш күп булган елны көз озын һәм яңгырлы була.

б) Сентябрьдә алма, ә октябрьда кәбестә исе аңкый.

в) Агачтан яфрак сирәк коелса, кыш салкын була.

## Тема. Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге табигать»

**Бурычлар:**

1. Балаларда бер-берсен тыңлый белү, кирәк урында тулыландыра белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның игътибарлылыгын, рәсемдәге детальләрне күрә алу сәләтен үстерү.

3. Рәсем буенча хикәя төзеп сөйләргә ярдәм итү.

**Сүзлек:** каен, нарат, имән, алтын көз, өн.

**Җиһазлар:** «Көзге табигать» рәсеме, аудиоязмада «Көзге җыр» (М.Мозаффаров көе).

## Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява;
Җирләр дымлана, –
Бу кайчак була? (Көз)

2. Җырлы уен. «Көз һәм балалар».

- Көз, Көз, әйт әле,
Кәрзинеңдә ниләр бар?..

3. Рәсем карау:

- Елның кайсы вакыты сурәтләнгән?
- Ни өчен шулай уйлыйсыз?
- Еракта нәрсә күрәсез? Ул нинди?
- Рәсемдә нинди агачлар күрәсез?
- Көз аларга нинди төсләр бүләк иткән?
- Күк йөзе нинди?
-Үләннәрне, чәчәкләрне көз ничек үзгәрткән?
- Урман читендәге елга турында нәрсә әйтеп була?
- Бу рәсем сезгә нинди кәеф бүләк итә?
- Бу рәсемгә сез нинди исем бирер идегез?

4. Рәсем буенча балалар хикәясе (4 – 6 бала хикәя сөйли).

5. Аудиоязма тыңлау: «Көзге җыр» (М.Мозаффаров көе).

## Тема. Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Көз»

**Бурычлар:**

1. Балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек сыйфатлары тәрбияләү.
2. Балаларның хәтер сәләтен, диалогик сөйләмнәрен үстерү.
3. Матур әдәбият белән балаларның кызыксынуын үстерү буенча алдагы эшчәнлектә башлаган эшне дәвам итү, шигырьнең эчтәлеген, катлаулы сүзләрне аңларга булышу, шигырьне яттан сөйләргә өйрәтү.

**Сүзлек:** елый, сер (яшерелгән), аяз, коймый, талгын җил, шиңәләр, сеңәләр, бәргәләнә, бармак яный, гомергә, моңсу, гүя, харап булмыйк.

**Җиһазлар:** көз рәсемнәре, аудиоязмада «Көзге җыр» (М.Мозаффаров көе)

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 187 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Мәкаль:

Көзге көн, бала кебек, әле көлә, әле елый.

- Көн елый яки көлә беләмени?

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Сынамышлар (әти-әниләр белән берлектә өйрәнгән сынамышларны искә төшерү).

а) Сентябрь аяз булса, көн салкын булыр.

б) Сентябрьдә кар күренсә, көз озак килер.

в) Агач яфрак коймый, кар яумый һ.б.

3. Шигырь уку: Х.Халиков. «Көз».

4. Балаларга сораулар:

- Көзге җил яфраклар белән ничек уйный?
- Иртә-кичен ни өчен суык була?
- Нинди кошлар җылы якка китә?
- Казлар ник моңсулана?
- Торналар нинди сүзләр белән хушлашалар?
- Аларны нәрсә куркыта?
- Ни өчен алар кышларга безнең якта калмый?

5. Шигырьне яттан сөйләү (4 – 6 бала яттан сөйли).

6. Музыка тыңлау. «Көзге җыр» (М.Мозаффаров көе). Музыка астында хәрәкәтләр ясау һәм хәрәкәтләрне аңлата бару.

## Проект. Көз күчтәнәчләре

### Тема. Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт. «Көзге могҗиза»

**Бурычлар:**

1. Балаларда туган як табигатенә, яшелчәләргә карата сакчыл караш тәрбияләү.

2. Балаларның иҗади күзаллауларын, күзәтүчәнлекләрен, ло-

гик фикерләү сәләтен үстерү.

3. Яшелчәләр турындагы белемнәрен системалаштыру, алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү.

**Сүзлек:** кисмәк, җиз бүкән, чүлмәк, яшелчә, тәм.

**Җиһазлар:** төрле формаларга кереп үскән яшелчәләр.

## Эшчәнлек барышы

1. Табышмаклар.

а) Озын яшел – түтәлдә,
Сары, тозлы – кисмәктә. (Кыяр)
б) Җир астында җиз бүкән,
Һәркөн ашыйсың, иркәм. (Бәрәңге)
в) Үсеп утыра бер чүлмәк,
Өстенә кигән йөз күлмәк. (Кәбестә)
г) Өч кат тун кигән,
Кем салдырса, шул елый. (Суган)

2. Балаларга сораулар. Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт.

- Яшелчәләр кайда үсә?
- Яшелчәләр ни өчен кирәк?
- Уңыш үссен өчен нинди шартлар кирәк?
- Иң файдалы нинди яшелчәләрне беләсез?
- Яшелчәләрдән нинди ризыклар әзерләп була?
- Күргәзмәдәге яшелчәләр нәрсәләргә охшап үскәннәр?

3. «Реклама ясa» уены.

Үрнәк: кыяр – яшел төстә, озынча, тәмле; ул түтәлдә үсә; кыяр файдалы; аннан салат ясыйлар, аны тозлыйлар, аны косметикада кулланалар; кыяр күп ашасагыз, тиз үсәрсез h.б.

4. Дидактик уен. «Бер – күп» (яшелчәләрне берлек һәм күплек санда әйтү: -лар -ләр, -нар -нәр кушымчаларын дөрес куллану).

5. Санамыш.

Мин барамын бакчага
Яшелчәләр сайларга.
Озын койрык, яшел чук,
Монда торма, тизрәк чык!

6. Бармак уены.

Кыяр өлгерә,
Борыч кызара,
Кәбестә үсә,
Помидор пешә,
Суган, сарымсак әзер –
Тик җыеп кына өлгер! (Кул йодрыкланган, бармакларны ача баралар).

**Тема. Сәхнәләштерү: В.Хәйруллина. «Яшелчәләр бәхәсе»**

**Бурычлар:**

1. Балаларда матур әдәбият әсәрләренә кызыксыну тәрбияләү.
2. Артистлык сәләтләрен үстерү.
3. Тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен ныгыту, шигырь эчтәлеген истә калдырырга ярдәм итү.

**Сүзлек:** бәхәсләшә, рәйхан гөл, тәпән, баклажан, каротин.

**Җиһазлар:** битлекләр, яшелчә муляжлары.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 513 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Санамышны кабатлау:

Мин барамын бакчага
Яшелчәләр сайларга.
Озын койрык, яшел чук,
Монда торма, тизрәк чык!

2. Бармак уены.

Кыяр өлгерә,
Борыч кызара,
Кәбестә үсә,
Помидор пешә,
Суган, сарымсак әзер –
Тик җыеп кына өлгер! (Кул йодрыкланган, бармакларны ача баралар).

3. Үстерешле уен «Кем беренче таный».

Бер бала яшелчә билгеләрен әйтә, калганнары нинди яшелчә булуын ачыклый.

4. Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Яшелчәләр бәхәсе».
5. Балаларга сораулар:
- Яшелчәләр ни өчен бәхәсләшә?
- Алар үзләрен ничек мактыйлар?
- Каротин кайсы яшелчәдә күп?
- Чөгендер барлык яшелчәләрне нәрсә әйтеп тынычландыра?
- Сез нинди яшелчә яклы?
6. Шигырьне сәхнәләштерү (бер яшелчә ролен берничә бала башкара ала).
7. Сүзле уен «Аш пешерү» (балалар, сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар).

Ярдәм көтеп тормыйбыз,
Яшелчәләр турыйбыз.
Чиста итеп юабыз,
Без кәбестә турыйбыз.
Бераз кишер кырабыз,
Ваклап суган турыйбыз,
Тозлап, майлап алабыз,
Яхшылап болгатабыз,
Бигрәк тәмле, ашагыз!

## Тема. Шигырь ятлау: Х.Гарданов. «Түтәлләрдә үсте яшелчә»

**Бурычлар:**
1. Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү.
2. Балаларның хәтер сәләтен, игътибарлылыгын үстерү.
3. Матур әдәбият әсәрен сәнгатьле итеп сөйли белүләренә ирешү, сорауларга тулы җавап алу.

**Сүзлек:** катлы-катлы, йодрык-йодрык, кып-кызыл.

**Җиһазлар:** киселгән өлешләрдән торган яшелчә рәсемнәре, яшелчәләр.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 512 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Уен. «Таралган рәсемнәр» уены (киселгән өлешләрдән

яшелчә рәсемнәре җыю).

2. Шигырь уку: Х.Гарданов. «Түтәлләрдә үсте яшелчә».

3. Балаларга сораулар:

- Көз көне түтәлләрдә нинди яшелчәләр үсә?

- Җир өстендә катлы булып нәрсә үсә?

- Алма кебек кызарган, йодрык-йодрык, ул нәрсә?

- Җир астына төшкән, кызыл булып пешкән – нәрсә ул, кем әйтә?

4. Шигырьне яттан сөйләү (4 – 6 бала шигырь сөйли).

5. «Тәме буенча бел» уены (балаларның күзләрен бәйләп яшелчә каптыру, тәме буенча нинди яшелчә булуын ачыклау).

6. Хәтер үстерү уены «Без (яшелчәләр) нинди әкиятләрдә, мультфильмнарда бар?»

## Проект. Икмәк – яшәү терәге.

### Тема. «Игенче хезмәте белән танышу»

**Бурычлар:**

1. Балаларда игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.
2. Табышмаклар ярдәмендә күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү.
3. Яңа очраган сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүзлек запасын баету, игенче хезмәтенең авыр һәм мактаулы эш икәнен аңлату.

**Сүзлек:** сабан, механизатор, комбайнчы, тракторчы, агроном.

**Җиһазлар:** слайдлар, рәсемнәр, аудиоязмада «Чайкала иген кырлары» җыры (Г.Латыйп сүзләре, И.Шәмсетдинов көе).

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмаклар:

а) Тәгәрмәчләр өстендә
Зур гына арбасы бар.
Аның эченә салып,
Бик күп йөкләр ташыйлар. (Машина)

б) Ат түгел, кешнәми,
Йөз аттан ким эшләми.
Үзе йөри тыр да тыр,
Йә, бу нәрсә, кем әйтер? (Трактор)

в) Эшне генә ярата ул,
Булганы юк уенда.
Аннан башка үткәрәләр,
Үзе килми туена. (Сабан)

г) Ура, суга, җилгәрә,
Үзе төяп җибәрә.
Бик күп җыеп игенне,
Баета ул илемне. (Комбайн)

2. Үстерешле диалог. «Ил табыны икмәктән башлана» (слайдлар, «Тракторчы», «Комбайнчы» рәсемнәре ярдәмендә).

- Икмәк өстәлгә нинди юллар белән килә?
- Икмәк үстерүдә кемнәр катнаша?
- Икмәк үстерүдә нинди һөнәр ияләренең хезмәте әһәмиятле?
- Икмәк үстергәндә нинди транспорт төрләре кулланыла?
- Алар нинди эшләр башкара?
- Икмәккә мөнәсәбәт нинди булырга тиеш?

3. Шигырьдән өзекләр уку. Р.Вәлиева. «Без игенчеләр булдык».

Тракторын тырылдатып,
Наил килеп тә җитте.
Сүз әйтергә өлгермәдем,
Җирне сөреп тә китте.
Тырма тагып артына,
Китереп бар шартына,
Шәпләп тырмалап бирде.
Комбайнын гөрләтеп,
Камил килеп тә җиткән.
Үзе ура, үзе суга,
Үзе җилгәрә икән.
Карасам, КамАЗы белән
Алмаз килеп тә җиткән.
Чыж да выж килеп йөрде,
Игенне ташып бирде.
Ипекәй ул – менә шундый
Тырыш хезмәт җимеше.

4. Җыр тыңлау: «Чайкала иген кырлары» (Г.Латыйп сүзләре, И.Шәмсетдинов көе).

5. Җырлы-хәрәкәтле уен «Ак калач».

## Тема. Әңгәмә. «Икмәк – тормышның нигезе»

**Бурычлар:**

1. Икмәккә сак караш тәрбияләү.
2. Балаларның игътибарлылыгын, хәтерен, фикер йөртә белү сәләтен үстерү.
3. Балаларга икмәкнең әһәмиятен аңлату, ипи үстерүдә катнашучыларның хезмәте турында белемнәрен ныгыту.

**Сүзлек:** ярма, орлык, башак, бөртек, тегермән.

**Җиһазлар:** слайдлар, эчтәлекле рәсемнәр, «Алтын бөртекләр» мультфильмы.

### Эшчәнлек барышы

1. Әңгәмә. «Икмәк – тормыш нигезе».

- Безнең өстәлебездә көн дә нинди ризык була?
- Икмәк нинди ул? Икмәкнең нинди төрләрен беләсез?
- Ни өчен икмәк – тормыш нигезе дибез?
- Икмәк үстерүдә кемнәрнең хезмәте зур?
- «Икмәкнең валчыгы да бездән олы, коеп ашама» дигән әйтемне сез ничек аңлыйсыз?

2. Дидактик уен «Тәртип буенча тезеп чык һәм сөйлә» (икмәк үстерүчеләрнең эшен күрсәткән эчтәлекле рәсемнәрне тәртип белән тезү: сөрәләр, тырмалыйлар, чәчәләр, уралар, амбарларга ташыйлар).

3. Эндәш өйрәнү:

Яңгыр яу, яңгыр яу,
Иләктән, чиләктән.
Пәрәмәчтән, коймактан,
Арпадан, бодайдан, –
Эшләр китәр уңайдан.

4. Зиһен үстерү уены «Мәкальне әйтеп бетер».

а) Икмәк – ил ... (тоткасы).
б) Ипидән зур нәрсә ... (юк).
в) Икмәкне әрәм-шәрәм итү зур ... (гөнаһ).
г) Икмәк – тормыш ... (нигезе).

5. Уен «Кем күбрәк камыр ашларын әйтә» (камыр ашларының төрләрен атау).

6. Мультфильм карау: «Алтын бөртекләр».

**Тема. Әкият уку: «Икмәк». Төрекмән халык әкияте**

**Бурычлар:**

1. Икмәккә сак караш, хөрмәт тәрбияләү.

2. Балаларның игътибарлылыкларын, хәтер сәләтен, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.

3. Игенче хезмәте турындагы белемнәрен ныгыту, татар халкының хезмәт сөючән халык икәнен, ялкаулыкның бездә элек-электән зур кимчелек, начар сыйфат саналуын, хезмәт сөю һәркемгә хас сыйфат булырга тиеш икәнен аңлату.

**Сүзлек:** төрекмән, иген, игенче, җир сөрү, ашлык, башак, тегермән.

**Җиһазлар:** слайдлар, рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 225 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Мәкаль:

Пешкән икмәкнең исе – һәр чәчәктән хуш исле.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Әкият уку: «Икмәк». Төрекмән халык әкияте.

3. Әкият буенча әңгәмә үткәрү:

- Егет белән әнисе ничек яшәгәннәр?
- Егет ни өчен тауга киткән?
- Әнисе ипине биргәндә, нәрсә дигән?
- Егетнең: «Әни мине алдаган»,- дигән уе белән килешәсезме?
- Егет урынында булсагыз, сез нишләр идегез?
- Егетнең нинди уңай сыйфатлары бар?

4. Уен-викторина «Икмәк ничек өстәлгә килә?» (өч эшчәнлектә кулланылган сораулар ярдәмендә оештырыла).

5. «Нишләгәнне әйтмибез, ә күрсәтеп бирәбез» уены (игенче хезмәтенә кагылышлы хәрәкәтләр ясау).

## Проект. Минем гаиләм, өем, йорт җиһазлары

### Тема. Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү: «Безнең гаилә»

**Бурычлар:**

1. Балаларда гаилә әгъзаларына хөрмәт, ярату хисләре тәрбияләү.
2. Образлы фикерләү сәләтен үстерү.
3. Балаларның үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзүләренә ирешү.

**Сүзлек:** корыч, әрем, назлы, бәбкәем, гаилә әгъзалары.

**Җиһазлар:** балалар алып килгән, гаилә темасын чагылдыра торган рәсемнәр, фотографияләр.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 206 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку: Г.Тукай. «Безнең гаилә».

Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи –<br>Безнең өйдә без җидәү: безнең песи – җиденчесе.

Бергә ашый, чәй эчә, безнең лә бергә йоклый ул,
Хезмәте дә бар: өйне тычкан явыздан саклый ул.

2. Балаларга сораулар (балалар алып килгән рәсемнәрен, фотографияләрен файдаланып җавап бирәләр).

- Сезнең гаиләдә кемнәр бар?
- Алар нәрсә белән шөгыльләнәләр?
- Сезнең гаиләгезнең яраткан бәйрәме нинди?
- Ял көннәрен сез ничек үткәрәсез?
- Сезнең гаилә нинди?

3. Уен-ситуация. «Бездә шулай, ә сездә ничек?»

Тәрбияче башлый, балалар дәвам итә:

а) Мин кайткач аш бүлмәсенә керәм, бәрәңге әрчергә тотынам. Әтиебез ит турый, кечкенә улыбыз әтисенә булыша. Ә сездә ничек? ...;

б) Эшләр беткәч, кичке ашны ашагач, без ял итәбез. Мин китап укыйм. Әтисе белән кечкенә улыбыз шашка уйный. Әбиебез оекбаш бәйли. Ә сездә ничек? ... (тәрбияче, үз күзлегеннән чыгып, ситуацияләрне күбәйтә ала).

4. Балаларның үз тәҗрибәсеннән чыгып төзелгән хикәяләре (фотографияләр һәм алдагы сорауларны кулланып төзелә).

5. Табышмак:

Кайвакыт ул мамык кебек йомшак,
Кайвакыт ул корыч кебек каты,
Кайчагында баллы, татлы,
Ә кайчакта әремнән дә әче. (Тел)

6. Тәрбияви күнегү «Назлы сүзләр» (гаиләдәге кешеләргә матур сүзләр белән эндәшү; мәсәлән: әнием, әтием, әнкәем, әткәем, әбекәем, әбекәй, дәү әни, дәү әти һ.б.).

7. Шигырь уку: Н.Исәнбәт. «Иң матур сүз».

### Тема. «Әби-бабайларны хөрмәтлик!»

**Бурычлар:**

1. Зурларга карата хөрмәт тәрбияләү.
2. Куелган сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирү осталыгын үстерү.

3. Әби-бабайларның кадерле кешеләр булуын төшендерү.

**Сүзлек:** дәү әни, дәү әти, өлкәннәр, онык, хөрмәт.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Әбием җыры» (Ә.Синугыл сүзләре, Г.Гәрәева көе).

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 128 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Тизәйткеч:

Сорамадым соравын,

Алдым бабам боравын.

2. Әңгәмә. «Әби-бабайларны хөрмәтлик!»

- Безнең өчен бик якын, газиз кешеләр – кемнәр алар?

- Әти-әнигә кем тормыш биргән? Аларны кем карап үстергән?

- Әби-бабай дип кенә түгел, тагын нинди ягымлы сүзләр белән эндәшәбез?

- Әби-бабаларыгыз, яратып, сезгә ничек итеп эндәшәләр?

- Сездән читтә яшәгән әби-бабаларыгызның хәлләрен ничек беләсез?

- Әби-бабайларыгызга ничек булышасыз?

3. Хәрәкәтле уен «Бабай һәм оныклар».

Бер бала – бабай, калганнары – оныклар; бабай өйдә утыра, ә оныклар өйдән читтәрәк нәрсә эшләячәкләре турында сөйләшәләр. Мәсәлән: бакчада җир казыдык, оекбаш бәйләдек, кер юдык һ.б. Аннары бабай янына киләләр, бабай алардан: «Сез кайда булдыгыз?»- дип сорый. Балалар: «өйдә», «урманда», «бакчада» һ.б. дип җавап бирәләр. Бабай: «Сез анда нишләдегез?»- ди. Балалар бергәләп бертөрле хәрәкәт белән нәрсә эшләгәннәрен күрсәтәләр. Бабай белергә тиеш. Дөрес җавап әйтелгәч, балалар йөгерәләр, бабай аларны куа. Беренче тотылган бала бабай була.

4. Шигырь уку: Р.Корбан. «Оекбаш».

5. Балаларга сораулар.

- Йон оекны безгә кемнәр бәйли?

- Ни өчен ул җылы була?

6. Тәрбияви күнегү «Кем күбрәк әйтә» («тәмле» сүзләр әйтешү).

7. Җыр өйрәнү: «Әбием җыры» (Ә.Синугыл сүзләре, Г.Гәрәева көе).

## Тема. Шигырь ятлау: Ә.Бикчәнтәева. «Дәү әнием»

**Бурычлар:**

1. Гаиләңне ярату, дәү әниләргә карата хөрмәт хисләре тәрбияләү.

2. Балаларның хәтер сәләтен, игътибарлылыгын, диалогик сөйләмен үстерү.

3. Шигырьне сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре бирү.

**Сүзлек:** гаилә әгъзалары, дәү әни, бәбкәм, нур.

**Җиһазлар:** гаиләгә кагылышлы рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 109 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Тизәйткеч. [з] авазы.

Зурлый белсәң,
Зурлар зурлар.
Зурлаганны
Зурлый зурлар.

2. Шигырь уку: Ә.Бикчәнтәева. «Дәү әнием».

3. Балаларга сораулар:

- Кем ул дәү әни?
- Дәү әни нинди?
- Дәү әни нәрсәләр эшли?
- Кемнең дәү әнисе бар?
- Дәү әни безгә ничек эндәшә?
- Ул безне нәрсәләргә өйрәтә?
- Дәү әнигә без нинди матур сүзләр әйтәбез?
- Дәү әни сүзен нинди сүзләр белән алыштырып була? (әби, әбием, әбекәй)

4. Шигырьне яттан сөйләү (4 – 5 бала яттан сөйли).

5. «Дәү әнигә эндәшү» уены.

Балалар ике командага бүленәләр. Һәр командага йомгак бирелә. Алар, ягымлы сүзләр әйтә-әйтә, йомгак урыйлар. Кайсы команда соңгы сүзне әйтә, шул җиңүче була. Мәсәлән: әбекәем, әбием, дәү әни, матурым, алтыным, яратканым һ.б.

## Тема. «Һәркемнең үз йорты бар»

**Бурычлар:**

1. Балаларда дөньяда яшәүче башка халыкларга ихтирам, алар турында кызыксыну сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның фикерләү, күзаллау сәләтен үстерү.

3. Җир йөзендә яшәүче халыкларның торак йортлары, аларның яшәү урыннарына бәйле булуы турында аңлату.

**Сүзлек:** тирмә, мич, бишек, сандык, сәке.

**Җиһазлар:** әкият өчен рәсемнәр, слайдлар, макетлар, мини-музей.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 450 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Ковролинда «Төлке һәм куян» әкиятеннән өзек карау. Балаларга сораулар.

- Куян өен нәрсәдән төзегән?
- Төлкенең өе нинди булган?
- Ни өчен төлкенең өе эреп беткән?
- Төлке өен дөрес төзегәнме?

2. Слайдлар, рәсемнәр карау: «Нинди йортлар була».

3. Балаларга сораулар:

- Йортларны нинди табигый материаллардан төзиләр? Ни өчен?
- Ни өчен шәһәрдә өйләрне күпкатлы итеп төзиләр?
- Авылда өйләрне нинди материалдан төзиләр?
- Нинди өйләрдә яшәү уңайлырак?
- Сезнең өй нинди материалдан төзелгән һәм ничә катлы?

4. Тәрбияче хикәясе.

Йортлар безне салкыннан, кызудан, яңгырдан, кардан саклыйлар. Без өйләребездә ял итәбез, ашыйбыз, эчәбез, дусларны кунакка чакырабыз һ.б. Өйләр бик күп төрле була. Аларны кешеләр яшәү урыннарының үзенчәлекләрен, һава торышының нинди булуын истә тотып, ул җирлектә нинди төзү материаллары куллануның уңай булуын исәпкә алып төзиләр. Мәсәлән: су басу куркынычы булган урыннарда өйләрне җирдән күтәртеп эшлиләр, көтүчелек белән шөгыльләнүчеләрнең күчеп-күчеп

йөрергә мәҗбүр булу сәбәпле, йортлары да җыелма була, бик кызу урыннарда өйләрне кызыл балчык белән сылап та төзиләр, чөнки мондый өй эченә җылы керми һәм салкынча һава тора һ.б.

- Кайсы милләт халыклары тирмәдә яши? Ни өчен?

5. Башкорт халык уены «Тирмә».

Уенда дүрт төркем балалар катнаша. Һәрбер төркем үз түгәрәгенә баса. Түгәрәкнең уртасында милли яулык капланган урындык тора. Һәр төркем үз түгәрәгендә җыр җырлап әйләнеп йөри:

Без – шат балалар,
Түгәрәккә басабыз.
Аланлыкка җыелып,
Әйлән-бәйлән уйныйбыз.

Аннан соң балалар музыка көенә бер зур түгәрәк ясап йөриләр. Музыка бетү белән, һәр бала үз урындыгына йөгерә, яулыкның дүрт почмагыннан тотып, баш өстенә күтәрәләр. Тирмә барлыкка килә.

6. Мини-музейда борынгы татар йортының җиһазларын карау.

- Йортта мичнең нинди әһәмияте бар?
- Бишектә кемне тирбәтәләр? Ни өчен?
- Сандыкта әбиләр, әниләр нәрсә саклый?
- Сәкене нәрсә өчен кулланырга мөмкин?
- Бабайлар урындык, өстәлне нәрсәдән ясаганнар?

7. Уен. «Табышмак әйтәм – җавабын табыгыз!»

а) Аягы бар, кулы юк,
Аркасы бар, түше юк.
(Урындык)

б) Дүрт туган бер ашъяулык астында. (Өстәл)

в) Калын түшәк салынган,
Мендәр, юрган куелган.
Бик уңайлы бу ятак,
Рәхәтләнеп мен дә ят.
Исеме аның?... (Караватт)

г) Беләсезме бу өйне?
Сыйдырган бар киемне. (Шкаф)

8. Шигырь уку: Х.Халиков. «Без төзүчеләр».

### Тема. Әңгәмә. «Йорт җиһазлары»

**Бурычлар:**

1. Йорт җиһазларына сакчыл караш, аларны ясаучыларга хөрмәт тәрбияләү.

2. Танып белү эшчәнлеген, игътибарлылыкны үстерү.

3. Балаларның йорт җиһазлары турындагы белемнәрен баету, тирәнәйтү.

**Сүзлек:** җиһаз эчендә, өстендә, аста.

**Җиһазлар:** йорт җиһазлары төшерелгән рәсемнәр яки уенчык җиһазлар.

**Эшчәнлек барышы**

1. «Яңа фатир» уены.

Алып баручы бүлмә фрагментлары сурәтләнгән зур карточкалар өләшә һәм кечкенә предметлы карточкаларны күрсәтә. Балалар үз рәсемнәрендә булырга тиешле, йорт җиһазлары төшерелгән карточкаларны дөрес әйтәләр һәм сорап алалар. Кем тизрәк шакмакларны каплап бетерә, шул җиңүче була.

2. Әңгәмә:

- Йорт җиһазларын нәрсәдән ясыйлар?
- Җиһазларны кайда ясыйлар?
- Кайдан сатып алалар?
- Йорт җиһазлары ни өчен кирәк?
- Өстәлләрнең нинди төрләрен беләсез?
- Нинди шкафлар була, алар ни өчен кирәк?
- Йорт җиһазлары булмаса, нәрсә булыр иде?

3. Зиһен үстерү уены «Сезнең фатирда нинди йорт җиһазлары бар, алар кайда урнашкан?»

4. «Табышмак әйтәм – җавап тап» уены (балалар йорт җиһазлары турында табышмаклар уйлап әйтешәләр).

5. Үстерешле уен. «Нәрсә үзгәрде?» (мәсәлән: алма өстәл өстендә иде, ә хәзер алма өстәл астында һ.б.).

6. Хәрәкәтле уен «Буш урын».

Урындыклар тезелә, балалар музыка астында урындыклар тирәли йөри. Музыка туктауга урындыкка утырырга җитешмәгән бала уеннан чыга.

## Тема. Шигырь уку: Ә.Ерикәй. «Әти йорт төзи»

**Бурычлар:**

1. Балаларда әти кешегә карата ихтирам һәм хөрмәт тәрбияләү.
2. Балаларның диалогик сөйләмен, логик фикерләү сәләтен үстерү.
3. Шигырьне игътибар белән тыңларга, эчтәлеге буенча тәрбияченең биргән сорауларына тулы җавап бирергә өйрәтү, балаларның төзүче һөнәре турындагы белемнәрен системалаштыру.

**Сүзлек:** биек, кирпеч түши, сырлап, шомартып, турылап.

**Җиһазлар:** төзүчеләр һөнәренә кагылышлы рәсемнәр, слайдлар, «Төзүче», «Буяучы» рәсемнәре.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 397 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмаклар:

а) Тик бер генә һөнәр беләм:
Кыям, турыйм, юнам, теләм.
(Балта)

б) Тешләре бар, авызы юк,
Үзе чәйни, үзе йотмый,
Ашаганы – агач он. (Пычкы)

в) Тимер жираф, башы күктә,
Күп күтәрә көче күпкә.
Тонна-тонна йөкләрне
Эләктереп ала ул,
Балконнарны балкытып,
Биек өйләр сала ул.
(Күтәрү краны)

2. Балаларга сораулар: «Төзүче һөнәре» (слайдлар, «Төзүче», «Буяучы» рәсемнәре ярдәмендә).

- Төзелештә кемнәр эшли?
- Төзүче һөнәре ни өчен кирәк?
- Алар нинди эшләр башкара?
- Төзүчеләр булмаса, нәрсә булыр иде?

3. Шигырь уку: Ә.Ерикәй. «Әти йорт төзи».

4. Балаларга сораулар:

- Без нинди һөнәр белән таныштык?
- Йорт нәрсәдән салына?
- Югарыга кирпечне нәрсә ярдәмендә күтәрәләр?
- Йорт төзүдә нинди һөнәр ияләре катнаша?
- Әти үз һөнәрен дөрес сайлаганмы?

5. Хәрәкәтле уен «Буяу сатыш».

Бер бала – буяу сатучы, икенчесе – буяу алучы, калганнары – буяулар; балалар тезелеп басалар һәм буяу сатучы аларның һәрберсенә үз төсен әйтеп чыга. Буяу алучы:

- Дөбер-дөбер...
- Кем бар?
- Миңа буяу кирәк иде.
- Нинди?
- Ак.
-Нәрсә буярга?
- Койма.

Ак буяу булган бала йөгереп китә. Тотылса, ул уеннан чыгарыла.

## Проект. Табын янында

### Тема. Савыт-саба кибетенә сәяхәт

**Бурычлар:**

1. Балаларда савыт-сабага карата сакчыл караш тәрбияләү.

2. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү.

3. Савыт-сабалар кибете турында белемнәрен тулыландыру, тәрбияче үрнәгендә кечкенә хикәяләр төзеп сөйләргә өйрәтү.

**Сүзлек:** чынаяк, чәнечке, пычак, чәйнек, кәстрүл, кашык, чүмеч, сатучы, сатып алучы, киштә.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмаклар:

а) Ут өстенә утырган да,
Борынын чөеп, пар өрә,
Кайный-кайный шапырына
Түрә үзенә күрә. (Чәйнек)
б) Колагы бар, башы юк,
Ашамаган ашы юк. (Кәстрүл)

2. Савыт-саба кибетенә сәяхәт. Балаларга сораулар:

- Сез киштәләрдә нәрсәләр күрәсез?
- Чәйнек, чынаяк, кәстрүл, кашыкларны бер сүз белән ничек

әйтеп була?

- Бу савытларны нинди очракта куллanабыз?
- Бу киштәдә нинди пыяла савытлар бар?
- Нинди алюмин савытлар бар?
- Җиз самавырлар бармы?
- Фарфор савытлар бармы?
- Савыт-сабаларга ярлык ни өчен эленгән?

3. Савыт-сабалар кибете турында хикәя төзү.

Үрнәк: Бу савыт-сабалар кибете. Монда савыт-сабалар сатыла. Фарфор, пыяла, җиз, көмеш, алюмин савыт-сабалар киштәләргә урнашкан. Һәрбер савыт-сабага ярлык эленгән. Бу ярлыкларга савыт-сабаның бәясе язылган. Савыт-сабаларны сатучы сата.

4. Зиһен уены «Сөйләгән буенча тап».

а) Башы гел суда булып тора, ә койрыгы чөйдә эленеп тора (Чүмеч);

б) Ул пыяла, фарфор, пластмасса да була, анда чәй пешерәләр (Чәй пешерү өчен чәйнек);

в) Ул зур да, кечкенә дә була, ул алюмин һәм эмаль була, аның ике тоткасы бар. Анда аш, ботка пешерәләр (Кәстрүл) һ.б.ш. тасвирлау табышмакларын балалар үзләре төзи.

5. Бармак уены.

Баш бармак ала чынаяк,
Имән бармак – тәлинкә.
Урта бармак – чәнечке,
Атсыз бармак аш сала.
Чәнти бармак ала кашык,
Утырырга, әйдә, ашык.

**Тема. Чагыштырма хикәя төзү. «Чәйнек белән самавыр»**

**Бурычлар:**

1. Балаларда бер-берсен тыңлый һәм җавапларны тулыландыра белү сыйфаты тәрбияләү.

3. Савыт-сабаны урынлы куллана белергә өйрәтү.

**Сүзлек:** самавыр, алюмин, эмаль, фарфор, җиз, көмеш.

**Җиһазлар:** самавыр, чәйнек.

## Эшчәнлек барышы

1. Балаларга сораулар:

- Савыт-сабалар нинди төрләргә бүленәләр?
- Чәй эчү өчен нинди савытлар кулланыла?
- Нинди савытларда чәй кайнатып була?

2. Чагыштырма хикәя төзү. «Чәйнек белән самавыр»:

- Бу нәрсә?
- Нинди өлешләрдән тора?
- Нинди материалдан ясалган?
- Нинди аермалары һәм охшаш яклары бар?
- Ни өчен кирәк?

3. Хикәя төзеп сөйләү (4 – 6 бала сөйли).

4. «Самавыр» уены.

«Самавыр» һәм «Әби» сайланып куела. Калган балалар читтәрәк тезелешеп утыралар. Әби балаларга чәй ризыклары исемнәре әйтеп чыга, аларны самавыр ишетмәскә тиеш. Әби самавырның күзләрен каплап: «Чәй эчәргә килә-килә ... шикәр!»- ди. Шикәр, әкрен генә килеп, самавырның аркасына төртә дә, үз урынына барып утыра. Самавыр караганда, балалар барысы да баш бармакларын өскә каратып утырган булалар. Самавыр кем төрткәнен әйтергә тиеш. Әгәр белсә, тотылган бала самавыр була. Белмәсә, шикәргә икенче исем кушылып, уен дәвам итә. Өч мәртәбә әйтә алмаган самавырга җәза бирелә.

## Тема. Әңгәмә: «Мин кунак яратам»

**Бурычлар:**

1. Үзеңне әдәпле тоту күнекмәләрен тәрбияләү.
2. Балаларның фикерне бер юнәлештә туплый белүләрен, сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирә алу сәләтләрен үстерү.
3. Милли ризыклар турындагы белемнәрен тирәнәйтү; балаларны кунакчыл булырга, кунакларга хөрмәт күрсәтергә өйрәтү.

**Сүзлек:** кунакчыл, кыстыбый, чәк-чәк, коймак, бәлеш.

**Җиһазлар:** милли ризыклар муляжы яки рәсемнәр, геометрик фигуралар.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 203 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Юраулар:

а) Самавыр җырласа, кунак килә.

б) Мәче битен юса, кунак көт.

в) Мендәр ишелсә, кунак килә.

г) Пычак яки кашык идәнгә төшсә, кунак килә.

2. Әңгәмә. «Мин кунак яратам».

Тәрбияче: Бүген без халкыбызның күркәм гадәтләреннән берсе – кунакчыллык турында сөйләшербез. Әби-бабаларыбыз элек-электән үк кунакчыл булган, кунакка ачык йөз, сый-хөрмәт күрсәткән.

- Кешеләр ни өчен бер-берсенә кунакка йөриләр?
- Ни өчен кунак килгәнне яратабыз?
- Кунакны каршы алырга ничек әзерләнәбез?
- Кунакны нинди сүзләр белән каршы алабыз?
- Кунакның күңелен ничек итеп ачалар?
- Татар халкы кунакны нинди милли ризыклар белән сыйлый?
- Табын янында әдәпле утыру кагыйдәләрен беләсезме?

3. Шигырь уку: Ш.Галиев. «Кунаклар».

4. «Дөресен әйт!» уены.

а) Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың.
Балга манып кабасың,
Ул нәрсә? (Коймак)

б) Вак-вак кына итеп кисеп,
Өяләр аны таудай.
Чак-чак кына алып, өзеп,
Аша, дустым, син шулай. (Чәк-чәк)

в) Йомырка белән онны
Бутап, камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар. (Өчпочмак)

5. «Нәрсәгә охшаган?» уены (кыстыбый, бәлеш, чәк-чәк, өчпочмак һ.б. нинди формада булуын ачыклау).

6. Мәгънәле сүзләр уены «Әйтеп бетер!»

а) Коры табынга кунак ... (утыртмыйлар).

б) Кунак ишегеңне ачса, син йөзеңне ... (ач).

в) Кунак сые: ... (якты йөз, тәмле сүз), аннан кала ... (ипи, тоз).

г) Каршы алу, озатып калу – ... (кунакка бар хөрмәт).

7. Җырлы уен «Кунаклар».

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар, ур-

тага бер бала чыга, һәм кырыйдагы балалар түгәрәк буенча әйләнеп җырлыйлар:

Ямьле бәйрәм көн иде,
Чакырдык без кунаклар.
Кунакларны сыйларга,
Салдык майлы коймаклар.
Чыж-чыж итеп коймаклар,
Җәелде, әй, җәелде.
(Кулларын як-якка җәяләр)
Менә тагын кечкенә
Булып калды, җыелды,
Җыелды, әй, җыелды.
(Кысылалар)
Аннан ары кабарды,
Кабарды, әй, кабарды.
(Кулларын югары күтәрәләр)
Шиңде, юп-юка калды,
Пеште инде коймаклар.
(Чүгәлиләр)
Сыйландылар кунаклар,
Тордылар, баш иделәр.
(Баш ияләр)
Таралдылар, әй, шатлар,
Бииләр, ай-яй, шатлар. (Бииләр)

## Тема. Хикәя сөйләү: «Тәлинкәнең төбе нинди?»

**Бурычлар:**

1. Балаларда савыт-сабаларга карата сак караш тәрбияләү.

2. Әсәрнең төп идеясен аңлый, геройларның кылган эшләренә дөрес бәя бирү күнекмәләрен, монологик сөйләмне үстерү.

3. Алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү.

**Сүзлек:** ашханә, тәлинкә төбе, аш тәлинкәсе, сай тәлинкә.

**Җиһазлар:** тәлинкәләр җыелмасы, туп.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 56 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Тирәненә аш салалар,
Саенда була ботка.
Минем исемне белсәгез,
Ватылмас идем бушка. (Тәлинкә)

2. Хикәя уку: «Тәлинкәнең төбе нинди?».

3. Балаларга сораулар:

- Тәлинкәнең төбен күрер өчен Мәрьям апа балаларга нәрсә тәкъдим иткән?

- Тәлинкә төбендә нинди рәсемнәр куренгән?
- Галиянең кәефе ни өчен төшкән?
- Галиянең ак тәлинкәсен нәрсәгә охшатканнар?
- Галия урынында булсагыз, сез нишләр идегез?

4. Хикәянең эчтәлеген сөйләү (4 – 5 бала сөйли).

5. Үстерешле уен «Сыйфатын әйт».

Балаларга ризык исемнәре кушыла. Балалар түгәрәккә басалар. Тәрбияче туп ыргыта, ә бала, ризык сыйфатларын әйтеп, тупны кире бирә. Башкалар бу ризыкны танып, исемен әйтәләр.

6. Аз хәрәкәтле уен «Ашханә».

Балалар түгәрәккә басалар. Тәрбияче балаларга ризык исемнәре кушып чыга. Ризык исемнәре кертеп, хикәя сөйләнә. Хикәя барышында исеме чыккан бала әйләнеп ала, ә «ашханә» дигән сүздә барлык балалар да әйләнәләр. Бала, үз ризыгын танымаса, уеннан чыга. Уен түгәрәктә бер генә бала калганчы дәвам итә. Ул җиңүче була.

## Проект. Киемнәр дә безне бизиләр

### Тема. Кием-салым кибетенә сәяхәт

**Бурычлар:**

1. Балаларда киемнәргә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү.
2. Тәрбияче биргән соруларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәсен үстерү.
3. Тормышта тышкы кыяфәтнең дә мөһимлеген аңлауларына ирешү; өс-баш, аяк киемнәрен чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтү.

**Сүзлек:** бизи; шәл, бүрек, башлык – баш киемнәре; өс (аяк) киемнәре.

Эшчәнлек кием-салым кибетендә уздырыла.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Кием кешене бизи.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Үстерешле уен. «Кибеттә үзеңне ничек тотарга?»
- Кычкырып сөйләшмәскә.
- Бер-береңә карата яхшы мөгамәләдә булырга.
- Сатучы белән әдәпле сөйләшергә.
- Үзеңә генә кирәк әйберне карарга.
- Әйберләргә карата сак булырга.
3. Кием-салым кибетенә сәяхәт (кибет белән танышу).
4. Балаларга сораулар:
- Кибеттә нинди бүлекләр бар?
- Ни өчен киемнәрне аерым бүлекләргә урнаштыралар?
- Киемнәрне кайда тегәләр?
- Һәр бүлектәге киемнәрне бер сүз белән ничек әйтергә була? (киемнәрне классификацияләү)
- Безгә киемнәр ни өчен кирәк?
5. Сүзле уен. «Өстегездәге киемнәр турында сөйләгез».
6. Сүзле уен. «Табышмак әйтәм, бел!»

а) Ике колагыннан тартсаң,
Усал агайдан яшерә. (Бүрек)

б) Урманда ул – ерткыч җәнлек,
Ахырына к өстәгәч, була... (бүрек)

в) Иңемдәге соры кәҗәм
Йомшак мамыктыр,
Каты-каты суыкларда
Мине җылытыр. (Мамык шәл)

## Тема. Әңгәмә. «Милли киемнәр»

**Бурычлар:**
1. Халык сәнгате аша балаларда зәвык, матур итеп киенергә теләк тәрбияләү.
2. Балаларның логик фикерләү сәләтен, сөйләм телен үстерү.
3. Милли киемнәргә кызыксыну уяту, үзләренә генә хас булган үзенчәлекләрен ачыклау, төсләрнең берләшүенә игътибар итү.

**Сүзлек:** лалә, өчьяфрак, канәфер чәчәге, милли.

**Җиһазлар:** милли киемнән курчаклар, милли киемнәр, кисмә рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку: Л.Лерон. «Татар баласы».

Калфак кигән кыз баланың
Багып алчы йөзенә,
Нинди гүзәл татар кызы,
Күз тимәсен үзенә.

Килешеп тора түбәтәй
Аның күркәм йөзенә.
Нинди матур татар улы,
Күз тимәсен үзенә.

2. Әңгәмә. «Татар милли киеме кигән кыз һәм малай курчакларын карау».

- Сез нинди милли киемнәр беләсез?
- Ни өчен аларны «милли» дип атыйлар?
- Аларның нинди үзенчәлекләрен әйтергә була?
- Татар халык киемнәрендә нинди орнаментлар (бизәкләр) күренә?
- Милли бизәкләрдә нинди төс юк?
- Малай белән кызның киеме нәрсә белән аерыла?

3. Шигырь – табышмаклар әйтү:

а) Яңа гына идем итек.
Ч өстәгәч, булдым ... (читек)

б) Әнием, ак сәйлән тезеп,
Чиккән яшел бәрхетне.
Бар түбәмдә ... (түбәтәем)
Мин бүген бик бәхетле.

в) Җырлый-җырлый сәхнәләрдә
Кызларның биер чагы.
Кызларга бик килешә
Башындагы ... (калфагы)

4. Җырлы-биюле уен «Түбәтәй».

Түбәтәйнең иң матурын кигәнсең,
Бик ераклардан кунакка килгәнсең.
Түбәтәең энҗеле дә укалы,
Түбәтәем менә кемдә тукталды.
Яле, дустым, җырлап кына ал әле.

Түбәтәй кемдә кала, шул балага «җәза» бирелә: бии, җырлый, табышмакка җавап әйтә һ.б.

5. Тизәйткеч ятлау:

Итек, читек, энә, без,
Матур итеп тегәбез.

6. Үстерешле уен. «Бу нинди бизәк?» (кисмә рәсемнәрне җыю: лалә, өчьяфрак, канәфер чәчәге һәм җыелган бизәк турында сөйләү).

## Проект. Саулык – зур байлык
### Тема. «Су һәм кояш – безнең белән гел юлдаш»

**Бурычлар:**

1. Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү.

2. Балаларның үз фикерләрен дөрес итеп җиткерә белү күнекмәләрен үстерү, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш булдыру.

3. Балаларга сәламәтлекне саклауда табигатьнең әһәмиятен аңлату, чыныгу чаралары белән таныштыру.

**Сүзлек:** талпына, армый-талмый, чыныккан, таза.

**Җиһазлар:** рәсемнәр, слайдлар.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 306 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: М.Хөсәен. «Армыйм да мин, талмыйм да мин».

Балаларга сораулар:

- Физзарядканы ни өчен саф һавада ясау яхшырак?

- Сәламәт булыйк дисәк, безгә нишләргә кирәк?

- «Сәламәт тәндә – сәламәт акыл» әйтемен сез ничек аңлыйсыз?

- Сез сәламәтлегегезне ничек саклыйсыз һәм ныгытасыз?

2. Табышмаклар:

а) Исе юк, төсе юк,
Аннан башка тормыш юк. (Су)

б) Лампа түгел – яктырта,
Мич түгел – җылыта. (Кояш)

в) Ипи түгел, су түгел,
Авыр түгел, аз түгел,
Ансыз яшәү мөмкин түгел. (Һава)

3. Тәрбияче хикәясе.

Үрнәк: Безгә үсү, сәламәт яшәү өчен су, һава һәм кояш бик кирәк. Саф һава һәм кояш тәнебезне чыныктыра, көч өсти. Ләкин кояш нурларыннан дөрес файдаланмасаң, сәламәтлеккә зыян килергә дә мөмкин. Шуңа күрә озак итеп кояшта кызынырга ярамый, урамга чыкканда баш киеме кияргә кирәк. Ә су-

лыкларга су коенырга бары тик зурлар белән генә барырга ярый. Таныш булмаган урыннарда су коену да куркыныч.

4. Дидактик уен «Нәрсә ярый, нәрсә ярамый».

- Кояшта баш киемсез йөрергә ... (ярамый).
- Озак кызынырга ... (ярамый).
- Елганың тирән урынында су коенырга ... (ярамый).
- Әти-әнигә әйтмичә, су буйларына, урманнарга китәргә... (ярамый).

5. Эндәш ятлау:

Кояш чык, чык, чык!
Майлы ботка бирермен,
Тәти кашык бирермен.
Кояш чык, чык, чык!
Тәти кашык сабы алтын,
Безгә кирәкми салкын.

## Тема. Сәхнәләштерү: А.Алиш. «Куян кызы» әкияте

**Бурычлар:**

1. Балаларда матур әдәбиятка кызыксыну, зурлар сүзенә колак сала белү сыйфатлары, сәламәтлеккә сак караш тәрбияләү.
2. Балаларның үзләре белгән әкиятләре буенча тамашалар уйнау осталыкларын, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.
3. Балаларны тирә-юньдәгеләр кыен хәлдә калганын күрә белергә, ярдәмгә килергә, әкият образларын дөрес итеп бирә белергә өйрәтү.

**Сүзлек:** сәламәтлек, дәвалый, киңәш, туңмасын, киез итекләр, бәбкәм, яланаяк.

**Җиһазлар:** куян, куян кызы, Айболит өчен битлек, костюмнар, урман күренеше, аудиоязма – урман шавы, «Куян кызы» мультфильмы.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 50 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Дөньяда иң кирәк,
Иң кирәктән ни кирәк? (Саулык)

2. Мәкаль:

Сәламәтлегеңне саклыйсың килсә, һәрвакыт сак бул.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

3. Әкият уку: А.Алиш. «Куян кызы».

4. Балаларга сораулар:

- Әкият нәрсә турында?
- Куян кызының аягы ни өчен авырткан?
- Куян үзенең кызына нинди ягымлы сүз әйтә?
- Куян кызының аягын кем дәвалый?
- Айболит Куян кызына нинди киңәш бирә?
- Ә сез нинди киңәш бирер идегез?

5. Мультфильм карау: «Куян кызы».

6. Әкиятне сәхнәләштерү: «Куян кызы».

7. Җырлы уен «Куянкай».

Түгәрәк уртасында моңаеп, куян утыра. Түгәрәктәгеләр җырлый-җырлый әйләнәләр:

Ак куянга ни булган,
Әллә инде авырган?
Иптәшен дә табалмый,
Урыныннан да торалмый,
Куян, куян, син сикер,
Иптәшең табып китер!

Куян, бер иптәшен уртага алып, әйләнеп бии, чакырылган бала куян булып кала, уен шулай дәвам итә.

### Тема. Шигырь ятлау: Ә.Ерикәй. «Чисталык сөябез»

**Бурычлар:**

1. Шигырь аша балаларда чисталыкка омтылыш тәрбияләү.

2. Эзлекле һәм сәнгатьле итеп шигырьне сөйләү күнекмәләрен, хәтер сәләтен үстерү.

3. Балаларны гигиена кагыйдәләренә гадәтләнергә өйрәтү, чисталык – сәламәтлекнең нигезе икәнен төшендерү.

**Сүзлек:** пөхтә, кичкырын, сөя.

**Җиһазлар:** сабын, сөлге, тарак, көзге, теш щёткасы һ.б.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Көч һәм рух тамырлары», 72 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмаклар:

а) Сиңа мин һәркөн кирәк,
Нәрсә соң мин, әйт тизрәк! (Су)

б) Хуш исле, шома,
Үзе чисталап юа. (Сабын)

в) Һәркөн авызына капса,
Яратса аны кеше,
Беркайчан да сызламас
Һәм ялтырап торыр теше.
(Теш щёткасы)

г) Аккош кебек ак кына,
Йомшак кына, пакь кына.
Көн дә сыйпый битемнән,
Элеп куям читеннән. (Сөлге)

2. Шигырь уку: Ә.Ерикәй. «Чисталык сөябез».

3. Балаларга сораулар:

- Матур буласыбыз килсә, без нишләргә тиеш?
- Балаларга пөхтәлекне ничек сакларга кирәк?
- Аш алдыннан һәрвакыт нишлибез?
- Кичкырын аякларны нәрсә белән юабыз?
- Чиста тору өчен нишләргә кирәк?

4. Шигырьне яттан сөйләү (5 – 6 бала сөйли).

5. «Реклама яса» уены (тарак, сөлге, теш щёткасы һәм пастасы, сабын, шампунь һ.б.).

## Проект. Исеменә күрә – җисеме

### Тема. Әңгәмә. «Исемең матур, кемнәр куйган?»

**Бурычлар:**

1. Балаларда башка кешеләргә карата игътибар, исемнәргә кызыксынучанлык тәрбияләү.
2. Логик фикерләүне, хәтер сәләтен, хәрәкәт активлыгын үстерү.
3. Балаларга һәр исемнең аерым бер мәгънә белдерүе турында төшенчә бирү; үзеңнең дә һәм иптәшләреңнең дә исемен һәм фамилиясен кыскартырга, үзгәртергә, бозарга ярамаганлыгын аңлату.

**Сүзлек:** ышанычлы, турылыклы, куркусыз, тынычландыручы, дәвалаучы, мәгънәле.

**Җиһазлар:** курчак, яулык.

## Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Кешегә дә ябышкан,
Әйбергә дә ябышкан,
Хайванга да ябышкан,
Сикерсәң дә, төшеп калмый,
Әйтегез бер тавыштан. (Исем)

2. Тәрбияче хикәясе.

Безнең һәрберебезнең үз исеме бар. Аларны безгә эти-әниләребез, әби-бабаларыбыз бирә. Татар халкы элек-электән үк балага матур, тирән мәгънәгә ия булган исемнәр кушарга тырышкан, чөнки исем кешенең алдагы тормышына тәэсир итә, аның асыл сыйфатына әверелә. Шуның өчен дә исемнәрне бозып әйтергә ярамый. Бозылган исемнең мәгънәсе югала. «Яхшы исем байлыктан да әйбәтрәк» дигән татар халык мәкалендә һичшиксез дөреслек ята. Татар исемнәренең күбесе ил-, ай-, гөл-, нур- кушымчалары ялгап ясалган. Безнең бакчада да андый исемнәр күп. Әйдәгез, бергәләп уйлыйк, сез нинди исемнәр беләсез?

3. «Матур исем әйт» уены.

Ай – Айдар, Айрат, Айнур, Айгөл, Айсылу һ.б.
Ил – Илназ, Илнур, Илгиз, Илгизә, Илсөяр, Илһам һ.б.
Гөл – Гөлназ, Гөлсөяр, Гөлшат, Гөлфирә һ.б.

4. Сүз эчендә энҗе бар. «Исеме җисеменә туры килгән».

- Исемеңнең аңлатмасын беләсеңме? (мәсәлән: Әминә – ышанычлы, турылыклы, куркусыз, Илшат – илгә шатлык китерүче, Гомәр – озын гомерле һ.б.).

5. Шаян шигырьләр:

а) Чәй эчәбез бал белән,
Бала-чагалар белән,
Бала-чага алты җан:
Әхмәт, Нәҗип, Закирҗан,
Зәйнәп белән Галия,
Иң соңгысы Асия.
(Ә.Фәйзи «Асия»)

б) Зәйнәп балык пешергән,
Бану бәреп төшергән,
Оркыясы, җыя-җыя,
Биш бармагын пешергән.

6. «Мин кем?» уены.

Безнең белән уйна, Ләйлә,
Тик уртага чык әле.
Күзләреңне йомып кына
Кем җырлавын әйт әле.

Бер бала күзен бәйләгән килеш уртага баса. Түгәрәктә баскан бер бала, көйләп: «Мин кем?»- дип сорый. Уртадагы бала, көйләп, иптәшенең исемен әйтә, белмәсә, аңа җәза бирелә.

7. «Адым саен исем ата» уены (уен барышында кем күбрәк исем әйтә, ул җиңүче була).

8. «Үз исемеңне хәрәкәттә күрсәт» уены.

Балалар түгәрәктә утыралар, сәгать теле уңаена үзләренең исемнәрен аңлата торган төрле хәрәкәтләр ясыйлар (уен бер-берсенең исемнәрен истә калдырырга ярдәм итә, уңай хисләр тудыра).

## Тема. «Без дә хокуклы»

**Бурычлар:**

1. Балаларда уеннар аша бердәмлек, дуслык сыйфатлары, әхлаклылык тәрбияләү.
2. Балаларның кызыксынучанлыкларын, үзләренә, тирәюньдәгеләргә карата игътибарлылыкларын, логик фикерләү сәләтен үстерү.
3. Кеше хокуклары турында матур әдәбият һәм рәсем-иллюстрацияләр аша балаларга аңлату, белемнәрен ныгыту.

**Сүзлек:** хокук, пыскып, ятим, кайгыртулы.

**Җиһазлар:** өстәл театры өчен материал, «Төлке, куян һәм әтәч», «Зөһрә кыз», «Золушка», «Үги кыз» әкиятләреннән рәсемнәр, «Көлгенә – Золушка» мультфильмы.

## Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: Ш.Галиев. «Җирдә миңа ни кирәк?»

Бар ла безнең хокукыбыз:
Яшәү урынлы булырга,
Әтиле дә, әниле дә,
Кайгыртулы да булырга.

2. Мәкаль:

Дөньяда иң ачы – ятимлек ачысы.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

Тәрбияче хикәясе: Димәк, һәр баланың әти-әниле булырга, яратырга һәм яратылырга, өйле булырга һәм кайгыртылып яшәргә, сәламәт булырга хокукы бар. Әкияттә бар нәрсә дә тиз генә матурлана да, сәламәт тә була ала, ләкин тормышта алай ук түгел шул!.. Безнең инвалид (сәламәтлекләре җитеп бетмәгән, зәгыйфь) балалар бар, хөкүмәт аларга бик нык игътибар итә, ярдәм күрсәтә, укырга да, ял итәргә дә булыша. Тагын балаларның үз халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, динен тотарга, үз телендә сөйләшергә дә хокуклары бар ...

3. Мультфильм карау: «Көлгенә – Золушка».

4. Балаларга сораулар.

- Үги ана кызның нинди хокукларын кыса?

- Балалар, сезнең нинди хокукларыгыз бар? (Әти-әниле булырга, яратырга һәм яратылырга, өйле булырга һәм кайгыртылып яшәргә, сәламәт булырга, үз халкының гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, динен тотарга, үз телендә сөйләшергә хокуклары бар)

5. Дидактик уен. «Алай ярыймы соң?» («Төлке, куян һәм әтәч», «Зөһрә кыз», «Көлгенә – Золушка», «Үги кыз» әкиятләренә рәсемнәр буенча).

- Нинди хокуклар сакланмаган?

6. Хәрәкәтле уен «Почмак сатыш».

Дүрт почмакта дүрт бала басып тора. Уртадагы бала:

Йортсыз-җирсез калдык без,
Ашсыз-сусыз калдык без,
Кемнәр сата почмагын,
Күп хак биреп алыйк без, – ди.

Шулай дигәч, почмактагылар йөгерешеп, урыннарын алышалар. Урын ала алмаса, уртадагы бала тагын сорый:

Сатлык почмак кемдә бар?
Булса, сатсын почмагын.

Почмактагылар: Кем алдырыр – йөгереп!
Син көтеп тор бер кавым!

## Проект. Салкын кыш. Кышкы уеннар
### Тема. Әңгәмә: «Без суыктан курыкмыйбыз»

**Бурычлар:**

1. Кышкы табигатьнең матурлыгына соклана белү сыйфаты тәрбияләү.

2. Балаларның иҗади күзаллауларын, бәйләнешле сөйләмен үстерү.

3. Кыш турында белемнәрен тирәнәйтү, авазларның дөрес әйтелешен ныгыту.

**Сүзлек:** алсу, ыжгыра, бөтерелә, оча, шуам, тәгәрәтәм.

**Җиһазлар:** кыш турында слайдлар яки рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Тел шомарткыч. [ш], [с] авазлары.

а) Ыш-ыш-ыш,
Безгә килде салкын кыш.

б) Су-су-су,
Суыкта битләр алсу.

2. Шигырь уку: Г.Зәйнашева. «Кыш килде».

Ап-ак тун киеп кыш килде,
Яфрак-яфрак кар ява.
Без дә кидек җылы туннар,
Куркытмый салкын һава.
Чормадан сикереп төште
Чаңгылар һәм чаналар.

Ак мамыктай ап-ак кышны
Сагынып көткәннәр алар.
Сөенәбез, шатланабыз,
Күңелле үтә кышлар.
Чаңгы, чана, тимераяк –
Безнең иң якын дуслар.

3. Әңгәмә. «Кыш килде»:
- Ни өчен тирә-як ап-ак?
- Елның кайсы вакыты?
- Кыш айлары нинди айлар?
- Кышын нинди үзгәрешләр була?
- Кыш сезгә ошыймы? Ни өчен?
- Кыш көне нинди уеннар уйнарга яратасыз?

4. Иҗади күзаллау уены «Карның файдасы һәм зыяны».
- Карның нинди файдасын беләсез?
- Карның нинди зыяны бар?

5. Сүзле-хәрәкәтле уен «Кар ява» (балалар, сүзләргә туры ки-

тереп, хәрәкәтләр ясыйлар).

Ябалак-ябалак кар ява,
Чыгабыз уйнарга,
Урамга – һавага.
Чуарлап өсләрне,
Ябалак кар, яу-яу!
Без ясыйбыз кардан тау,
Ак мамыктай тузгып яу!
Бик дәү булсын безнең тау!

## Тема. Тәҗрибә.
## «Предметларның бер хәлдән икенче хәлгә күчүе»

**Бурычлар:**

1. Туган як табигатендәге үзгәрешләргә карата кызыксынучанлык тәрбияләү.

2. Балаларның күзәтүчәнлеген, фикерләү сәләтен һәм сөйләмен үстерүне дәвам итү.

3. Кайбер әйберләрнең бер халәттән икенче халәткә керүен тәҗрибә ясау юлы белән күзәтеп, балаларның белемнәрен тирәнәйтү.

**Сүзлек:** карлану, кар салу, карлы-бозлы, карлы-буранлы.

**Җиһазлар:** тәҗрибә өчен фильтр.

Эшчәнлек табигатьтә уза.

## Эшчәнлек барышы

1. Табышмак.

Ак кына, вак кына,
Ак мамык сымак кына.
Югала, юк була,
Учта тотсаң чак кына. (Кар бөртеге)

2. Шигырь уку: Г.Афзал. «Беренче кар».

Кояш йөри сүрелеп кенә,
Болытка төренеп кенә.
Кыяр-кыймас әйләнгәләп,
Кар ява иренеп кенә.
Бу әле – кышның малае,
Бу – беренче кар әле.
Ак сакаллы, җил-буранлы
Кыш бабае бар әле.

3. Балаларга сораулар.

- Кар кайчан ява?
- Кар бөртекләре нәрсәгә ошаган?
- Карның нинди үзлекләрен беләсез?

4. Тәҗрибәләр үткәрү.

а) Зурайткыч пыяла аша кар бөртекләрен карау.

- Кар бөртекләре нинди формада?

б) Карның эрүен күзәтү:

- Карны кулга алгач, кар нишли? Ни өчен эри?

в) Карны бияләйгә куеп карау.

- Ни өчен эреми? Карга сулыш өрсәң, нишли? (Суга әйләнә)

- Суны урамда, суыкта калдырсаң, ул нинди халәткә керә? (Алдан әзерләнгән бозны карау)

- Бозны бүлмәгә алып керсәң, нәрсә була?

г) Боз суын фильтр аша үткәрү, нәтиҗәләр ясау. (Эшчәнлек бүлмәдә уза)

5. Үстерешле уен «Кар һәм боз».

Кар һәм бозның үзенчәлекләре чагыштырып әйтелә. Дөрес җавап әйткән балага фишка бирелә. Соңыннан нәтиҗә ясала. Иң күп фишка җыйган бала җиңүче була.

6. Сүзле уен «Кар бөртекләре» (балалар, сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар).

Кар, кар, кар ява,
Бураннарны туздыра.
Кулларга төшеп эри,
Үзе бик тиз туңдыра.
Йомшак карны алабыз,
Аннан туплар ясыйбыз.

7. Зиһен күнегүләре «Сүз эчендә энҗе бар».

- Карлану – кар белән каплану.
- Кар салу – кар яту, кар җыелу, кар өю.
- Карлы – кары булган, кар капланган.
- Карлы-бозлы – кар белән боз катыш.
- Карлы-буранлы – кар яуган һәм буран бураган.
- Тәңкә-тәңкә (кар).

## Тема. Рәсем буенча хикәя төзү: «Кышкы уеннар»

**Бурычлар:**

1. Балаларда үзара дустанә мөнәсәбәт, бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү.

2. Балаларның бәйләнешле сөйләм телен, эзлекле итеп сөйли белү сәләтен үстерү.

3. Балаларның хикәя төзеп сөйли белүләрен ныгыту, рәсемнең

эчтәлеге буенча сорауларга тулы җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек:** шук, шаян, тимераяк, көрт.

**Җиһазлар:** «Кышкы уеннар» рәсеме.

## Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: М.Крыймов. «Җилләр җыры». [ж], [ш], [у] авазлары (балалар белән авазларны ныгыту).

Илләр ашып,
Карлар ташып,
Выжылдыйбыз: «Выж-ж-ж!»
Юллар көрәп,
Карлар иләп,
Без эшлибез: «Эш-ш-ш!»
Биеп-чөеп,
Көртләр өеп,

Без җырлыйбыз: «Ыж-ж-ж!»
Каршы җилгә,
Чыксаң юлга,
Билләреңне «Бу-у-у!»
Тунсыз булсаң,
Бездән туңсаң,
Кулларыңны «Ууу-у-у!»

2. Рәсем карау. «Кышкы уеннар». Әңгәмә:
- Сез рәсемдә нәрсәләр күрәсез?
- Бу рәсемдә нинди көн сурәтләнгән?
- Тау башында балалар нишли?
- Тау итәгендә нинди кызыклы хәл булган?
- Рәсемнең арткы өлешендә кемнәрне күрәсез?
- Алар нишлиләр?
- Бу рәсемгә карап балалар турында нәрсә әйтер идегез?

3. План буенча балалар хикәясе.
а) Кышкы табигатьне тасвирла.
б) Һава торышын тасвирла.
в) Балалар эшчәнлеге турында сөйлә (ничек киенгәннәр? нәрсә эшлиләр?).
г) Рәсемгә исем уйла.

4. Сүзле уен «Кар бөртекләре» (уенны кабатлап уйнау).

Кар, кар, кар ява,
Бураннарны туздыра.
Кулларга төшеп эри,
Үзе бик тиз туңдыра.
Йомшак карны алабыз,
Аннан туплар ясыйбыз.

Кар атышып уйныйбыз,
Бик күңелле яшибез.
Суыктан без курыкмыйбыз,
Рәхәтләнеп уйныйбыз.
Кар бөртекләрен куып,
Уйнаудан һич туймыйбыз.

## Тема. Хикәя уку: К.Ушинский. «Кыш әбинең шуклыгы»

**Бурычлар:**

1. Серле табигать күренешләренә соклану хисләре һәм мәхәббәт уяту.

2. Балаларның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү.

3. Кышкы салкын көннәрнең кошлар, хайваннар, кешеләр өчен иң авыр вакыт булуын ачыклау; балаларны әдәби әсәр аша кышның тасвирланышы белән таныштыру.

**Сүзлек:** өрде, җанвар, корт, шарт-шорт, яра, күшиләр, төпкә, толып, шыбыр тир, бөрки, гарьләнде.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Балалар бакчасы», 314 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак.

Әби килгән сагынып,
Ак чикмәнен ябынып. (Кыш килү)

2. Хикәя уку: К.Ушинский. «Кыш әбинең шуклыгы».

3. Балаларга сораулар:

- Кыш әби кошларга ничек ачуланды?
- Кошлар кая очып киттеләр? Ә нинди кошлар калды?
- Җанварлар кышның салкыннарына ничек җайлаштылар?
- Балыкларга каршы кыш нинди усал гамәлләр кылды?
- Кыш кешеләрне ничек сынады?
- Кыш әби ни өчен гарьләнде?
- Салкын кыш балаларга ничек бәйләнде?
- Кыш нишләп елды?

4. Сынамышлар. «Халык әйтсә, хак әйтә» (әти-әниләр белән берлектә өйрәнгән сынамышларны әйтү):

а) Кояш бик еракта булып күренсә, салкын булыр.

б) Багана сызгырса, суык булыр.

в) Каз аягын күтәреп торса, салкын булыр.

г) Чыпчык агачның очына кунса – көн салкын була, түбән ботакларына кунса – җил чыга.

5. Сүзле уен «Син нишләргә яратасың?»

Балалар бу сорауга чиратлашып җавап бирәләр. Мәсәлән: мин чаңгы шуарга яратам. Ә син?

6. Хәрәкәтле уен «Нардуган».

Бер бала уртага чыга. Башка балалар, аның тирәли бер түгәрәк ясап, кулга-кул тотынышып, түбәндәге нардуган җырын җырлап әйләнәләр.

Син уртада, без кырыйда,
Әйләнәбез, нардуган.
Син нишләсәң, ни кылансаң,
Мин дә шуны булдырам!

Җыр бетүгә, уртадагы бала нинди дә булса бер хәрәкәт ясый, түгәрәктәге балалар шул хәрәкәтне кабатларга тиешләр. Кем шуны булдыра алмый, уртадагы бала үз урынына аны чыгара да, уен баштагыча дәвам итә.

## Проект. Бездә кышлаучы кошлар

### Тема. Балалар бакчасы тирәли экскурсия. «Җимнәр сибәм кошларга»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кошларга сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.

2. Чагыштыру, күзәтүчәнлек, кызыксынучанлык күнекмәләрен үстерү.

3. Балаларның кошлар турында белемнәрен баету, өлкәннәр ярдәмендә җимлекләр куярга өйрәтү.

**Сүзлек:** җим, җимлек.

**Җиһазлар:** кышлаучы кошларның битлекләре, җимлек. Эшчәнлек табигатьтә үтә.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 70 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. «Булсаң зирәк, әйт тизрәк» уены:

а) Гөлдер-гөлдер гөл итекле,
Гөлкәй кызыл читекле.
(Күгәрчен)

б) Җәй тукылдый бу чүкеч,
Кыш тукылдый бу чүкеч.
Ничек чыдый бу чүкеч? (Тукран)

в) Савытыннан сабы озын.
(Саескан)

г) Яшькелт-сары түшле ул,
Бер кечкенә кошчык ул.
(Песнәк)

д) Иртә таңнан кичкә хәтле
Чык-чырык та чык-чырык.
(Чыпчык)

2. Үстерешле диалог. «Кышлаучы кошлар».

- Бездә кышлаучы нинди кошларны беләсез?

- Аларны кайда очратырга була?

- Кышлаучы кошлар нәрсәләр белән тукланалар?

- Кошларга елның кайсы вакытында күбрәк ярдәм кирәк?

- Аларга ничек итеп ярдәм итәргә мөмкин?

- Бу нәрсә? (Тәрбияче алдан әзерләгән җимлекне күрсәтә, агачка элә)

- Ул ни өчен кирәк? (Тәрбияче белән бергә җимлеккә кошлар өчен азык салу. Өйдә дә җимлекләр ясауны тәкъдим итү)

3. Шигырь уку: Ә.Кари. «Кошлар туйдырам».

4. Тизәйткеч. [ж] авазы.

Җим-җим-җим итә,
Җимлеккә кошлар килә.

Җил-җил-җил исә,
Җиде кош очып китә.

5. Сүзле-хәрәкәтле уен «Килегез, кил, кошкайлар» (Х.Гарданов буенча).

- Килегез, кил, кошкайлар.
Сез бит безнең дускайлар.
Бакчабызга куныгыз,
Көн дә кунак булыгыз.
- Чыпчык, чыпчык-чык-чырык,
Җим сиптем, кил тиз очып!

Чыпчык битлеге кигән бала уртага чыга, «җим чүпли» яки бии. Балалар, шулай сүзләргә туры китереп, уртага чыгалар.

- Песнәк, песнәк, кил тизрәк –
Җим сибәм сиңа әзрәк.
- Карга, карга, син кара,
Кабып кал азык барда!

## Тема. Рәсем карау. «Кошлар килгән җимлеккә»

***(И.Н.Мурашковска методикасы буенча)***

**Бурычлар:**

1. Балаларда кошларга сакчыл караш тәрбияләү, ярдәм итәргә теләк тудыру.

2. Рәсемнең эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга дөрес, ашыкмыйча, башкалар ишетерлек һәм аңларлык итеп җавап бирү күнекмәләрен үстерү.

3. И.Н.Мурашковска методикасы буенча, рәсемгә карап, хикәя төзеп сөйләргә өйрәтү.

**Сүзлек:** җимлек, песнәк, түше яшькелт-сары, томшык, койрык.

**Җиһазлар:** магнитофон, кышлаучы кошларның тавышлары язылган аудиоязма, «Кошлар килгән җимлеккә» рәсеме.

### Эшчәнлек барышы

1. Эндәш:

Песнәк, песнәк, кил тизрәк –

Җим сибәм сиңа әзрәк!

2. Аудиоязмада кышлаучы кошларның тавышларын тыңлау.

- Нинди кошны таныйсыз?

3. Рәсем карау. «Кошлар килгән җимлеккә».

4. Балаларга сораулар:

1 адым: - Кем нәрсә күрә, әйтегез (балалар берәмләп һәр предметны әйтә баралар, тәрбияче тактада ясый бара).

2 адым: - Нинди ике рәсемне бергә кушып була, ни өчен? (мәсәлән: җимлек белән песнәкне бәйләп була, чөнки песнәк җимлеккә кунып, бөртекләр чүпли).

3 адым: - «Нинди тавышлар ишетәсең?» (уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү).

4 адым: - «Нинди исләр тоясың?» (уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү).

5 адым: - «Рәсемдәге әйберләрнең сыйфатларын әйтү» (уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү)

6 адым: - Хикәя төзү (биш адымны берләштерү) (5 – 6 бала сөйли; хикәя сыйфатлы булмаса, тәрбияче үрнәк бирә).

5. Сүзле уен.

Карга килә – казан аса,
Саескан килә – су сала,
Тукран килә – тоз сала,
Песнәк килә – пешерә,
Чыпчык килә – тикшерә,
Күгәрчен ашап бетерә.

## Тема. Шигырь ятлау: Д.Гарифуллин. «Песнәк»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кошларга, барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.
2. Шигырьне ятлау теләге булдыру, хәтер сәләтен үстерү.
3. Балаларда шигырьне сәнгатьле итеп сөйләү күнекмәләре булдыру.

**Сүзлек:** кырау, кырпак, читлек, алъяпкыч.

**Җиһазлар:** песнәк рәсеме.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Иң матур сүз», 132 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Кырау булсын,
Кырпак булсын,
Китмәс дустым.
Җәен-кышын
Салмый сары
Алъяпкычын. (Песнәк)

2. Шигырь уку: Д.Гарифуллин. «Песнәк».

3. Балаларга сораулар:

- Песнәк ни өчен тәрәзәне шакый?
- Кошлар ни өчен рәхмәтләрен җиткерәләр?
- Кошлар Илнур турында ниләр әйткәннәр?
- Әтисе улын нинди сүзләр әйтеп үсендергән?

4. Шигырьне яттан сөйләү (4 – 5 бала сөйли).

5. Хәрәкәтле уен «Кошлар һәм читлек».

Уенда катнашучы ярты төркем бала, кулга-кул тотынышып, «читлек» хасил итәләр, калганнары – кошлар. Алар төрле якка очып йөриләр. Уенны алып баручы хәбәр биргәч, читлек ачыла – балалар кулларын югары күтәрәләр. Кошлар читлеккә кереп-чыгып йөриләр. Алып баручы яңадан хәбәр салгач, читлек ябыла – балалар чүгәли төшеп, кулларын төшерәләр. Түгәрәктән чыга алмый калган кошлар тотылган дип исәпләнә. Алар да кулга-кул тотынышып, чит-

лек ясаучылар янына басалар. Өч-дүрт кат читлек ачылып-ябылгач, уенга йомгак ясала. Соңыннан уенчылар урыннарын алмашалар.

## Тема. Шигырь уку: Г.Лотфи. «Балалар ярдәм итә»

**Бурычлар:**

1. Матур әдәбият аша балаларда мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның диалогик сөйләмен, әйләнә-тирә мохит үзгәрешләрен, аларның бер-берсе белән бәйләнешен күрә белү сәләтен үстерү.

3. Авазларны ныгыту буенча эшне дәвам итү. Балаларның сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирүләренә ирешү, кышлаучы кошлар турында белемнәрен ныгыту.

**Сүзлек:** орчык.

**Җиһазлар:** темага туры килгән рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Иң матур сүз», 132 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Авазлар өстендә эш. [т], [ч], [к] авазлары.

а) Кара карга кардан бара,
Канатларын кага-кага.

б) Тукый, тукый тукыган,
Тугыз талны чукыган.

в) Чыпчык, чыпчык, чык, чыпчык,
Чык-чык, кошчык, очып чык.

2. Шигырь уку: Г.Лотфи. «Балалар ярдәм итә».

3. Балаларга сораулар:

- Кышын бездә нинди кошлар яши?
- Кышын салкыннарда кошларга нинди ярдәм кирәк?
- Кошлар балаларга ничек итеп рәхмәт әйтәләр?

4. Санамыш.

Чар, чар, чыпчыклар,
Бирсәгез лә орчыклар.
Анда чык, монда чык,
Саубуллаш та, моннан чык.

5. Сүзле-хәрәкәтле уен (балалар сүзгә туры китереп хәрәкәтләр башкаралар).

Урамда ак кар яуган,
Өй түбәсе агарган.
Агач ботаклары бар да
Яшел күлмәген салган.
Безнең бакчада кошлар да
Нигәдер сайрамыйлар.

Салкын икәнлекне сизеп,
Җим эзләргә очмыйлар.
Әйдә, дуслар, бергә чыгып
Җимнәр салыйк кошларга.
Азык булса, җиңел булыр
Бар кошларга кышларга.

6. Уен-викторина «Кем яхшырак белә».

Балалар ике командага бүленә, командаларга кышлаучы кошлар, аларның үзенчәлекләре турында сораулар бирелә. Беренче дөрес җавап биргән командага фишка бирелә. Соңыннан фишкаларны санап, нәтиҗә чыгарыла.

## Проект. Кыргый хайваннар

### Тема. Төркемдә уен оештыру. «Зоопаркка сәяхәт»

**Бурычлар:**

1. Кыргый хайваннарга карата кайгыртучанлык һәм зоопаркта үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Уеннар һәм тирә-юнь белән танышу барышында балаларның бәйләнешле сөйләм телен, логик фикерләү сәләтен үстерү.

3. Кыргый хайваннар һәм аларның үзенчәлекләре турында белемнәрен баету.

**Сүзлек:** бурсык, маймыл, арыслан, фил.

**Җиһазлар:** өстәл өсте зоопаркы, уенчыклар, рәсемнәр.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмаклар:

а) Үзе кардай ап-ак ул,
Озын колак, бик сак ул.
Дошман күрсә, элдертә,
Кем аны куып җитә? (Куян)

б) Кош түгел – оча,
Ябалактан курка.
Чикләвекне бик ярата.
Сызгырса, урманны яңгырата. (Тиен)

в) Асрамый да умарта,
Балны бик-бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача тормый ята.
(Аю)

2. «Зоопаркка сәяхәт». Балаларга сораулар.

- Зоопарк ни өчен кирәк?
- Зоопаркта нинди хайваннар яши?
- Алар нәрсәләр белән туклаңалар?
- Сезнең зоопаркка барганыгыз бармы?
- Сезне шаккаттырган хайван турында сөйли аласызмы?
- Сез ничек уйлыйсыз, хайваннарга кайда ныграк ошый: читлектәме, әллә ирektәме?

3. Дидактик уен «Дөрес тап. Дөрес итеп билгелә» (интерактив тактада яки рәсемнәрдә кыргый хайваннарның яшәү урыннарын, ризыкларын, табигатькә ничек җайлашуларын ук ярдәмендә билгеләү).

4. Бармак уены:

Баш бармагым бүредер,
Имән бармагым – төлке,
Урта бармагым – бурсык,
Атсыз бармагым – аю,
Чәнти бармагым – куян,
Куянны кая куям?

5. Хәрәкәтле уен. «Куяннар һәм бүре».

Бер бала бүре, калганнары куяннар була. Уен барышында куяннар үз урыннарында (түгәрәкләрдә) утыралар, ә бүре икенче якта (чокырда) утыра. Тәрбияче әйтә:

Ямьле болында куяннар
Сикергәләп йөриләр.
Як-якларына каранып,
Бүре килүен күзлиләр.

Куяннар урыннарыннан чыгып уйныйлар, ә бүре, чокырдан чыгып, куяннарны тотмакчы булып йөри. Куяннар үз урыннарына йөгерәләр. Тотылган куянны бүре үзе белән чокырга алып китә.

## Тема. Рәсем буенча хикәя төзү: «Куяннар»

**Бурычлар:**

1. Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү.
2. Карау өчен бирелгән рәсем турында сөйлисе килү теләген үстерү.
3. Балаларга хикәя төзеп сөйләүгә булышлык итү, кыргый хайваннар турында белемнәрен тирәнәйтү.

**Сүзлек:** куян, көч, җиңеп булмый.

**Җиһазлар:** «Куяннар» рәсеме.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак:

Алгы тәпиләре кыска,
Чабарга ул бик оста.
Соры тунын сала да,
Ак тунын кия кышка. (Куян)

2. Балаларга сораулар:

- Куяннар ни өчен кыш көне ак тун кия?
- Кыш көне куяннар нәрсә белән туклана?

3. Рәсем карау. «Куяннар».

- Рәсемдә кайсы ел фасылы сурәтләнгән? Ни өчен сез алай дип уйлыйсыз?
- Рәсемнең алгы өлешендә нәрсә күрәсез?
- Куяннар нишли? Ни өчен алар урманнан чыкканнар?
- Ни өчен  куянарның берсе, арт аякларына басып, гаҗәпсенеп карап тора?
- Аның турында нәрсә әйтергә була?
- Рәсемнең арткы өлешендә нәрсә ясалган?
- Сез бу рәсемгә  нинди исем бирер идегез?

4. Рәсем буенча балалар хикәясе (4 – 6 бала сөйли).

5. Сүзле уен «Куяннар санамышы».

Бер, ике, өч ...
Куяннарда бөтен көч!
Дүрт, биш ...
Безне җиңеп булмый һич!
Алты, җиде ...
Куяннар башын иде!
Сигез, тугыз, ун ...
Алты бүре – алты тун!
Без тук бүген, бүре ач –
Әнә килә, тизрәк кач!

6. Зиһен үстерү күнегүе (әйтемнәр буенча балаларның фикерен тыңлау).

а) Койрык кыска, озын колак,
Аңа шулай яхшырак.

б) Арткы аяклары озын,
Ә алда алар кыска.

в) Кышын куян ак тун кия,
- Миңа яхшы,- дия-дия.

## Тема. Әкият уку, сәхнәләштерү. «Төлке белән бүре». Татар халык әкияте

**Бурычлар:**

1. Балаларда театр сәнгатенә мәхәббәт һәм эстетик зәвык тәрбияләү.

2. Балаларның үзләре белгән әкиятләре буенча тамашалар уйнау осталыкларын үстерүне дәвам итү, диалогик сөйләм күнекмәләрен үстерү.

3. Сорауларга тулы җавап бирүләренә ирешү, әкиятнең эчтәлеген, эзлекле итеп, үз сүзләре белән сөйләргә ярдәм итү.

**Сүзлек:** чана, төягән, бөгәрләнгән, яка, карана, бәке, көянтә.

**Җиһазлар:** төлке, бүре, бабай, әби киемнәре.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 206 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

а) Сорыдыр төсе,
Үткендер теше,
Урманда йөри,
Сарыклар эзли. (Бүре)

б) Урманнан чыгар,
Корсак асты чуар,
Койрыгы сырлы,
Хәйләсе күптөрле. (Төлке)

2. Әкият уку: «Төлке белән бүре».

3. Балаларга сораулар:

- Әкият нәрсә турында бара?
- Төлке картны ничек хәйләләгән?
- Төлке хәйләсенә тагын нәрсә эләккән?
- Бүренең койрыгы ни өчен өзелгән?
- Бүре ни өчен алданган?
- Әкият ничек тәмамлана? (Кыйналган кыйналмаганны алып бара).

4. Әкиятне сәхнәләштерү (балалар эшчәнлеге).

5. Сүзле уен «Аксак төлке».

Аксак төлке белән өй хуҗасы сайлана, башка балалар, тавыклар булып, зур түгәрәк эченә кереп басалар. Сорауларга җавап биреп уйныйлар. Аксак төлке, ялгышып, икенче аягы белән дә җиргә баса, хуҗа күреп, аның үзен куа башлый.

## Тема. Әкият уку.
## «Бүре аларны нигә ашаган?» Болгар халык әкияте

**Бурычлар:**

1. Балаларда халык авыз иҗатына уңай караш, әкият аша дуслык, бердәмлек сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның үз фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен, хәтерен үстерү.

3. Әкият эчтәлеге буенча сорауларга тулы, аңлаешлы итеп җавап бирүләренә ирешү.

**Сүзлек:** абзар, өзелеп елый, уртаклаша, бугаз, үч алу, жыйнаулашып.

**Җиһазлар:** кисмә рәсемнәр, бүре битлеге.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 156 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Такмаза әйтү:

Барыр идем урманга,
Соңга калсам, кунарга
Таба алмасам бер җир дә,
Очрап куйса бүре дә,
Куып китеп ач бүре,
Кайта алмасам кире?
Юк, мин урманга бармыйм,
Бармыйм, урында ауныйм.
Утыным бетсә бетәр.
Тиздән җәе дә җитәр.

2. Әкият уку: «Бүре аларны нигә ашаган?»

3. Балаларга сораулар.

- Бүре абзарда нишләгән?
- Елап барган сарыкка нәрсә очраган?
- Сарык кәҗәгә нәрсәләр сөйләгән?
- Кәҗә аңа ни дип әйткән?
- Сарык нинди җавап кайтарган?
- Эт сарыкка нинди ярдәм тәкъдим иткән?
- Бүре янына баргач, сарык белән нәрсә булган?
- Кәҗә белән эт нинди фаҗигага юлыккан?
- Бүре ни өчен шатланган?
- Сез ничек уйлыйсыз, бүренең сүзләрендә дөреслек бармы?
- Бу әкият нәрсәгә өйрәтә? (Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар)

4. «Бүре һәм көтү» уены:

Көтүче:

Алдым кулыма быргы,
Кычкыртам: тру-ру-ру ...
Ә шунда бер сыер
Каршы чыкты: му-му-му ...

Көтүдән (сыер, сарык, кәҗә, бозау битлекләре киеп уйнаучы балалар арасыннан) мөгри-мөгри сыер чыга.

Көтүче:

Син, сыер, кит урманга,
Хәтфә төсле кырларга,
Тик кайтырсың кич белән,
Кич белән күп сөт белән.

Терлекләр төрлесе төрле якка таралышалар. Бүре чыгып куа башлый, качып өлгерә алмаган баланы тотып ала. Ул бала бүре булып, уен дәвам итә.

5. Тасвирлау табышмаклары төзү (кыргый хайваннар турында).

## Проект. Йорт хайваннары һәм кошлары

### Тема. Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү: «Ишегалдында»

**Бурычлар:**

1. Балаларда барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү, аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү.

2. Балаларның бәйләнешле сөйләмен, бер-берсен тыңлый, башкаларның җавапларын тулылындыра алу сәләтен үстерү.

3. Рәсемнәр аша балаларның йорт хайваннары һәм кошлары турындагы күзаллауларын системалаштыру, кешенең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру.

**Сүзлек:** бозау, колын, көчек, чеби, бәбкә.

**Җиһазлар:** уенчыклар, авыл өе макеты.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмаклар.

а) «Кикрикүк!»- дип, таң белән
Йокыдан уятучы,
Ул – иң иртә торучы
Һәм иң иртә ятучы. (Әтәч)

б) Күлгә таба йөгерә,
Җиргә басып лап та лоп.
Күпләп су эчә, ашый,
«Бак-бак»,- диеп мактанып. (Үрдәк)

в) «Иһа-һа-һай»,- дип кешни,
Арба тарта, йөк ташый.
Чабышка да чыга ул,
Аннары солы ашый. (Ат)

г) Хайван рәхәткә чыккан:
Һаман җирне актара.
«Мырык-мырык» сөйләнә,
Ә борыны кап-кара. (Дуңгыз)

д) «Кыйгак-кыйгак» килә дә,
Бермәлгә уйга кала.
Исәп итеп суда йөзә,
Һәм бераз оча ала. (Каз)

е) Кешенең дусты, йортның
хуҗасы. (Эт)

2. Үстерешле диалог.

- Бу табышмаклар нәрсәләр турында?
- Ни өчен аларны йорт хайваннары һәм кошлары дибез?
- Тагын нинди йорт хайваннарын һәм кошларын беләсез?
- Алар кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар?
- Кешеләр алар турында ничек кайгырталар?
- Кешеләр аларны ни өчен асрыйлар?
- Җылы якларда яшәүче нинди йорт хайваннарын һәм кошларын беләсез?
- Нинди йорт хайваннарын һәм кошларын күргәнегез бар?

3. Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя сөйләү: «Ишегалдында».

4. Дидактик уен «Баласын әйт!» Мәсәлән: сыер – бозау, ат – колын, тавык – чеби һ.б.

## Тема. Рәсем карау. «Песи һәм песи балалары»

**Бурычлар:**

1. Балаларда бер-береңне игътибар белән бүлдермичә, сабыр гына тыңлау сыйфатлары тәрбияләү.

2. Хайваннарның һәм балаларының исемнәрен дөрес атау күнекмәләре бирү, хәрәкәтне белдерә торган сүзләрне ныгыту.

3. Эчтәлекле рәсем буенча хикәя төзергә өйрәтү.

**Сүзлек:** бөгәрләнгән, ала, йомшак.

**Җиһазлар:** «Песи һәм песи балалары» рәсеме, песи битлеге, туп, «Гав исемле мәче баласы» мультфильмы (беренче вакыйга).

## Эшчәнлек барышы

1. Тизәйткеч:

Мич башында биш мәче,
Биш мәченең биш башы.
Биш мәченең биш башына
Ишелмәсен мич ташы.

2. Рәсем карау. «Песи һәм песи балалары».

- Рәсемдә нәрсәләр күрәсез?
- Ана песи нинди?
- Рәсемдә ничә песи баласы бар?
- Песи балалары турында сөйләгез.
- Алар бер-берсеннән нәрсә белән аерыла?
- Охшашлыклары бармы?

3. Рәсем буенча хикәя төзү (5 – 6 бала сөйли).

4. Дидактик уен «Нәрсә ничек кычкыра?» (туп белән). Мәсәлән: песи, песи баласы – мыраулый; эт, көчек – өрә; ат, колын – кешни; сыер, бозау – мөгери һ.б.

5. Сүзле уен «Сүзләр ясa». [с] авазы.

Мас-мас – мырламас.
Мас-мас – җырламас.
Мас-мас – суламас.
Мас-мас – ашамас.
Мас-мас – утырмас.
Мас-мас – ятмас.
Мас-мас – йокламас.

6. Хәркәтле уен «Песи һәм тычканнар».

7. Мультфильм карау: «Гав исемле мәче баласы» (беренче вакыйга).

## Тема. Хикәянең эчтәлеген дәвам итеп сөйләү. Г.Мөхәмметшин. «Ак песи»

**Бурычлар:**

1. Балаларда игътибарлылык, ярдәмчеллек сыйфатлары тәрбияләү.
2. Балаларның иҗади күзаллауларын, фонематик ишетү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.
3. Балаларга үз тәҗрибәләренә таянып хикәя төзергә, үз

фикерләрен аңлаешлы итеп башкаларга җиткерергә ярдәм итү.

**Сүзлек:** күмәч, ут-күз, ага (абый).

**Җиһазлар:** рәсемнәр, песи битлеге, туп, «Гав исемле мәче баласы» мультфильмы (икенче вакыйга).

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 167 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку:

Әти, песи алыйк әле!
Һәммәбез карар иде.
Әгәр песи булмаса,
Мәче дә ярар иде.

2. Хикәя уку: Г.Мөхәммәтшин. «Ак песи».

3. Балаларга сораулар:

- Айдар бакчага бармый калган көн нинди булган?
- Ул көнне Айдар нәрсә очраткан?
- Айдар песигә ничек ярдәм иткән?
- Балалар Айдарның сөенечле хәбәрен ничек кабул иткәннәр?
- Сез ничек уйлыйсыз, аннан соң нәрсә булган?

4. Балалар хикәясе (4 – 6 бала хикәя сөйли).

5. Сүзле уен «Песине дәшү» (туп белән). Мәсәлән: песием, йомшагым, пескәем, аппагым, йомгагым, нәнием һ.б.

6. Мультфильм карау: «Гав исемле мәче баласы» (икенче вакыйга).

## Проект. Транспорт

### Тема. «Җир өсте, һава һәм су транспорты»

**Бурычлар:**

1. Балаларда урамда игътибарлылык һәм транспорт хезмәткәрләренә ихтирам тәрбияләү.

2. Транспорт турындагы күзаллауларын киңәйтү, фикерләү сәләтен үстерү.

3. Балаларны транспорт төрләре белән таныштыруны дәвам итү, аларның исемнәрен истә калдыру, кулланылышын белү.

**Сүзлек:** коры җир, су юлы, тимер юл, һава юлы.

**Җиһазлар:** төрле транспорт рәсемнәре, төрле транспорт йөртүчеләрнең рәсемнәре: «Тракторчы», «Машинист», «Комбайнчы», «Очучы», «Машина йөртүче».

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмаклар:

а) Кылга асылына,
Тимергә таяна,
Утыртып чаба
Теләсәң кая. (Трамвай)

б) Уф итәр, пуф итәр,
Төкеренер дә пошкырыр.
Пошкырса да алып китәр,
Акча түләсәң, илтер. (Поезд)

в) Канаты бар – йоны юк,
Үзе бара – юлы юк. (Самолёт)

2. Балаларга сораулар:

- Трамвай, поезд, самолёт – бер сүз белән ничек атыйбыз?
- Транспортны нинди төрләргә бүлергә була?
- Нинди коры җир транспортларын беләсез?
- Ни өчен алар шулай атала?
- Нинди су транспортлары була?
- Нинди һава транспортлары бар?
- Транспорт ни өчен кирәк?
- Машиналарны, эш беткәч, кая куялар?
- Автобусларны? Трамвайны?

3. «Нәрсә артык?» уены:

а) Мотоцикл, скутер, велосипед, мопед.
б) Трамвай, троллейбус, автобус.
в) Самолёт, вертолёт, поезд.
г) Теплоход, метеор, автобус.
д) Самокат, велосипед, троллейбус.
е) Комбайн, трактор, самолёт.

4. Ярышлы уен «Поезд».

Балалар ике төркемгә бүленәләр һәм старт сызыгы артына бер-бер артлы тезелеп басалар. Алар – «вагоннар». Төркем алдында – «локомотивлар». Тәрбияче сигнал биргәч, капитаннар алдан билгеләнгән урынга (флагка) таба йөгерәләр һәм аны әйләнеп узып, кире командаларына киләләр. Капитаннарга икенче булып басып торган балалар (вагоннар) ябышалар һәм икәүләшеп йөгерәләр. Уен барлык вагоннар да беркетелеп беткәнче дәвам итә. Старт сызыгына беренче булып килеп җитүче поезд җиңүче була.

5. «Рәсемгә карап бел һәм әйт» уены:

Балаларга рәсемнәр күрсәтелә, алар төрле транспорт

йөртүчеләрнең исемнәрен әйтәләр: «Тракторчы», «Машинист», «Комбайнчы», «Очучы», «Машина йөртүче».

### Тема. Чагыштырып тасвирлау хикәясе төзү. «Йөк машинасы һәм җиңел машина»

**Бурычлар:**

1. Балаларда бер-берсен бүлдермичә тыңлый белү, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның тасвирлап сөйли белү күнекмәләрен ныгыту, мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү.

3. Балаларны тәрбияче биргән план буенча чагыштырып тасвирлау хикәясе төзергә өйрәтүне дәвам итү, юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен ныгыту.

**Сүзлек:** йөк машинасы, җиңел машина.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Юлларда булсын тәртип» җыры (В.Вәлиева сүзләре һәм көе), уенчык машиналар, өч төсле түгәрәкләр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмаклар:

а) Тәгәрмәчләр өстендә
Зур гына арбасы бар.
Арбаның эченә салып,
Бик күп йөкләр ташыйлар.
(Йөк машинасы)

б) Очмый, жуылдамый да,
Ул урам буйлап чаба.
Аның ике күзендә дә,
Яктырып утлар яна.
(Җиңел машина)

2. Фикер алышу:

- Машиналар нинди төрләргә бүленә?
- Йөк машинасы нәрсә өчен кирәк?
- Йөк машинасының кузовына утырып йөреп буламы?
- Безгә җиңел машиналар ни өчен кирәк?
- Сез җиңел машиналарның нинди маркаларын беләсез?

3. Йөк машинасы һәм җиңел машина уенчыкларын аерым-аерым карау:

- Бу нәрсә?
- Нинди өлешләрдән тора?
- Нәрсәдән ясалган?

- Ни өчен кирәк?

4. Чагыштырма тасвирлау хикәясе төзү.

Үрнәк: Бу – җиңел машина, ә бу – йөк машинасы. Җиңел машинаның ак кабинасы, дүрт кечкенә алтынсу тәгәрмәчләре, пластмасстан ясалган утыргычлары бар. Ә йөк машинасының әрҗәсе тимердән, руле пластмасстан ясалган, дүрт зур кара тәгәрмәче бар. Җиңел машинаның кабинасы пластмасстан эшләнгән, тәрәзәләре пыяла, ә йөк машинасының кабинасы тимер, тәрәзәләре шулай ук пыяладан ясалган. Йөк машинасы йөк ташыр өчен, ә җиңел машина кешеләрне йөртер өчен кирәк.

5. Балалар эшчәнлеге (5 – 6 бала сөйли).

6. Хәрәкәтле уен «Машиналар һәм җәяүлеләр».

Балалар машиналар һәм җәяүлеләргә бүленәләр. Тәрбияче кулында төсле түгәрәкләр светофор ролен үти. Светофор машиналарга һәм җәяүлеләргә аерым сигналлар бирә.

7. Җыр тыңлау: «Юлларда булсын тәртип» (В.Вәлиева сүзләре һәм көе).

### Тема. Хикәя уку: И.Дәүләтшин. «Алпамыш шәһәргә килде»

**Бурычлар:**

1. Юлда үз иминлеген һәм башкаларның иминлеген кайгырту һәм саклау сыйфаты тәрбияләү.
2. Балаларның игътибарлылыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү.
3. Матур әдәбият аша балаларның юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү һәм ныгыту.

**Сүзлек:** тротуар, чат, бина.

**Җиһазлар:** рәсем һәм схемалар, төсле түгәрәкләр, туп.

**Матур әдәбият:** Р.Р.Газизов. «Балалар бакчасы», 537 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. «Ми чарлау» уены (туп белән).

- Җәмәгать транспортлары – … .
- Юл хәрәкәтендә катнашучылар – … .
- Җәяүле юлны кайдан чыга?
- Тротуар нәрсә өчен хезмәт итә?

- Нинди юлны аркылы чыгарга җиңелрәк: киңнеме, әллә тарнымы?
- Светофорның ничә сигналы бар?
- Транспортка утыргач, сез кем буласыз?
- Тимер юлдан йөри торган транспорт төрләре – … .
- Йөк машинасы һәм поездның кайсына йөк күбрәк сыя?

2. Хикәя уку: И.Дәүләтшин. «Алпамыш шәһәргә килде».

3. Хикәя буенча әңгәмә.

- Алпамыш шәһәрдә кем белән очраша?
- Дусты аңа нинди кагыйдәне өйрәтә?
- Машиналарның кайчан кузгалып китәсен каян белгәннәр?
- Алпамыш юлдагы ак сызыклар турында нәрсә белгән?
- Алпамыш нинди төр транспортлар белән танышкан?
- Ни өчен трамвайның артыннан чыгарга ярамый?
- Троллейбус белән автобусны кайсы яктан урап үтәләр?
- Сез бу кагыйдәләрне үтисезме?

4. Хәрәкәтле уен «Күңелле светофор».

Балалар, тәрбияче күрсәткән төсләргә туры китереп, хәрәкәт итәләр.

5. Үстерешле уен «Кагыйдәне бел!»

Тәрбияче рәсем һәм схемалар күрсәтә, балалар кагыйдәне әйтәләр.

## Проект. Юл йөрү кагыйдәләре

### Тема. «Машина йөртүче һәм җәяүлене кисәтүче куркынычсызлык билгеләре»

**Бурычлар:**

1. Балаларда урамда, җәмәгать транспортында, торак зонасында үз-үзеңне тоту культурасын тәрбияләү.
2. Юлларда күзәтүчәнлекне, фикерләү мөстәкыйльлеген, игътибарлылыкны үстерү.
3. Юл билгеләрен аера белү, юлда хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәнүне дәвам итү.

**Сүзлек:** тыючы, боеручы, мәгълүмат бирүче, кисәтүче, хезмәт күрсәтү.

**Җиһазлар:** урам макеты, юл билгеләре, рәсемнәр, руль.

## Эшчәнлек барышы

1. Тизәйткеч. [з] авазы.

Озын-озын, озын юл,
Озын юлга чыкты ул.
Озын юлда озак йөреп,
Очына барып чыкты ул.

2. Мәкаль:

Юлда булсаң, уяу йөр.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

3. Үстерешле диалог.

- Син нинди очракта пассажир буласың?
- Урамга чыккач та сез кемгә әвереләсез? (Җәяүле)
- Юл хәрәкәтендә нинди яхшы ярдәмчеләр бар?
- Нинди дә булса транспорт чарасын идарә итүчене кем дип йөртәләр?

4. Урам макетын карау:

- Бу юлда хәрәкәт ничә юнәлешле?
- Светофорның нинди сигналларын беләсең һәм алар нәрсә аңлата?
- Урам үз эченә нәрсәләрне ала?
- Җәяүле нинди юлдан һәм кайсы яктан йөри?
- Монда нинди юл билгеләре бар?

5. Дидактик уен «Юл билгесен дөрес куй!»

а) Велосипедларда йөрү тыела – Тыючы.
б) Җәяүле юлы – Боеручы.
в) Тукталыш урыны – Мәгълүмат бирүче.
г) Җәяүлеләр юл аркылы чыгу урыны – Кисәтүче.
д) Беренче медицина ярдәме пункты, туклану пункты – Хезмәт күрсәтү билгеләре.

6. Җырлы-сүзле уен (балалар сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар, юлда очраган (тәрбияче күрсәткән) юл билгеләрен әйтеп баралар).

Автобуска утырдык,
Сәяхәткә җыендык.
Би-би-би, би-би-би!
Сәяхәткә җыендык.

Барабыз урам аша,
Безгә кояш елмая.
Би-би-би, би-би-би!
Безгә кояш елмая.

## Тема. Әңгәмә. «Велосипед – минем дустым»

**Бурычлар:**

1. Балаларда юлда үз-үзеңне тоту культурасын тәрбияләү.
2. Бирелгән мәгълүматны тыңлый белү һәм үзләштерүне формалаштыру, мөстәкыйль фикер йөртә белү, коммуникатив сәләтләрен үстерү.
3. Велосипедта хәвефсез йөрү кагыйдәләрен өйрәтү.

**Сүзлек:** велошлем, терсәкчә, руль, утыргыч, чылбыр, багажник.

**Җиһазлар:** юл билгеләре, велосипедның өлешләре төшерелгән рәсемнәр, шәһәр макеты, велосипед.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 414 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Руль, утыргыч, ике педаль,
Ялтыравык ике тәгәрмәч.
Ә хәзер җавабын көт:
Ул минем ... (Велосипед)

2. Шигырь уку: К.Низамиева. «Велосипедыңа өйрәт».

3. Әңгәмә: «Велосипед – минем дустым».

- Нинди велосипедларны беләсез?
- «Кама», «Аист», «Салют» һ.б. маркалы велосипедларны беләсезме?
- Велосипедчылар нинди кагыйдәләрне белергә тиеш?
- Велосипедчы нинди махсус киемнәр кия?
- Хәрәкәт башланыр алдыннан велосипедның нәрсәләрен тикшерергә кирәк?
- Велосипед йөртүчегә нәрсәләр тыела?

4. Дидактик уен «Велосипедыңны җый!»

Балаларга велосипед өлешләре төшерелгән рәсемнәр бирелә, алардан велосипед җыела: рам, тәгәрмәчләр, руль, педаль, утыргыч.

5. Макетта эш (велосипедта хәвеф-хәтәрсез йөри торган урыннарны билгеләү).

**Тема. Шигырь ятлау: Ш.Галиев. «Светофорның өч күзе»**

**Бурычлар:**

1. Балаларда урамда, юлда үз-үзләрен дөрес тоту, бер-берсенә игътибарлы булу, сабырлык сыйфатлары тәрбияләү.

2. Шигырь аша светофор турындагы белемнәрен ныгыту, хәтер сәләтен үстерү.

3. Шигырьне яттан сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү; милиционер-регулировщик турында кыскача белем бирү.

**Сүзлек:** ваемсыз, кисәтү, чат, сакта, ич, кузгалма, сабыр, дия.

**Җиһазлар:** яшел, кызыл, сары төстәге түгәрәкләр, «Милиционер-регулировщик» рәсеме.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 413 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак.

Җәен, кышын, язын, көзен,
Иртән, кичен, көндезен
Ача-йома өч күзен,
Телсез әйтәдер сүзен –
Бик тиз аңлыйлар үзен.
Бу нәрсә? (Светофор)

2. Шигырь уку: Ш.Галиев. «Светофорның өч күзе».

3. Шигырь буенча әңгәмә:

- Урам чатында нәрсә тора?
- Светофор нинди хезмәт башкара?
- Нинди өч сүзне әйтеп тора?
- Кызыл күз, сары күз, яшел күз нәрсә ди?

4. Шигырьне яттан сөйләү (4 – 5 бала сөйли).

5. Рәсем карау: «Милиционер-регулировщик».

Тәрбияче хикәясе: Юлларда иминлекне саклаучы юл билгеләре, светофор бик әһәмиятле. Юл иминлеген тәэмин итүче бер мөһим кеше бар. Ул – милиционер-регулировщик. Аның кулында жезл була. Ул шул жезлы ярдәмендә юл хәрәкәте белән идарә итә. Светофор булмаган юл чатларында яисә светофорлар ватылган очракта юлчыларга милиционер-регулировщиклар ярдәмгә килә.

6. Уен «Светофор».

Тәрбияче яшел төсле түгәрәк күтәрсә, балалар алга баралар.

Сары төс күтәргәндә – бер урында атлап торалар, кызыл төскә – бер-берләренә бармак яныйлар.

## Проект. Хезмәт төбе – хәзинә

### Тема. Төзелеш булган җиргә сәяхәт яки рәсем карау. «Хезмәткә хөрмәт»

**Бурычлар:**

1. Балаларда хезмәт кешесенә, төзүче һөнәренә хөрмәт тәрбияләү.
2. Бәйләнешле сөйләм һәм танып белү эшчәнлеген үстерү.
3. Балаларның өлкәннәр хезмәте турында күзаллауларын киңәйтү, төзүчеләр хезмәте белән таныштыру.

**Сүзлек:** һөнәрләр, штукатурчы, ташчы, буяучы.

**Җиһазлар:** слайдлар, рәсемнәр, туп.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырьне кабатлап уку: Ә.Ерикәй. «Әти йорт төзи».

Минем әти – төзүче,
Ул сала биек йортлар.
Ул салган биек йортларда,
Балкып торалар утлар.

Минем әти кирпеч түши,
Нык итеп, тигез итеп.
Матурлап, сырлап, шомартып,
Турылап, тигез итеп.

2. Балаларга сораулар.

- Кем биек-биек йортлар төзи?
- Йортның стеналарын кирпеч белән кем өя?
- Стенаны измә белән кем сылый, тигезли, шомарта?
- Балта остасы нәрсә эшли?
- Тәрәзә рамнарын кем буйый?

3. Йорт төзүчеләр турында слайдлар, рәсемнәр карау (тәрбияче хикәясе).

4. Туплы уен:

- Ышкы кемнеке?
- Пумала кемнеке?
- Измә кемнеке?

5. Мәкальләр:

а) Хезмәт кешене бизи.
б) Кем эшләми – шул ашамый.
в) Эшләп ашасаң, тәмле булыр.
г) Хезмәт кешесе хөрмәткә лаек.
д) Хезмәт иясе – хөрмәт иясе.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

6. Сүзле-хәрәкәтле уен «Эшләсәң эш табыла». [ш] авазы (балалар сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар).

Оста иртән үк эшкә кереште,
Эш кораллары юксынган эшне.
Сөенде ышкы (эш-эш-эш),
Шатланды пычкы (ты-рыш, ты-рыш),
Очынды чүкеч (шап-шап-шап),
Талпынды балта (шалт-шалт).

## Тема. Әңгәмә. «Кем булырга?»

**Бурычлар:**

1. Хезмәт кешесенә хөрмәт тәрбияләү.
2. Балаларның фикер йөртә белү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү.
3. Өлкәннәр хезмәте, аларның һөнәрләре турында балаларның белемнәрен киңәйтү, алар хезмәтенең мөһимлеген аңлату.

**Сүзлек:** янгын сүндерүчеләр, табиб, хезмәт иясе, һөнәр.

**Җиһазлар:** һөнәр ияләре күрсәтелгән рәсемнәр: «Төзүче», «Сатучы» һ.б., аудиоязмада «Кәрия-Зәкәрия» көе.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль: Эш – кешенең көзгесе.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Әңгәмә:

- Сез нинди һөнәрләрне беләсез?
- Әти-әниләрегез нинди һөнәр ияләре?
- Эшчән кешегә нинди сыйфатлар хас?
- Хезмәт яратмаган кешене нинди диләр?
- Нинди һөнәр иң кирәклесе дип уйлыйсыз, ни өчен?
- Зур үскәч, синең кем буласың килә?
- Сез һөнәрләр турында нинди мәкальләр беләсез?
- Сез ничек уйлыйсыз, үз һөнәренең остасы булу өчен нишләргә кирәк?

3. «Тапкырларга – табышмак» (табышмакларга туры килгән рәсемнәр күрсәтелә).

а) Шәһәр, авыл йоклый әле.
Без бик иртә торабыз.
Иләк биетеп, он илибез,
Һәм мичне кыздырабыз.
Ипекәй һәр иртәдә
Килсен өчен өстәлгә.(Ипи пешерүче)

б) Ул сала биек йортлар.
Ул салган биек йортларда
Балкып кабына утлар.
Кем икән ул, балалар? (Төзүче)

в) Янып торган чәчкә ясап
Өйләрне матурлаучы.
Кем икән соң ул, балалар?
Ул әлбәттә ... (буяучы)

г) Ул эшли зур кибеттә,
Конфет-прәннек сата.
Я, әйтегез кем беләә?
Ул бит ... (сатучы апа)

д) Ул теккән матур киемне
Барлык кешеләр кия.
Үз эшен бик тә сөюче,
Ул буладыр ... (тегүче)

4. Бармак уены «Һөнәрләр».
Баш бармагым – биюче,
Имән бармак – тегүче,
Урта бармак – төзүче.
Атсыз бармагым – укытучы,
Чәнти бармак кем була?
Читек чигүче була.

5. Дидактик уен «Парын тап».

Һөнәр ияләре төшерелгән рәсемнәр һәм эш кораллары төшерелгән вак рәсемнәр бирелә. Балалар дөрес итеп эш коралларын урнаштыралар.

6. Җырлы уен. «Кәрия-Зәкәрия» көенә.

Бу бик яхшы тегүче,
Бу бик яхшы тегүче.
Аның күлмәге матур,
Аннан үрнәк алыгыз.

Бу бик яхшы очучы,
Бу бик яхшы очучы.
Ул бик булган һәм кыю,
Аннан үрнәк алыгыз һ.б.

**Тема. Хикәя уку: К.Ушинский. «Иртәнге нурлар»**

**Бурычлар:**

1. Матур әдәбият аша балаларда хезмәткә уңай сыйфатлар, ялкаулыкка тискәре караш тәрбияләү.
2. Балаларның хәтерен, игътибарын, сөйләм күнекмәләрен үстерү.
3. Әсәрнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен башкаларга аңлаешлы итеп җиткерә белергә өйрәтү.

**Сүзлек:** пырхылдап, өздереп, сусыл үлән, кунача, кәрәз.
**Җиһазлар:** әсәрнең эчтәлегенә туры килгән рәсемнәр.
**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 175 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Тел шомарткыч. [ш] авазы.
Үз ишен ише көтә,
Эшлене эше көтә.
2. Хикәя уку: К.Ушинский. «Иртәнге нурлар».
3. Балаларга сораулар:
- Кояшның беренче нуры кайда төште?
- Тургай ничек итеп сөенечен белдерде?
- Икенче нур төшкәч, куянкай нишләде?
- Өченче нурга әтәч белән тавыклар ничек куандылар?
- Дүртенче нур бал кортына ничек тәэсир итте?
- Бишенче нур үзенә төшкәч, ялкау нишләде?
- Бу балага сез нәрсә әйтер идегез?
- Ә сез нинди эшләр башкарасыз?
4. Сүзле-хәрәкәтле уен «Без инде хәзер зурлар».

Без инде хәзер зурлар.
Күп эшли безнең куллар.
Без чокыр да казыйбыз,
Без кирпеч тә өябез,

Без түшәм дә җәябез,
Без түбә дә ябабыз,
Тәрәзәләр куябыз
Һәм ишектән керәбез.

5. Тизәйткеч ятлау:

Ишми, Ишми,
Мич башыннан төшми.

Мич башыннан төшми, –
Ничек тәне пешми.

# Проект. Кунак булсаң, тыйнак бул
## Тема. Әңгәмә. «Сүз эчендә энҗе бар»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кунаклар белән аралашу, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту, кешеләргә ихтирам тәрбияләү.
2. Бәйләнешле сөйләм һәм мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү.
3. Кунакларга хөрмәт күрсәтү кагыйдәләрен бирү.

**Сүзлек:** гадәт, әдәп, якты чырай.

**Җиһазлар:** эчтәлекле уен өчен кирәк-яраклар, кулъяулык.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку: Э.Мөэминова. «Чакыру».

Безнең халык кунакчыл:
«Якты чырай, такта чәй»,- дип,
Каршы ала кунакны.
Ата-баба гадәтләрен
Без дә дәвам итәбез.
Безгә кунакка килегез –
Чын күңелдән көтәбез.

2. Халык юрамалары:

а) Мендәр ишелсә, кунак килә.

б) Самавыр җырласа, кунак чакыра.

в) Мәче битен юса, кунак көт.

3. Мәкаль: Кунак булсаң, тыйнак бул!

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

4. Балаларга сораулар:

- Сез кунакка йөрергә яратасызмы?
- Әдәпле, тыйнак кунак нинди була?
- Ямьсез гадәтләр нindиләр алар?
- Кунакта кеше үзен ничек тотарга тиеш?

5. Такмаза «Сәлам кайтарышы»:

Әй, Әпсәләм, Әпсәләм,
Сәлам бирдем: – Әпсәләм!
Синнән безгә тиештер бит:
– Вәгаләйкемәссәләм.

6. Уен «Кулъяулык алыш».

Балалар түгәрәккә басалар. Кулына кулъяулык алган бала кунакка әйтелә торган матур сүзләрне әйтә. Мәсәлән: килүегез өчен рәхмәт, гаеп итеп китмәгез һ.б.

7. Сюжетлы-рольле уен «Гаилә» (кунакка чакырышып уйнау).

**Тема. Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Табын кагыйдәләре»**

**Бурычлар:**

1. Балаларда кунакта үз-үзен тота белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның хәтер сәләтен, игътибарлылыгын, матур әдәбият әсәрләренә, халык авыз иҗатына карата кызыксынучан-

лыкларын үстерү.

3. Шигырь эчтәлеге буенча тәрбияченең биргән сорауларына тулы җавап бирергә, үз фикерләрен дөрес итеп башкаларга җиткерә белергә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** җыйнак, кунак, уймак, чынаяк.

**Җиһазлар:** табын кагыйдәләрен эченә алган төрле-төрле сюжетлы рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** З.М.Зарипова, И.М.Хәмитов. «Бал бабай», 72 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Тел төзәткеч.

Нак-нак-нак – мин бүген кунак.
Нак-нак-нак – мин булам кунак.
Нак-нак-нак – бу минем чынаяк.

2. Әйтем: Тыйнаклык кешене бизи.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

3. Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Табын кагыйдәләре».

4. Әңгәмә:

- Кунак нинди булырга тиеш?
- Тыйнак кунак – ул нинди була?
- Табын янында ризыкны ничек ашарга кирәк?
- Авызны чапылдатып ашау матурмы?
- Табын янында дөрес утырган бала турында ни диләр?
- Ашар алдыннан нинди матур сүз әйтәбез?

5. «Дөресен әйт!» уены (табын кагыйдәләрен эченә алган төрле-төрле сюжетлы рәсемнәр белән).

6. Бармак уены:

Бер бермәк,
Ике икмәк.
Өч өчмәк,
Дүрт дүртмәк.
Биш биштәт,
Алты атмак.
Җиде җитмәк,
Сигез сипмәк.
Тугыз тукмак,
Ун уймак.
Таба тулы коймак.

7. Такмаза:

Рәхмәт, сыйладыгыз,
Көн дә шулай кыланыгыз.
Баегыз, тегермән салыгыз,
Онны сатып алыгыз.

## Проект. Россия – зур дәүләт

### Тема. «Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел!»

**Бурычлар:**

1. Балаларда туган илне ярату, башка милләт вәкилләренә карата хөрмәт тәрбияләү.

2. Балаларның хәтерен, логик фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен, кызыксынучанлыкларын үстерү.

3. Балаларның Россия башкаласы Мәскәү турындагы белемнәрен баету, Россия символикасы турында мәгълүмат бирү.

**Сүзлек:** әләм, тугра, бөркет, калкан.

**Җиһазлар:** слайдлар, рәсемнәр, символика, уен өчен рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку: Ш.Маннур. «Яхшы бел!»

Татарча да яхшы бел,
Русча да яхшы бел.
Икесе дә – безнең өчен,
Иң кирәкле затлы тел.
Татарчасы – туган тел,
Безгә газиз булган тел.
Атаң-анаң, әби-бабаң
Сине сөя торган тел.
Тел кешене дус итә,
Бер-берсенә беркетә.
Бел, балам, син рус телен
Һәм онытма үз телең!

2. Үстерешле диалог.

- «Туган тел» дип нинди телне атыйлар?
- Безгә рус телен белү ни өчен кирәк?
- Татарстан нинди җирдә урнашкан? (Россиянең матур җирендә...)
- Аның башкаласы нинди шәһәр?
- Россиянең башкаласы нинди шәһәр?

3. «Мәскәүгә сәяхәт» уены (слайдлар, рәсемнәр белән).

Танылган урыннар төшерелгән рәсемнәр карала. Алар турында кыскача мәгълүмат бирелә. Мәсәлән: Кремльдә Президентыбыз эшли, анда гыйбадәтханәләр бар. Кызыл Мәйданда зур бәйрәмнәр, Җиңү парады үтә, мәңгелек ут яна һ.б.

4. Россия символикасы белән танышу:

- Әләм һәм тugраны кайда очратырга мөмкин?

- Анда нинди төсләрне күрергә була?
- Бу төсләр нәрсәне аңлата?
- Тугра формасы буенча нәрсәне хәтерләтә?
- Анда нинди кош сурәтләнгән?
- Ни өчен аның башы икәү? (Ул зур илебезне саклый, уяу тора)

5. Үстерешле уеннар: «Дөрес итеп тез!» (төсле тасмалардан Татарстан һәм Россия әләмен тезү), «Тугрананы җый» (аерым рәсемнәрне бер-берсенә куеп, Татарстан һәм Россия туграсын җыю).

## Тема. Әңгәмә. «Теле барның – иле бар»

**Бурычлар:**

1. Балаларда туган телебезне ярату, зурлау, аңа соклану хисләре тәрбияләү.
2. Халык авыз иҗаты аша балаларның сөйләмен үстерү.
3. Мәкаль-әйтемнәрдәге төп фикерне аңларга, җырлаганда сүзләрне ачык итеп җырларга өйрәтү.

**Сүзлек:** татлы тел, кадерләгән, күңел түрем.

**Җиһазлар:** магнитофон, аудиоязмада «Туган тел» җыры.

### Эшчәнлек барышы

1. Җыр җырлау: Г.Тукай. «Туган тел».
2. Шигырь уку: Ф.Яруллин. «Анам теле».

Татар теле – анам теле,
Иң беренче бабам теле.
Буыннардан-буыннарга
Күчеп килгән заман теле.

Анам теле – телләр теле,
Милләтемнең бердәнбере.
Син булганга без дә исән,
Син булганга без дә тере.

3. Балаларга сораулар.

- Татар теле турында нәрсә әйтергә була? (Бабаларыбыз сөйләшкән борынгы тел)
- Татар телен тагын ничек әйтергә була? (Туган тел, ана теле)
- Ни өчен туган телне ана теле диләр?
- Син булганга без дә исән дигәнне сез ничек аңлыйсыз?
- Туган телебез нинди? (матур, бай, моңлы-җырлы һ.б.)

4. Мәкаль, әйтемнәр:

а) Теле татлының дусты күп.
б) Туган телен кадерләгән халык кадерле булыр.
в) Туган телем – иркә гөлем.
Киңдер сиңа күңел түрем.
г) Иң татлы тел – туган тел,
Анам сөйләп торган тел.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

5. Тәрбияче хикәясе.

«Балам»,- диеп туган телдә
Эндәшә миңа әткәм.
«Әнием»,- дип әниемә
Мин туган телдә дәшәм.

Балаларның үз туган телләрендә эти-әниләре белән сөйләшүе – аларга рәхәт, күңелле, җан җылысы бирә. Үзенең эти-әнисен, туган илен яраткан кеше туган телен дә ярата, хөрмәт итә. Без дә үзебезнең туган телебезне, татар телен сакларга, аның белән горурланып яшәргә тиешбез. Безнең республикабыз – күпмилләтле. Татарстанда татарлар, руслар, марилар, чувашлар, удмуртлар, башкортлар һәм башка милләт вәкилләре яши. Аларның һәрберсенең үз туган теле бар. Алар да үз туган телләрендә аралашалар, үзләренең милли йолаларын үтиләр.

## Проект. Батырлыкта – матурлык

### Тема. «Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кыю, батыр солдат булу теләге уяту; этиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү.
2. Ватанны саклаучылар турындагы күзаллауларын киңәйтү; бәйләнешле сөйләм үстерү.
3. Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар турында белем бирү, аларның мөһимлеген аңлату.

**Сүзлек:** пехотачы, танкист, диңгезче, очучы, артиллерия, чик сакчылары.

**Җиһазлар:** слайдлар, рәсемнәр, таякчыклар.

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: К.Булатова. «Солдатлар».

Бабай да солдат булган,
Әти дә солдат булган.
Зур абый да, солдат булып,
Ил чикләрендә торган.

Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына.
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим әле аз гына.

2. Үстерешле диалог.

- Ватанны кемнәр саклый?

- Алар Ватанны кемнән саклыйлар?

- Хәрбиләрнең нинди төрләрен беләсез?

- Сезнең әтиләрегез, абыйларыгыз армиядә кем булып хезмәт иткәннәр?

- Малайлар, зур булгач, кайда хезмәт итәсегез килә?

- Сез ничек уйлыйсыз, хәрбиләр нинди булалар?

3. Тәрбияче хикәясе (хикәя рәсемнәр ярдәмендә).

Безнең илебез зур һәм бик матур. Анда төрле-төрле милләт вәкилләре яши. Илебезнең чикләре дә бик зур. Халкыбыз тыныч яшәсен өчен, аның чикләрен җирдән дә, судан да, һавадан да сакларга кирәк. Хәрбиләрнең җирне, күкне, диңгезне саклаучы төрләре була. Аларны без киемнәреннән, погоннарыннан, эмблемаларыннан (билгеләреннән) һәм корал төрләренә карап аера алабыз. Хәрбиләрнең уртак бер билгесе дә бар. Алар барысы да бик кыюлар ...

4. «Әйе – юк» уены.

- Самолётны кем йөртә, матросмы?

- Самолётны кем йөртә, очучымы?

- Корабльне кем йөртә, очучымы?

- Корабльне кем йөртә, матросмы?

- Танкны кем йөртә, матросмы?

- Танкны кем йөртә, танкистмы?

- Чикләрне кем саклый, матросмы?

5. Мәкальләр, әйтемнәр:

а) Ватанга хезмәт – үзеңә хезмәт.

б) Ил тыныч булса – без дә тыныч.

в) Илдә яшисең икән – илеңә хезмәт ит.

г) Батыр егет – ил күрке.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

6. Дидактик уен «Таякчыклардан төзе» (танк, ракета, корабль, самолёт һ.б.).

### Тема. Шигырь уку: Җ.Дәрзаман. «Солдат булдым»

**Бурычлар:**

1. Илебезнең тынычлыгын саклаучы солдатларга карата патриотик хисләр тәрбияләү.

2. Балаларның хәтерен, диалогик сөйләмнәрен үстерү.

3. Шигырь эчтәлеге буенча сорауларга төгәл, кабатланмыйча, аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтү.

**Сүзлек:** кыю, батыр, тугры, төгәл, җаваплы, түземле, чыдамлы.

**Җиһазлар:** солдатлар тормышыннан эпизодлар төшерелгән слайдлар.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 117 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку: Җ.Дәрзаман. «Солдат булдым».

2. Балаларга сораулар:

- Малай биленә нәрсә буган? Җиңенә нәрсә таккан?
- Йолдызлы бүрек кигәч, ул үзен кем итеп хис иткән?
- Ул ни өчән әтисе каршына килгән?
- Әтисеннән нинди фәрман алган?
- Ялкаулыгы ни өчен беткән?
- Малай ничек үзгәргән?
- Аны нинди гамәлләр «солдат» иткән?

3. Солдат тормышыннан эпизодлар (слайдлар) карау. «Солдатның бер көне».

4. Тизәйткеч. [h] авазы.

Һәммә ялкау гамәлсез,
Һәм һөнәрсез, һәм гамьсез.

5. Җырлы-сүзле уен «Күрсәт әле, үскәнем» (солдатлар тормышы буенча).

## Проект. Заманча әкиятләр

### Тема. «Винни-Пух кунакка бара» – минем яраткан мультфильмым»

**Бурычлар:**

1. Балаларда башкаларның фикерләрен бүлдермичә тыңлый

белү, дөрес итеп аралаша белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның иҗади сөйләмен, үз тәҗрибәсеннән чыгып сөйли белү күнекмәләрен үстерү.

3. Заманча мультфильмнарны таный белергә, аларның эчтәлеге буенча үз фикерләрен башкаларга җиткерә белергә өйрәтү.

**Сүзлек:** кунакчыл, тыйнак.

**Җиһазлар:** төрле мультфильм рәсемнәре, «Винни-пух кунакка бара» мультфильмы.

**Эшчәнлек барышы**

1. Мультфильм карау. «Винни-пух кунакка бара».

2. Фикер алышу.

- Бу мультфильмда нинди геройлар бар?
- Сезгә кайсы герой бик ошады, ни өчен?
- Винни-пухның сезгә ошамаган (ошаган) яклары бармы, ни өчен?
- Сез кайсы геройга «кунакка бару кагыйдәсен» аңлатыр идегез, ни өчен?
- Төймәборынга нинди киңәш бирер идегез?
- Куян нинди халәттә калган?

3. «Маҗаралар сөйләү».

- Кунакка йөрергә яратасызмы, ни өчен?
- Кунакка баргач нинди кызыклы хәлләр булганы бар?
- Сезгә нинди мультфильмнар ошый? Ни өчен?

4. Мәкаль: Күңелсездән көлке чыкмас.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

5. Дидактик уен «Бу нинди мультфильмнан?»

Балалар рәсемнәргә карап, заманча мультфильмнарны таныйлар, исемнәрен әйтәләр. Мультфильм геройларына, аларның эшләренә карата үз бәяләмәләрен бирәләр.

## Проект. Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!

### Тема. Әңгәмә. «Әни кирәк»

**Бурычлар:**

1. Балаларда әниләргә карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү.

2. Балаларның логик фикерләү сәләтләрен, әниләргә карата игътибарлылыкларын үстерү.

3. Сорау – җавап тибында аралашу аша баланы, үз белемнәренә таянып, фикер йөртергә, гомумиләштерергә, аерып карарга һәм берләштерергә өйрәтү.

**Сүзлек:** яклау, үлчи, шәфкать.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Әни кирәк» җыры (Р.Миңнуллин сүзләре, М.Шәмсетдинова көе), рәсемнәр, таҗлары аерыла торган чәчәк, магнитлы такта.

**Эшчәнлек барышы**

1. Мәкаль: Ана – шәфкать диңгезе.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Җыр тыңлау: «Әни кирәк» (Р.Миңнуллин сүзләре, М.Шәмсетдинова көе).

3. Фикер алышу.

- Көннәр якты булсын өчен кем кирәк?
- Йокы татлы булсын өчен кем кирәк?
- Җил-яңгырдан саклар өчен, усаллардан яклар өчен кем кирәк?
- Ашлар тәмле булсын өчен, дөнья ямьле булсын өчен кем кирәк?
- Гөлләр чәчәк атсын өчен, бәхет-шатлык артсын өчен кем кирәк?
- Иң кадерле кеше җирдә кем, димәк?

4. Дидактик уен «Кемнең әнисе кайда эшли?» (магнитлы такта ярдәмендә).

Балалар рәсемнәр буенча һөнәр ияләрен билгелиләр. Мәсәлән: тегү машинасы рәсеме – тегүче; ризыклар, савыт-саба рәсемнәре – пешекче һ.б.

5. Санамыш. [ч] авазы.

Әлчи-бәлчи,
Әни миңа күлмәк үлчи.
Үлчи торгач, җитмәде,
Кисә торгач, бетмәде.
Чәүкә, чыпчык,
Син кал, бу чык.

6. «Әнием – алтыным» уены (таҗлары аерыла торган чәчәк ярдәмендә).

Балалар, әниләргә карата матур сүзләр әйтә-әйтә, алдан әзерләп куелган чәчәкнең таҗын җыялар. Мәсәлән: матурым, кояшым, күз нурым һ.б.

### Тема. Шигырь ятлау: Н.Гайсин. «Әни гөлләре»

**Бурычлар:**

1. Балаларда шигырьнең тылсымлы юллары аша әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү.

2. Шигырьгә кызыксыну уяту, ятлау теләге тудыру; игътибарлылыкларын, хәтер сәләтен үстерү.

3. Авазларны, сүзләрне ачык әйтеп, сәнгатьле сөйләргә өйрәтү.

**Сүзлек:** кулъяулык, талчыбык.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Әнкәм гөле» җыры (В.Агапов сүзләре һәм көе), рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 144 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:
Күңелсезгә – юаныч,
Күңеллегә – куаныч. (Җыр)
2. Җыр тыңлау. «Әнкәм гөле» (В.Агапов сүзләре һәм көе).
3. Фикер алышу.
- Җыр сезгә ничек тәэсир итте?
- Ни өчен бик моңсу булды?
- Сезнең өйдә гөлләр бармы?
- Ул гөлләрне кем үстерә?
- Гөлләр ни өчен кирәк дип уйлыйсыз?
4. Шигырь уку: Н.Гайсин. «Әни гөлләре».
5. Балаларга сораулар:
- Әни нәрсә утыртты?
- Гөлләр өйгә нинди үзгәреш керттеләр?
- Әниемә ничек булышам?
- Хуш исле нәфис гөлләр ничек үсәр?
6. Шигырьне яттан сөйләү (5 – 6 бала сөйли).

7. Лото-табышмаклар (бүлмә гөлләре турында).

Тәрбияче табышмаклар әйтә. Балалар шул табышмакларның җавапларын рәсем ярдәмендә күрсәтәләр һәм әйтәләр. Мәсәлән:

Исемнәре бер үк төрле,
Холыклары төрле-төрле:
Берсе тышта тып-тып тама,
Берсе өйдә тып-тын тора. (Тамчы һәм тамчы гөл)

## Проект. Без язны яратабыз

### Тема. Балалар бакчасы тирәли максатчыл күзәтү

**Бурычлар:**

1. Туган ягыбызда була торган язгы табигать күренешләренә соклану хисләре тәрбияләү.
2. Балаларның күзаллау, фикерләү, акыл сәләтен үстерү.
3. Максатчыл күзәтү аша балаларны язгы табигать күренеше белән таныштыру.

**Сүзлек:** саба җиле, йомшак җил, гөрләвек, каурый, бүртте, ләйсән яңгыр.

Эшчәнлек табигатьтә уза.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырьне әйтеп бетер!

Елгада бозлар кузгалды,
Елмая, көлә кояш.
Урамнар буйлап атлады
Ямьле һәм күңелле ... (Яз)

2. Балаларга сораулар:

- Тирә-юнь ничек үзгәрә?
- Яз көне һава торышы нинди була?
- Табигатьтә нинди үзгәрешләр барлыкка килә?
- Агачлар язны ничек каршылыйлар?
- Яз көне кояш нинди була?
- Яз көне җир өстеннән аккан су ничек атала?
- Яз көне беренче булып нинди кошлар кайта?
- Сыерчыкларны ничек каршы алабыз?

- Безнең уен мәйданчыгына яз нинди үзгәрешләр кертте?

3. Тәрбияче хикәясе:

Кояш күктә җылы нурларын сибә. Зәңгәр күктә каурый-каурый болытлар йөзә. Саба җилләре исеп китә. Җылы яклардан кошлар очып кайта. Агачларда бөреләр уянып бүртә. Җир өстеннән җырлый-җырлый гөрләвекләр йөгерә. Язның иң беренче яңгыры – ләйсән яңгыр явып үтә.

4. Ай исемнәренә эпитетлар туплау:

Март – тамчыбай, гөрләвекбай.

Апрель – хуҗа, ул канатлы дусларыбызны каршылый; сулы, ташулы, хезмәт батыры, матур.

Май – ямьле, матур, чәчәкле.

5. Үстерешле уен. «Яз турында кем күбрәк сүз таба?» Мәсәлән: күчмә кошлар, ташу, тамчылар, бөреләр, умырзая һ.б.

6. «Торыйк-торыйк, торналар» уены. [р] авазы.

Барлык балалар аркалары белән түгәрәк ясап, урындыкларга утыралар. Уртада алып баручы. Барысы бергә кабатлыйлар:

Торыйк-торыйк, торналар
Торкылдашып торалар.
Торганнары очып китә,
Тормаганны тоталар.

Сүзләрне әйтеп бетерүгә, алып баручы кулларын чәбәкли, балалар урындыкларыннан сикереп торалар. Алып баручы торып өлгермәгән баланың аркасына кагылып ала һәм ул бала алып баручы була. Уен шулай дәвам итә.

## Тема. Рәсем буенча хикәя төзү: «Яз»
## *(И.Н.Мурашковска методикасын кулланып)*

**Бурычлар:**

1. Балаларда сөйләгәнне игътибар белән тыңлый белү, сорауларга төгәл җавап бирә белү сыйфаты тәрбияләү.
2. Әйләнә-тирә дөньяга эстетик мөнәсәбәт формалаштыру, бәйләнешле сөйләмне үстерү.
3. Балаларны табигатьтә була торган үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү, рәсем буенча сөйли белүләренә ирешү.

**Җиһазлар:** яз рәсеме, аудиоязмада «Язгы тамчылар» җыры («Табигать күренешләре» циклыннан, Р.Еникеев көе).

**Эшчәнлек барышы**

1. «Язгы тамчылар» җырын тыңлау («Табигать күренешләре» циклыннан, Р.Еникеев көе).

2. Балаларга сораулар:

- Бу музыка нинди ел фасылына туры килә?
- Ни өчен шулай дип уйлыйсыз?
- Бу көйне тыңлаганда, сез нәрсәләрне күз алдына китерәсез?
- Язгы айлар нинди айлар?

3. Рәсем карау:

1 адым: Кем нәрсә күрә? (балалар берәмләп һәр предметны әйтә баралар, тәрбияче тактада схема төшерә).

2 адым: Нинди предметларны бергә бәйләп була, ни өчен? (балалар рәсемдәге предметлар арасындагы бәйләнешләр турында сөйли).

3 адым: Нинди тавышлар ишетәсез?

4 адым: «Нинди исләр тоясыз?» (уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү).

5 адым: «Рәсемдәге әйберләрнең сыйфатларын әйтү» (уй белән рәсем эченә керү, сорауга җавап бирү).

6 адым: Хикәя төзү (биш адымны берләштерү). (5 – 6 бала хикәя төзеп сөйли; хикәя сыйфатлы булмаса, тәрбияче үрнәк бирә).

4. «Яз һәм балалар» җырлы-хәрәкәтле уены.

Балалар: Исәнме, яз, матур яз!
Безне сагынып килдеңме?
Агачларга, куакларга
Яшел чуклар элдеңме?
Яз: Саумы, нәни дусларым!
Сезне сагынып килдем мин.
Сезгә аяз көннәр дә,
Яңгыр да китердем мин.

Балалар: Яңгыр яу, яу, яу,
Бар табигать юынсын,
Тирә-як көлеп торсын.
Яңгыр: «Яу, яу»- дип яңгыр телисез,
Ә үзегез качып йөрисез.

## Тема. Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау

**Бурычлар:**

1. Балаларда бер-берсен игътибар белән тыңлый, иптәше сөйләгәнне тулыландыра, аның эшчәнлегенә дөрес бәя бирә белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Халык авыз иҗаты белән таныштыру аркылы балаларның сүзлек байлыгын, диалогик сөйләмнәрен, хәтер, иҗади уйлау сәләтләрен үстерү.

3. Яз турында эндәшләр, тизәйткечләр, әйтенүләр, сынамышлар өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** тәти, күк күлмәк, келәт.

## Эшчәнлек барышы

1. Балаларга сораулар:
- Бар табигать җанланган ел фасылы кайчан?
- Нинди яз айларын беләсез?
- Сез язны ни өчен яратасыз?

2. Тизәйткеч. [ж] авазы.

Җы-җы-җы-җы
Яз килде җылы.

3. Эндәш ятлау: «Кояш, чык!»

Кояш, чык, чык, чык!
Майлы ботка бирермен.
Майлы ботка Казанда,
Тәти кашык базарда.

Әти китте базарга,
Тәти кашык алырга.
Тәти кашык – сабы алтын,
Безгә кирәкми салкын.

4. Әйтенү «Сыерчык».

Сыерчык, сыерчык,
Күк күлмәгең киеп чык.
Үзеңнеке булмаса,
Атаңныкын киеп чык.

5. Мәкаль: Язгы хезмәт – көзге хөрмәт.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.
- Яз көне кешеләр нинди хезмәт башкаралар?
- Чәчүгә чыгар алдыннан нинди бәйрәм була?
- Яз көне нинди борынгы бәйрәмнәр билгеләп үтелә?

6. Зиһен сынаш уены «Кап та коп»:

Балалар, бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш, йодрыкларын йодрык өстенә куеп, кулларын бергәләп күтәреп-төшереп, түбәндәге такмазаны әйтәләр:

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек.

Базга төштек, бал ашадык,
Келәткә кердек, май каптык,
Кап та коп,
Тимер туп,
Авызыңны ач та йом!

Бар да берьюлы авызларын йомалар. Кем дә кем беренче булып авызын ачса яисә көлеп җибәрсә, шул балага җәза бирелә. Ул яз турында табышмаклар, мәкальләр, сынамышлар әйтә.

### Тема. Шигырь ятлау: М.Мазунов. «Яз килә»

**Бурычлар:**

1. Табигатьнең матурлыгын күрә, аңа соклана белү хисләре тәрбияләү.
2. Балаларның хәтерен, сәнгатьле итеп сөйли белү осталыкларын үстерү.
3. Аерым сүзләрне аңларга булышу, татар теленә генә хас авазлар кергән сүзләрне дөрес әйтүләренә ирешү, шигырьгә кызыксыну уяту.

**Сүзлек:** аяз, күк, көмеш тамчы.

**Җиһазлар:** яз турында рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 130 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Әйтемнәр:

а) Каз килсә – яз килә.
б) Апрель туса – яз була.
в) Апрель җитсә, яз җитәр,
Эреп бетеп, кар китәр.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

2. Шигырь уку: М.Мазунов. «Яз килә».

3. Балаларга сораулар:

- Яз килгәндә табигатьтә нинди үзгәрешләр була?
- Күктәге кояш ничек көлә?
- Автор тамчыларны нәрсә белән чагыштыра?
- Яздан ямьлерәк ел фасыллары бармы? Ни өчен?
- Яз безгә нәрсәләр алып килә?

4. Шигырьне яттан сөйләү (5 – 6 бала сөйли).

5. Дидактик уен «Җөмләне дәвам ит!»

Мәсәлән: Җылы яктан кошлар ... . Урманда ... уянды. Җиргә тама көмеш ... . Нур сибеп ... көлә. Яз белән бергә ... килә һ.б.

6. «Яз килде» уены (рәсемнәр ярдәмендә).

Балалар рәсемнәр буенча җөмләләр төзиләр һәм һәрбер җөмләгә хәрәкәтләр уйлап чыгаралар.

## Тема. Тәҗрибә үткәрү. «Суган утырту»

**Бурычлар:**

1. Балаларда суган үстерү теләге тудыру, хезмәткә хөрмәт тәрбияләү.
2. Балаларның логик фикер йөртү күнекмәләрен үстерү.
3. Суганның файдалы яшелчә икәне турында төшенчә бирү; суган үстерү турында белемнәрен тулыландыру.

**Сүзлек:** җылылык, яктылык, итләч, йомры.

**Җиһазлар:** чиләк, туфрак, тартма, утырту өчен суганчалар, сулы лейка, тартмада һәм түтәлдә үскән суган рәсемнәре.

### Эшчәнлек барышы

1. Рәсемнәр карау (түтәлдә һәм тартмада үскән суган рәсемнәре):

- Бу рәсемнәргә карап, сез нәрсә әйтә аласыз?
- Яшелчәләрне, түтәл ясап, кайсы вакытта утырталар?
- Тартмага суган утыртуның нинди уңай ягы бар?
- Суган үссен өчен нәрсәләр кирәк? (яктылык, җылылык, су)

2. «Табышмак әйтәм – җавабын тап!»

а) Кечкенә генә йорт, эче тулы корт. (Кыяр)

б) Өсте яшел, асты кызыл, җирдә үсә. Ул нәрсә? (Кишер)

в) Кат-кат тунлы, карыш буйлы. (Кәбестә)

г) Җир астында җиз бүкән, ул ни икән? (Бәрәңге)

д) Туп түгел – түгәрәк,
Тычкан түгел – койрыклы. (Чөгендер)

е) Итләч, йомры, яшелен
Өзеп алдым, яшердем.
Гаҗәпләндем бераздан –
Кояшсыз да кызарган. (Помидор)

ж) Үскәндә яфрагын ашыйлар,

Үсеп җиткәч, үзен ашыйлар. (Суган)

3. Үстерешле диалог (суган үзенчәлекләрен әйтү):

- Ул нинди формада?
- Нинди төстә?
- Катымы, йомшакмы?
- Тәме нинди?
- Суган ни өчен кирәк?
- Суганның файдасы нинди?
- Суганнан нинди ризыклар пешереп була?

4. Суган утырту:

Өстәлдә һәр балага җитәрлек итеп суганчалар, тартма, туфрак, лейка белән су әзерләп куела. Балалар тәрбияче белән бергәләп суган утырталар, суган утырту тәртибен сөйләмдә ныгыталар.

5. Сүзле-хәрәкәтле уен «Аш пешерү».

Ярдәм көтеп тормыйбыз,
Яшелчәләр турыйбыз.
Без кәбестә турыйбыз,
Чиста итеп юабыз,
Бераз кишер кырабыз,
Ваклап суган турыйбыз.
Тозлап, майлап алабыз,
Яхшылап болгатабыз,
Бигрәк тәмле, ашагыз.

## Проект. Безнең канатлы дусларыбыз

### Тема. Терәк сораулар буенча, рәсемгә карап, чагыштырма хикәя төзү. «Сыерчык белән карга яз килүгә шатлана»

**Бурычлар:**

1. Кошларга сак караш һәм кайгыртучанлык хисе тәрбияләү.
2. Балаларның күзаллау, тасвирлый белү сәләтен үстерү.
3. Кошлар турында белешмә бирү, тышкы билгеләренә карап сыерчыкны һәм карганы танырга өйрәтү, кешеләрнең алар турында ничек кайгыртуын күзаллый белүне формалаштыру.

**Сүзлек:** сыерчык оясы, моң-көең.

**Җиһазлар:** сыерчык рәсеме, карга рәсеме, сыерчык оясы, карга оясының рәсеме.

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: Б.Рәхмәт. «Яз килә».

Яз килә! Яз килә!
Сыерчык, карга килә.
Гөрләшеп, сайрашып,
Җырчы кошлар килә.

2. Сыерчык һәм карга ояларын карау:
- Нинди кош ояларын күрәсез?
- Бу ояларны кем ясаган? Нәрсәдән?
- Бу ояларда нинди кошлар яши?
- Балалары турында ничек кайгырталар?
- Кошларга карата без нинди мөнәсәбәттә булырга тиеш? Ни өчен?
- Сез кошларга ничек ярдәм итәсез?

3. Чагыштырып хикәя төзү:
Балаларга ике рәсем тәкъдим ителә. Беренче рәсемдә сыерчык сайрап тора, ә икенчесендә карга утыра. Балалар сорауларга җавап биреп, чагыштырып хикәя төзиләр.

4. Әйтенүләр ятлау:

а) Сыерчык, сыерчык,
Ояңнан очып чык.
Ошаса бу өең,
Түгелсен моң-көең!

б) Карга әйтә: Кар, кар,
Мичтә бәлеш бар, бар,
Мичтән бәлеш алыр идем,
Өйдә кунак бар, бар.

5. «Табышмак әйтәм – җавабын тап!»

а) Агач башында йорты,
Эчендә яши җырчы.
(Сыерчык)

б) Купшы итеп киенгән,
Кап-кара күлмәк кигән.
Яз килгәнен хәбәр итеп,
Җылы яклардан килгән. (Кара карга)

**Тема. Уен-викторина: «Кошлар – безнең дусларыбыз!»**

**Бурычлар:**
1. Балаларда кошларга, барлык тереклек ияләренә карата мәрхәмәтлелек, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү.
2. Балаларның күзаллый, тасвирлый белү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен, иҗади мөмкинлекләрен үстерү.
3. Балаларга кошлар турында белешмә бирү, тышкы билгеләренә карап таныргa, исемнәрен әйтергә өйрәтүне дәвам итү.
**Сүзлек:** сырт, туена, ерткыч, купшы, зирәк, кәеф.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Кошлар тавышы», туп, интерактив такта, рәсемнәр.

## Эшчәнлек барышы

1. Эрудит сораулар.

- Кошлар хайваннардан нәрсә белән аерылалар?
- Ак сыртлы кошның исеме ничек?
- Кызыл күкрәкле кошны атагыз.
- Оча торган барабанчыны кем белә?
- Нинди кошлар хат ташучы була алалар?
- Нинди кош, сәгате булмаса да, вакытны әйтә?
- Көз көне җылы якларга китеп, язын кире кайткан кошлар ничек дип аталалар?
- Нинди кош көндез йоклый, төнлә оча, кешеләрне куркыта?
- Дөньяда иң зур кош нәрсә ул?
- Нинди кош судан коры чыга?
- Урман докторы дип кайсы кошны атыйлар?
- Нинди кош үз йомыркасын чит ояга сала?

2. Аудиоязма тыңлау: «Кошлар тавышы».

3. Игътибарлылык уены «Кошлар кайтты».

Тәрбияче шигырьне укый, балалар, күчмә кошларның исемнәрен ишеткәч, кул чабалар:

Мондый кошлар кайттылар:
Күке, казлар, аккошлар,
Сандугачлар, песнәкләр,
Ябалаклар, ләкләкләр,
Кара карга, тургайлар,
Сыерчыклар, чыпчыклар,
Карлыгачлар, торналар.
Барыгыз да булганнар,
Барыгыз да уңганнар.

4. «Яхшы – начар» уены.

- Кошларның җылы якка китүе яхшымы, начармы? Ни өчен? Аңлатып бирегез.

5. Дидактик уен «Исеңә төшер һәм җөмләне тәмамла!» (интерактив такта яки рәсемнәр белән).

- Кайсы кошның нәрсә белән туенуын күрсәтегез.

Песнәк – ...
Карабүрек – ...
Карчыга – ...

Аккош – ...

Белешмә өчен сүзләр: ерткыч, бөҗәк ашаучы, орлык белән туенучы, балык ашаучы һ.б. Мәсәлән: песнәк – бөҗәк ашаучы кош.

6. «Сыйфатларын әйт!» уены (туп белән). Мәсәлән: ябалак – авыр хәрәкәтле, сандугач – җырчы, аккош – зифа һ.б.

7. Тел шомарткыч: [ч] авазы.

Чыпчык, чыпчык,
Чык, чыпчык.
Чыкчы, чыпчык,
Чык, кошчык.

## Тема. Шигырь уку: Г.Тукай. «Карлыгач»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кошларга карата сак караш, мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләү.

2. Әдәби әсәрләргә эмоциональ мөнәсәбәт формалаштыру, диалогик сөйләмне үстерү.

3. Балаларны игътибар белән шигырь тыңларга өйрәтүне дәвам итү, шигырь аша кошларның үзенчәлекләре турында белемнәрен киңәйтү.

**Сүзлек:** тәрәзә капкачы, иренмичә, ялтыр-йолтыр.

**Җиһазлар:** кош рәсемнәре, кош оялары төшерелгән рәсемнәр, карлыгач рәсеме.

## Эшчәнлек барышы

1. Дидактик уен «Һәр кошның үз өе».

Балаларга кош рәсемнәре һәм төрле кош оялары төшерелгән рәсемнәр бирелә. Алар рәсемнәрне парлап урнаштыра.

2. Табышмак:

Кулы юк, балчык ташый,
Балтасы юк, оя ясый. (Карлыгач)

3. Шигырь уку: Г.Тукай. «Карлыгач».

4. Балаларга сораулар:

- Карлыгач нинди урынны оя иткән?

- Ояны ничек итеп, нәрсәдән ясаган?

- Карлыгач балаларын нәрсә белән сыйлый?

5. Хәрәкәтле уен «Оясыз кош».

Балалар парлашып түгәрәккә басалар. Алар кошлар булалар. Кошлар түгәрәк буйлап очып йөриләр.

Тәрбияче: Очып баручы кошлар
Тукталдылар аланда.

Балалар парлашып басалар, парсыз калган бала – оясыз кош була. Ул бала уеннан чыгарыла.

Тәрбияче: Утырып ял иттеләр,
Кире очып киттеләр.

Уен шулай дәвам итә.

## Проект. Хәрәкәттә – бәрәкәт

### Тема. «Минем яраткан спорт төре»

**Бурычлар:**

1. Балаларда ихтыяр көче, сабырлык, кыюлык, уен кагыйдәләрен үтәү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Танып белү һәм мөстәкыйль фикерләү эшчәнлеген үстерү.

3. Үз теләкләрен башкаларныкы белән яраклаштырырга, иптәшләре алдында җаваплылык хисе тоярга өйрәтү.

**Сүзлек:** көрәшче, милли көрәш, баскетбол, волейбол, футбол, теннис.

**Җиһазлар:** спорт төрләре турында слайдлар яисә рәсемнәр, уеннар өчен спорт җиһазлары, аудиоязмада «Мин спортчы» җыры (Р.Вәлиева сүзләре, И.Якупов көе).

### Эшчәнлек барышы

1. Җыр тыңлау: «Мин спортчы» (Р.Вәлиева сүзләре, И.Якупов көе).

2. Балаларга сораулар:

- Нәрсә ул спорт?

- Спортчы нинди булырга тиеш?

- Сезнең гаиләдә спорт белән шөгыльләнүчеләр бармы?

- Нинди спорт төрләрен беләсез? (җиңел атлетика, аэробика, көрәш, ат чабышы һ.б.)

- Спорт белән шөгыльләнгән бала нинди була?

- Спорт белән шөгыльләнгәндә нинди кагыйдәләрне үтәргә кирәк?

- Син нинди спорт төрен яратасың? Ни өчен?

3. Үстерешле уен. «Бу нинди спорт төре» (слайдлар, рәсемнәр карау).

4. Үзлектән хикәя төзү: «Минем яраткан спорт төре».

- Мин велосипедта йөрергә яратам, чөнки ... (хикәяне балалар дәвам итә).

5. Дидактик уен «Кемгә нәрсә кирәк» (рәсемнәр белән): Мәсәлән: кимоно – көрәшчегә, туп – футболчыга, кәшәкә – хоккейчыга һ.б.

6. Хәрәкәтле уен «Кайсыбыз җитезрәк» (спорт төрләреннән уеннар).

## Тема. Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Туплар»

**Бурычлар:**

1. Балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.
2. Спортның төрләренә карата кызыксынучанлыкны, мөстәкыйльлекне үстерү.
3. Сөйләмдә грамматик формаларны һәм ясалма, мәгънәсе капма-каршы булган сүзләрне куллана белергә өйрәтү.

**Сүзлек:** көрәшче, милли көрәш, баскетбол, волейбол, футбол, теннис.

**Җиһазлар:** төрле туплар, тасма, сикергеч.

**Матур әдәбият:** М.Ф.Кашапова. «Иң татлы тел – туган тел», 146 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Типтем – очты биеп-биеп,
Суга төште, батмады.
Әни әйтә: «Шуны чөеп,
Тәрәзәне ватма»,- ди. (Туп)

2. Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Туплар».

3. Балаларга сораулар:

- Нинди туплар була?
- Спортчылар нинди туплар белән уйныйлар?
- Фәниснең тубы белән нинди уеннар уйнарга була?
- Туп белән махсус урында уйнамасаң, нинди бәлагә юлыгырга

мөмкин?

- Һавасы чыккан тупка ничек ярдәм итәргә?

4. «Булсаң зирәк – әйт тизрәк» уены.

а) Футбол, хоккей, теннис – алар – ...

б) Ярышларда беренчелекне алган кеше – ул – ...

в) Хоккей, футбол уеннарында капкада торучы – ул – ...

г) Стадионда тамашачылар утыра торган урын – ...

д) Ярышларны кем хөкем итә?

5. Дидактик уен «Киресен әйт»:

| | |
|---|---|
| Старт – | Кыю – |
| Җиңү – | Биек – |
| Шатлану – | Көчле – |
| Тиз – | Җиңел – |
| Хәрәкәт – | |

6. Хәрәкәтле уен «Күңелле уеннар». [h], [x] авазлары.

Балалар ярымтүгәрәк ясап утыралар. Бер төркем бала уртада туп, тасма, сикергеч белән төрле спорт күнегүләре башкара. Тамашачы балалар хуплау сүзләре кычкырып торалар. Ничек хупларга икәнен башта тәрбияче күрсәтә: Хуп!.. Яхшы!... Һай, һай, һай!!! – балалар төрле тизлектә әйтәләр.

## Проект. Су – яшәү чыганагы

### Тема. Әңгәмә. «Яңгыркаем, яу, яу!»

**Бурычлар:**

1. Табигатькә сак караш һәм мәхәббәт тәрбияләү.

2. Балаларның фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен, игътибарлылыкларын үстерү.

3. Табигатьтә була торган үзгәрешләр турында балаларның күзаллауларын киңәйтү, яңгырның каян килеп чыгуын аңлату, табигатькә соклана һәм аның гүзәллеген күрә белергә өйрәтү.

**Сүзлек:** ләйсән яңгыр, эре яңгыр, яшенле яңгыр, суалчан.

**Җиһазлар:** слайдлар яки рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку: И.Юзеев. «Яңгыр ява».

Яңгыр ява, яңгыр ява
Шыбыр-шыбыр.
Йөгереп чыга бала-чага,
Ыбыр-чыбыр.

Яшен яшьни, күкләр тетри
Дөбер-шатыр.
Курыкмыйлар, кулларында
Зонтик-чатыр.

2. Балаларга сораулар:

- Нинди яңгырлар була?

Тәрбияче: Ләйсән яңгыр – язын беренче тапкыр сибәләп яуган вак кына җылы яңгыр. Эре яңгыр – җәйге яңгыр, гадәттә, каралып, куерып килгән болыттан ява. Авыр эре яңгыр тамчылары җиргә уктай атыла, тәнгә тисә, салкынлыгы белән чеметеп-чеметеп ала. Яшенле яңгыр – җәйге чиллә вакытында була. Кап-кара болытлар бергә җыела, һәм көчле җил куба. Яшен яшенли, күк күкри, шул ук вакытта яңгыр да чиләкләп коярга тотына. Яшенле яңгыр вакытында боз да яварга мөмкин. Кояшлы яңгыр – бик аз вакыт эчендә яуган яңгыр.

3. Тәрбияче хикәясе «Яңгыр ничек барлыкка килә?»:

Кояш диңгез, океан, елга, күл өстен җылыта һәм аларның суы парга әйләнә. Пар җылы һава агышы белән югарыга күтәрелә. Ул шунда суына, куера һәм бик вак су тамчылары хасил итә. Без аларны ак болытлар итеп күрәбез. Бер-берсе белән куышып, эреләнгән, авырайган тамчылар исә сибәләп яисә коеп ява торган яңгыр булып җиргә төшә. Яңгыр менә шулай барлыкка килә.

4. Зиһен үстерешле уен «Яңгырның файдасы һәм зыяны»:

- Яңгырның нинди файдасы бар?

- Күп итеп яуган яңгыр файдалымы яисә зыянлымы?

5. «Сүз эчендә энҗе бар»

Мәсәлән: а) яңгырлау – бик еш яңгыр яву;

б) яңгырлы – яңгыр ява торган, явым-төшемле;

в) яңгырсыз – яңгыр булмаган, корылыклы (яңгырсыз ел);

г) яңгыр суалчаны – сөяксез, нечкә йомшак тәнле, шуышып хәрәкәтләнә торган озынча корт (русча: дождевой червь);

д) яңгыр башмагы – гөмбә, аю тәмәкесе (русча: дождевик);

е) яңгыр күзе төшү – яңгыр алдыннан берән-сәрән тамчы тамып алу;

ж) яңгыр артыннан чыккан гөмбәдәй – бик тиз, бик күп булып барлыкка килү.

6. Мәкаль: Халык әйтсә, хак әйтә.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

- Яңгыр боткасы буламы?

Тәрбияче: Элекке заманда – озак вакыт яңгыр яумый торган, корылыклы елларда – балалар йорт саен тоз, май, ярма җыеп йөргәннәр. Аннары су буена төшеп, казан асып, тәмле ботка пешергәннәр. Су сибешеп уйнаганнар, шулай итеп яңгыр теләгәннәр.

## Тема. Тәҗрибә. «Суның үзенчәлекләре»

**Бурычлар:**

1. Яшәү чыганагы булган суга сак караш тәрбияләү.
2. Балаларның күзаллауларын, мөстәкыйль фикер йөртә белү сәләтен үстерү.
3. Гади тәҗрибәләр һәм уеннар аша балаларның су үзенчәлекләре турындагы белемнәрен тирәнәйтү.

**Сүзлек:** халәт, салават күпере.

**Җиһазлар:** бал кашыгы, сулы, сөтле стакан, тоз, елга комы, термос, пыяла, күбекле су, салам таякчыклары.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Булмаган җире сирәк,
Үзе һәрвакыт кирәк. (Су)

2. Фикер алышу (Җир шары макеты, глобус ярдәмендә):

- Анда коры җир күбрәкме, әллә сумы?
- Су кайларда була?
- Су турынданиләр беләсез?
- Ул нинди?
- Кешеләр, хайваннар, үсемлекләр сусыз яши алалармы?
- Алар суны каян таба?
- Сулыкларны пычратырга ярыймы?
- Суның ничә төрле халәте бар?
- Су белән нәрсәләр эшләргә мөмкин?

3. Су белән тәҗрибәләр:

Беренче тәҗрибә: Исе бармы? (Балаларга суны иснәп карарга кушу).

Икенче тәҗрибә: Тәме бармы? (Балаларга гади су биреп, тәмен татып карарга кушу).

Өченче тәҗрибә: Төсе бармы? Кайсыда бал кашыгы күренер? Ни өчен? (Бал кашыгын су һәм сөт салынган стаканга төшерү).

Дүртенче тәҗрибә: Ике стаканда су. Берсенә – тоз, икенчесенә елга комы салына, болгатабыз.

- Кайсы эреде? Ни өчен? Тоз кая китте?

Бишенче тәҗрибә: Термоска кайнар су салабыз. Аны ачкач, пар күтәрелә. Өстен пыяла белән ябабыз, бераздан анда су парлары пәйда була.

4. Хәрәкәтле уен «Яр – су».

Озын сызык сызыла. Сызыкның бер ягы «Су», икенче ягы – «Яр». Алып баручы «Яр – су, яр – су, яр – су» дип тора, ә балалар, буталмыйча, ул әйткән җиргә сикерәләр. Буталганы уеннан чыга. Иң соңгы бала җиңә һәм алып баручы була.

5. Тыныч уен «Салават күпере». Сабын күбекләрен очыртып уйнау, анда салават күперендәге төсләр булуын ачыклау.

## Проект. Уттан саклан!

### Тема. Әңгәмә. «Янгын куркынычсызлыгы»

**Бурычлар:**

1. Ут чыгу куркынычы булган әйберләр белән сак булу сыйфаты тәрбияләү.

2. Балаларның уй-фикерләрен бер юнәлештә туплый белү сәләтен, игътибарлылыкларын үстерү.

3. Янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре белән танышуны дәвам итү, янгын чыгу очрагында үзләрен дөрес тоту күнекмәләрен ныгыту.

**Сүзлек:** янгын, ялкын, электр.

**Җиһазлар:** рәсемнәр, машиналар.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмаклар:

а) Аягы юк, кулы юк,
Тиз йөгерә, тиз җиңә. (Ут)

б) Ялт-йолт итәр,
Ялмап китәр. (Ут)

в) Башыбыз бар, гәүдәбез бар,
Юк кул-аякларыбыз.
Балалар тотса, куркабыз –
Яман шул якларыбыз. (Шырпы)

2. Фикер алышу:

- Ут кешенең дустымы, әллә дошманымы?
- Ут кешеләргә ни өчен кирәк?
- Утны дөрес кулланмаганда, нинди зыян килергә мөмкин?
- Нинди әйберләрдән янгын чыгу куркынычы зур?
- Янгын чыккан очракта нәрсә эшләргә кирәк?
- Куркынычсызлык чаралары нинди була?

3. Дидактик уен «Ут кайда яшеренгән?» Рәсемнәр карау; балаларның рәсем буенча фикерләрен тыңлау.

4. Үстерешле уен «Кагыйдәне бел!»

- Шырпы белән уйнама!
- Электр әйберләренә зурлардан башка кагылма!
- Урманда учак якма!
- Газ плитәсен үзең кабызма!
- Янгын чыккан очракта «01» гә шалтырат!

Пожар турында ишеткәч,
Сигнал бирергә ашык.
Янгын гел көчәя бара,
Туктатып булмый ич һич.
Су гына сүндермәс аны,
Кирәк шул... (Ут сүндергеч)

5. Хәрәкәтле уен «Телефон номеры буенча тап».

Уен эстафета формасында оештырыла. Балалар ике командага бүленәләр. Тәрбияче телефон номерын әйтеп тора: 01, 02, 03, 04. Балалар, чиратлап, шул номерга туры килгән машина рәсемен табып күрсәтәләр. Кайсы команда алдан өлгерә, шул җиңүче була.

## Тема. Шигырь уку: Г.Гыйльманов. «Ярый әле»

**Бурычлар:**

1. Матур әдәбият аша балаларда саклык, игътибарлылык сыйфатлары тәрбияләү.
2. Балаларның уй-фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү.
3. Балаларның җөмләләрдәге һәр сүзне үз урынына куеп, кушымчаларны дөрес ялгап әйтә белүләрен камилләштерү.

**Сүзлек:** имеш, бәп-бәләкәй, өеп, учак, маташа, дөрләп, үрле-кырлы, үкерә, газап, хикмәт, өстәвенә.

**Җиһазлар:** «Янгын бүлегендә мин нәрсә күрдем?» дигән рәсем күргәзмәсе, уен өчен ике телефон.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 204 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!» уены.

- Нәрсә ул янгын?
- Ут кешеләргә нинди зыян (файда) китерә?
- Нинди әйберләрдән янгын чыгарга мөмкин?
- Янгын чыккан очракта безгә кемнәр ярдәм итә?
- Янгын чыккан очракта нинди номерга шалтыратырга кирәк?

2. Шигырь уку: Г.Гыйльманов. «Ярый әле».

3. Балаларга сораулар:

- Кечкенә малай нәрсә белән уйнаган?
- Ут белән уйнаган малай белән нинди хәл килеп чыккан?
- Ул ничек исән калган?
- Уйнаган әйберләре чын булган булса, малай белән нәрсә булыр иде?
- Шырпы белән уйнарга ярыймы?

4. Рәсем күргәзмәсе. «Янгын бүлегендә мин нәрсә күрдем?» Балаларның үз рәсемнәре буенча фикерләрен тыңлау.

5. Мәкаль, әйтемнәр:

а) Батыр үзе үлсә дә, исеме үлмәс!
б) Куркак кеше үз күләгәсеннән курка.
в) Куркуын җиңгән – батыр булыр.
д) Батыр иле өчен үләр.
г) Кыю бер үләр, куркак мең үләр.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

6. Дидактик уен «Янгын сүндерүчеләрне чакыр!»

Уен өчен ике телефон кирәк була: берсе – шалтыратуларны кабул итү (диспетчерлык) пункты, икенчесе – хәбәр бирү өчен. Балалар «01» номеры аша янгын сүндерүчеләрне чакыралар. Чакыру вакытында төгәл, ачык итеп, үзләренең исемнәрен, фамилияләрен, кайда нәрсә януын хәбәр итәләр, янгын чыккан урынның адресын әйтәләр.

## Проект. Бүлмә гөлләре
### Тема. «Хуш исле нәфис гөлләр»

**Бурычлар:**

1. Балаларда бүлмә гөлләренә карата сак караш тәрбияләү.
2. Бәйләнешле сөйләм, чагыштыра белү, фикерләү сәләтен үстерү.
3. Бүлмә гөлләрен үзләренә генә хас үзенчәлекләре буенча танып, бер-берсеннән аерырга өйрәтү, кеше тормышында аларның әһәмиятен аңлату.

**Сүзлек:** бүлмә гөле, фикус, алоэ, үрмә гөл, кактус.

**Җиһазлар:** бүлмә гөлләре яисә рәсемнәр, дидактик уен өчен материал.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку: Л.Шакирҗанова. «Гөлләр».

Үстерде гөлләр Гөлнара,
Шундый матурлар алар,
Урамнан үтүчеләр
Бары да сокланалар.

Гөлнара үстергән гөлләр
Күмелделәр чәчәккә.
Ул аларны бүләк итеп,
Алып килде бакчага.

2. Балаларга сораулар:

- Гөлнара нинди гөлләр үстергән?
- Алар кайда үсәләр?
- Аларны урамда үстерәләрме?
- Сез нинди гөлләр беләсез?
- Гөлләр безгә каян килгән?

3. Алоэ гөле турында әкият сөйләү.

Тәрбияче: Борын-борын заманда җылы якта бер кабилә булган. Кабилә кешеләре урманга ауга йөри торган булганнар. Бервакыт бер аучы, каты яраланудан хәлсезләнеп, агач күләгәсендә ята икән. Агач телгә килеп: «Син минем бер яфрагымны кисеп ал да, яраңа яп, яраң төзәлер»,- дигән. Аучы шулай эшләгән. Аягы бик тиз төзәлгән. Агачка рәхмәт йөзеннән ул аның бер ботагын өенә алып кайтып, чүлмәккә утырткан. Шулай итеп, алоэ гөле бүлмәдә үсә торган булган.

4. Дидактик уен «Чәчәк-яфрак». Чәчәкләренә, яфракларының формаларына һәм сабакларына карап, гөлнең чәчәген һәм яфра-

гын дөрес табу; гөлнең исемен әйтү.

5. Сүзле-хәрәкәтле уен «Ал кирәк – гөл кирәк».

Балаларның һәрберсенә чәчәк – гөл исеме бирелә: яран, роза, тамчы гөл, фикус, кына һ.б. Балалар ике төркемгә бүленәләр. Кулга-кул тотынышып, бер-берсенә каршы басалар, түбәндәгечә әйтешәләр:

1 нче төркем:
Ал кирәк, гөл кирәк,
Сезгә нинди гөл кирәк.

2 нче төркем:
Ал кирәк, гөл кирәк
Безгә матур чәчәкле,
Тамчы гөл бик кирәк.

Тамчы гөл каршы якка йөгереп барып, ике бала арасыннан үтәргә, аларның җитәкләшкән кулларын «өзәргә» тырыша. «Өзеп» чыга алса, ике баланың берсен җитәкләп алып, кире үз ягына кайта. Әгәр «өзә» алмаса, үзе шул якта кала.

## Тема. Тәҗрибә. «Кояш, су, һаваның үсемлекләр өчен әһәмияте»

**Бурычлар:**

1. Балаларда үсемлекләрне күзәтә белү сыйфаты, тирә-юньгә кызыксынучанлык тәрбияләү.
2. Гади генә тәҗрибәләр ясап, балаларның хәтерен, игътибарлылыгын, логик фикерләү сәләтен үстерү, халык авыз иҗатына кызыксынуларын арттыру.
3. Балалар белгән табигать күренешләрен күзәтеп, алар арасында үзара бәйләнеш булуы турында нәтиҗә чыгарырга өйрәтү.

**Сүзлек:** кислород, углекислый газ.

**Җиһазлар:** ике төрле шартларда үскән бүлмә гөлләре, дидактик уен өчен материал.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

а) Зур алтын кыршау тәгәри,
Көн саен һава буйлап.
Тупка да бик охшаган ул –
Кызганыч, булмый уйнап. (Кояш)

б) Исе дә юк, төсе дә юк,
Аннан башка тормыш юк. (Су)

в) Борынга керә, үпкәгә үтә,
Аннан башка яши алмый
беркем дә. (Һава)

2. Фикер алышу.

- «Кояш, су һәм һава безнең иң якын дусларыбыз» әйтемен сез ничек аңлыйсыз?

- Сәламәт булыр өчен нишләргә кирәк? (Саф һавада булырга кирәк)

- Җан ияләре нинди һаваны сулый? (Кислород)

- Үсемлекләр нинди һава сулый? (Углекислый газ)

- Углекислый газ кайдан чыга?

- Һава чиста булсын өчен, нәрсә эшләргә кирәк?

- Үсемлекләр үссен өчен нәрсә кирәк? (Кояш, су, һава)

3. Эндәшләр:

а) Яңгыр яу, яу, яу,
Бакчаларда алмагач
Корый яңгыр яумагач.
Игеннәр дә күп булсын,
Сыерлар да тук булсын,
Безгә катык, сөт булсын.
Яңгыр яу, яу, яу.

б) Кояшкаем, чык,чык.
Майлы ботка бирербез.
Майлы ботка казанда,
Тәти кашык базарда.
Кирәкми безгә салкын,
Кирәк безгә саф алтын.

4. Дидактик уен «Мин кайда үсәм» (интерактив тактада яисә рәсемнәр белән).

Болын, урман, кыр, чәчәк клумбасы сурәтләнгән 4 зур рәсем эленә. Балалар кулларындагы чәчәк рәсемнәрен дөрес итеп урнаштырырга тиешләр. Мәсәлән: умырзая урманда үсә ...

5. Ике төрле урынга утыртылган яран гөлләрен күзәтү.

Берсе – күләгәдә, икенчесе кояшта үсә. «Нинди аерма күрәсез? Ни өчен шулай дип уйлыйсыз?» дигән сораулар бирелә. Ахырдан нәтиҗә ясала: кояш нурлары төшкән гөл матур булып үсә.

6. Сүзле-хәрәкәтле уен «Ал кирәк – гөл кирәк» (кабатлау).

Балаларның һәрберсенә чәчәк – гөл исеме бирелә: яран, роза, тамчы гөл, фикус, кына һ.б. Балалар ике төркемгә бүленәләр. Кулга-кул тотынышып, бер-берсенә каршы басалар, түбәндәгечә әйтешәләр:

1 нче төркем:
Ал кирәк, гөл кирәк,
Сезгә нинди гөл кирәк?

2 нче төркем:
Ал кирәк, гөл кирәк,
Безгә матур чәчәкле
Тамчы гөл бик кирәк.

Тамчы гөл каршы якка йөгереп барып, ике бала арасыннан

үтәргә, аларның кулларын «өзәргә» тырыша. «Өзеп» чыга алса, ике баланың берсен җитәкләп алып, кире үз ягына кайта. Әгәр «өзә» алмаса, үзе шул якта кала.

## Проект. Галәм киңлекләре

### Тема. «Планетарийга сәяхәт» уены.

**Бурычлар:**

1. Балаларда беренче очучы Ю.Гагарин белән танышу аша илебезгә карата горурлык хисләре тәрбияләү.

2. Балаларның образлы күзаллауларын, иҗадилыкларын, хәтерен үстерү.

3. Балаларга Кояш системасы, планеталар турында элементар белешмә бирү, алар турында күбрәк беләсе килү теләге уяту.

**Сүзлек:** галәм, орбита, планета, глобус, космонавт, ракета, Кояш системасы.

**Җиһазлар:** слайдлар, рәсемнәр, глобус, «Космоска очучы» рәсеме.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 432 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Глобусны карау. Балаларга сораулар.

- Бу нәрсә?
- Без яши торган планетаның исеме ничек?
- Ул нинди формада?
- Зәңгәр төс белән глобуста нәрсә күрсәтелә?
- Яшел төс нәрсәне аңлата?
- Аяз кичтә күк йөзе нинди була?
- Ни өчен көндез йолдызлар күренми?

2. «Планетарийга сәяхәт» уены (интерактив тактада, слайдлар яисә рәсемнәр белән).

Тәрбияче: Безнең Галактиканың үзәгендә иң зур йолдыз – Кояш урнашкан. Кояш безгә җылылык һәм яктылык бирә. Кояш тирәсендә тугыз планета хәрәкәт итә. Аларның һәрберсенең үз юлы бар. Бу юл орбита дип атала. Кояш һәм планеталарны бергә Кояш системасы дип атыйлар. Безнең планетабыз кояштан иң

уңай ераклыкта урнашкан. Шуңа күрә бары безнең планетабызда гына тереклек өчен шартлар бар. Кешеләр галәм киңлекләре белән бик күптән кызыксынганнар. Галәм очкычы – космик корабль төзегәннәр. Иң беренче булып Ю.Гагарин галәмгә очкан. 12 нче апрель – Космонавтика көне дип билгеләп үтелә («Космоска очучы» рәсеме күрсәтелә).

3. Сүзле уен «Яшь космонавтлар».

Балалар сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар.

Без – булачак космонавтлар
Тик тормыйбыз бер дә без:
Кулларны күтәрәбез,
Аннары төшерәбез.
Чүгәлибез, торабыз,
Башны уңга борабыз,
Аннан сулга карыйбыз
Һәм сикерә башлыйбыз.
Шул арада иелеп,
Басарга өлгерәбез.
Тирән итеп сулыйбыз,
Ял итәргә туктыйбыз.
Без бик көчле булабыз.

4. Тапкырларга – табышмак:

а) Лампа түгел, яктырта, мич түгел, җылыта. (Кояш)

б) Төнлә калка, көндез ята. (Ай)

в) Мич тулы пәрәмәч, уртасында бер калач. (Ай һәм йолдызлар)

г) Төнлә баксам, күк тулган, иртән баксам, юк булган. (Йолдызлар)

5. Шигырь уку: Г.Гыйльманов. «Чүмеч йолдыз».

6. Тизәйткеч ятлау:

Җидегәндә җиде кыз,
Җиргә якын ул йолдыз.
Җиргә якын Җидегәндә
Җиде йолдыз, җиде кыз.

## Проект. Г.Тукай иҗаты

### Тема. Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты

**Бурычлар:**

1. Балаларда Г.Тукайның күпкырлы иҗатына кызыксыну уяту, ихтирам хисләре тәрбияләү.

2. Шигырьнең эчтәлеге буенча үз фикерләрен әйтә белү, фикерләү, хәтер сәләтен үстерү.

3. Г.Тукайның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштыру,

әдәби әсәрләрне тыңлый, эчтәлеген сөйли белүләренә ирешү.

**Сүзлек:** шәкерт, буыннар, ятим.

**Җиһазлар:** Г.Тукай портреты, китаплар, аудиоязмада «Туган тел» җыры.

**Эшчәнлек барышы**

1. Җыр тыңлау: «Туган тел».

Нинди таныш, моңлы көй бу?
Тукай җыры – «Туган тел».
Истән бер дә чыкмый торган
Халык көе – «Туган тел».

2. Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты белән танышу (слайдлар, рәсемнәр ярдәмендә):

- Портретта сез кемне күрәсез?
- Г.Тукайның нинди әсәрләрен беләсез?

3. Китаплар карау. Иллюстрацияләр ярдәмендә әсәрләрнең исемнәрен искә төшерү.

4. Үстерешле уен «Кайсы әсәрдән икәнен бел!»

а) Кешенең якын дусты,
Йортның тугры сакчысы.
Аннан гел игелек көт,
Ә исеме ничек?
(Эт – «Кызыклы шәкерт»)

б) Җәен соры, кышын ак,
Аңа шулай яхшырак.
(Куян – «Бичара куян»)

в) Нәкъ кеше кебек үзе,
Бар маңгаенда мөгезе.
«Былтыр кысты»,- дип акыра,
Туганнарын чакыра.
(«Шүрәле»)

г) Чуар, йомшак күлмәге,
Тотсаң, уңа бизәге.
Тоттырмый, китә очып,
Я кала җирдә посып.
(Күбәләк – «Бала белән күбәләк»)

5. Шигырь уку: «Кызыклы шәкерт».

- Малай Акбайны ничек өйрәтә?
- Акбайның ни өчен өйрәнәсе килми?
- Малай Акбайга ни өчен тырышырга куша?

6. «Су анасы» уены:

Балалар түгәрәккә басалар. Бер бала Су анасы итеп билгеләнә. Ул күзләре бәйләнгән килеш түгәрәк уртасында утыра. Уйнау-

чылар түгәрәк буйлап җырлап йөриләр:

Су анасы, Су анасы,
Су анасын күр әле.
Каршыңда кем басып тора –
Ялгышмыйча әйт әле.

Җыр ахырында балалар туктап кала. Күзе бәйләнгән Су анасы урыныннан тора, тәрбияче бармагы белән берәр уенчыга төртеп күрсәтә. Әлеге бала Су анасы янына килә. Су анасы, капшап карап, аның кем икәнлеген әйтергә тиеш. Әгәр дөрес әйтсә, шул уенчы Су анасы була.

### Тема. Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Бала белән күбәләк»

**Бурычлар:**

1. Балаларда Г.Тукай әсәрләренә карата кызыксыну тәрбияләү.
2. Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарлылыгын, иҗадилыкларын үстерү.
3. Балаларда оештыру һәм алып баручы ролен башкару осталыгын формалаштыру, үзләренең эш-гамәлләрен, уенны алып баручы һәм башка катнашучыларның гамәлләренә яраклаштырырга өйрәтү.

**Сүзлек:** чуар, уңа.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Бала белән күбәләк» җыры, сәхнәләштерү өчен атрибутлар, «Бала белән күбәләк» мультфильмы.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Чуар йомшак күлмәге,
Тотсаң, уңа бизәге.
Тоттырмый, китә очып,
Я кала җирдә посып. (Күбәләк)

2. Шигырь уку: «Бала белән Күбәләк».
3. Балаларга сораулар:

- Кыз Күбәләккә нинди сораулар бирә?
- Күбәләк ни дип җавап кайтара?

- Күбәләк кайда яши?
- Нәрсә белән туклана?
- Күбәләкне ни өчен рәнҗетмәскә кирәк?
4. Җыр тыңлау: «Бала белән күбәләк».
5. Мультфильм карау: «Бала белән күбәләк».
6. Шигырьне сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Бала белән күбәләк».

### Тема. Шигырь ятлау: З.Туфайлова. «Тукай абый»

**Бурычлар:**

1. Шигырьнең тылсымлы сүзләре аша шагыйрьгә карата мәхәббәт һәм ихтирам тәрбияләү.
2. Балаларның үз теләкләре белән яттан шигырьләр сөйләүгә булган омтылышларын, хәтер сәләтен үстерү.
3. Шигырьдәге төп фикерне әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** җен, гүзәл, Шүрәле.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Туган тел» җыры, Г.Тукай әсәрләреннән төзелгән мультфильмнар.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 197 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Җыр тыңлау: «Туган тел» (Г.Тукай сүз.)
2. Үстерешле уен «Танып әйт».

Г.Тукай әсәрләреннән төзелгән мультфильмнардан өзекләр күрсәтелә. Балалар аларның исемнәрен атыйлар.

3. Шигырь уку: З.Туфайлова. «Тукай абый».
4. Балаларга сораулар:

- Бала иң гүзәл бер җыр дип нинди җырны атый?
- Тукайның нинди әкиятләрен беләбез?
- «Су анасы», «Шүрәле»не ни өчен дуслар дип атыйбыз?

5. Шигырьне яттан сөйләү (5 – 6 бала сөйли).
6. Җырлы-биюле уен «Шүрәле, Шүрәле».

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәк ясыйлар. Түгәрәк эченә бер бала чыга. Балалар, такмак әйткәндә, аның исемен әйтеп җырлыйлар. Бу бала, такмак беткәч, йә бии, йә җырлый, йә шигырь сөйли. Түгәрәк эченә икенче бала керә.

Җен дә түгел, җил дә түгел
Күренеп йөри торган.
Шүрәлене саклап тора
Татарда кара урман.
Куш.: Шүрәле, Шүрәле,
Син Айгөлне күр әле!
Үзе бии, үзе җырлый,
Куллар чабып тор әле!

Бер мөгез дә, койрык бер,
Кети-кети уйный ул.
Кием-салым кими ул,
Балаларга тими ул!
Куш.: Шүрәле, Шүрәле,
Син Газизне күр әле!
Җырга оста – җырласын,
Һич оялып тормасын.

## Проект. Урман-җиребезнең матурлыгы, байлыгы

### Тема. Урман почмагына экскурсия

**Бурычлар:**

1. Балаларда урманга һәм аның байлыкларына сак караш тәрбияләү.
2. Кешеләр тарафыннан табигатьне сакларга кирәклеге турында нәтиҗә чыгара белү, логик фикер йөртә белү сәләтен үстерү.
3. Балаларның урман, андагы тереклек турындагы белемнәрен тирәнәйтү, мул табигатьнең кеше тормышында әһәмиятен аңлату.

**Сүзлек:** урман, сәяхәтче, яшел доктор, сукмак, бака яфрагы, энҗе чәчәк.

**Җиһазлар:** дару үләннәре рәсемнәре, туп.

Эшчәнлек табигатьтә уздырыла.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак:

Моңлы да ул, серле дә ул,
Файдалы да, бай да ул.
Кызарып җиләк пешә,
Чикләвекләр өлгерә.
Санап та бетереп булмый.
Нәрсә соң ул, кем белә? (Урман)

2. Фикер алышу:

- Урман кешегә ни өчен кирәк?
- Урманда нәрсәләр үсә?
- Ни өчен күп кошлар урманда яши?
- Урманда нинди җәнлекләр, бөҗәкләр яши?

- Урманда нинди шифалы үләннәр үсә?
- Урманда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен беләсеңме?

3. Дидактик уен «Табышмак буенча агачны бел һәм күрсәт»

а) Ак кием кигән, яшел чугын элгән. (Каен)

б) Җәен дә, кышын да бер төстә. (Чыршы, нарат)

в) Нинди агач җилсез шаулый? (Усак)

г) Җимешем кып-кызыл була,
Бу – шатлык минем өчен.
Чөнки көзге салкын да
Һич тә үзгәртми төсем. (Миләш)

4. Үстерешле уен «Безнең яшел докторлар» (рәсемнәр белән).

Беләсезме үләннәрнең
Күпме дару биргәнен.
Дәшмисезме? Шулар инде
Яшел доктор дигәнем.

а) Сәяхәтче юлдашы
Булыр бу үлән.
Сукмакларда мин аны
Һәрвакыт күрәм.
(Бака яфрагы)

б) Мин дә таныйм дус-
ишне,
Кара нинди хуш исле.
Тагып йөрерлек түшкә
Бу бит көрән ... (мәтрүшкә)

в) Бик күп төрле авыруга
Шифасы бар аның да.
Тамакны да дәвалый ул,
Эчәк авыруларын да.
(Сары мәтрүшкә)

г) Сусауны тиз баса
Бу җиләк чыннан да.
Су эзләп йөрисе
Юк икән урманда.
(Каен җиләге)

д) Энҗе чәчәк – матур чәчәк,
Энҗе сыман чыннан да.
Дарулы да, агулы да,
Сак булыгыз җыйганда.

е) Күрегез әле сез
Сукыр кычытканны.
Йөрәк даруы өчен
Җыялар ич аны.

ж) Яратам мин таң нурын,
Дару минем тамырым.
Шикәре дә җитәрлек,
Тәме исең китәрлек. (Тузганак)

5. Җырлы уен «Аю урманында».

Җиләк җыям чиләккә,
Әниемә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк микән?

6. «Сорау – җавап» уены (туп белән).

- Нинди агач ак күлмәк кия?

- Ни өчен керпе баласын тотарга ярамый?

- Яз җиткәч, кызлар күп итеп умырзая чәчәген җыеп кайттылар. Алар дөрес эшләдеме?

- Урманда үсүче нинди агач ныклыгы белән башкалардан аерыла?

## Тема. «Камканы күзәтү»

**Бурычлар:**

1. Балаларда табигатьтәге тереклек ияләренә карата сак караш тәрбияләү.

2. Образлы күзаллау сәләтен, күзәтүчәнлекләрен, диалогик сөйләмне үстерү.

3. Табигатьтә яшәүче бөҗәкләр белән таныштыруны дәвам итү; камка турында үзләренең белгәннәрен бәйләнешле итеп сөйләргә өйрәтү.

**Сүзлек:** камка, тәти кош, каты канат, кондыз оча, яфракка куна.

**Җиһазлар:** камка рәсеме, туп.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 161 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Эндәш:

Камка түти, киявең килгән,
Тимер капкаң ач та коч.

2. Камканы карау:

- Камка нинди?
- Ул ничек хәрәкәтләнә?
- Камка нәрсәләрне аулый?
- Алар кайда яшиләр?
- Камка нинди файда китерә?
- Камкалар кайда кышлыйлар?

3. Тәрбияче хикәясе:

Камка озынча формада. Ул ачык кызыл яки кызгылт-сары төстә, кара таплар белән бизәлгән. Аның төсе тирә-юньгә

җайлашкан, саклану чарасы булып тора. Кошлар андый төстәге бөҗәкләрне ашарга ярамаганлыкны беләләр. Аның үтә күренмәле көрән кечкенә, каты канатлары бар. Камка бик тиз үрмәли, ерак араларга оча ала. Камка бик күп зарарлы бөҗәкләрне ашап, кешеләргә зур файда китерә. Камка кыш чыгар өчен агач кайрыларына, корыган агач кәүсәләренә яшеренә.

4. Шигырь уку: Ш.Галиев. «Камканы коткардым».

5. Дидактик уен «Дөресен әйт!» (туп белән). Мәсәлән: Камка нинди? Ул ничек хәрәкәтләнә? Нәрсә ярата? Камка кайда кышлый? һ.б.

## Тема. «Кызыл китап» нәрсә ул?

**Бурычлар:**

1. Кызыл китапка кертелгән хайван һәм үсемлекләрне кызгану, алар өчен борчылу хисләре уяту, табигатькә карата сак караш тәрбияләү.

2. Балаларның әйләнә-тирә дөнья белән кызыксынуларын, бәйләнешле сөйләмнәрен үстерү.

3. Балаларны сирәк калган һәм югалып бара торган хайваннар, үсемлекләр турындагы китап белән таныштыру, аның әһәмиятен аңлату.

**Сүзлек:** Кызыл китап, кыр кәҗәсе, кондыз, бөркет, дельфин, аккош, лачын, тыюлыклар.

**Җиһазлар:** Кызыл китап, слайдлар, рәсемнәр, туп.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Табигатьне саклаган – үз яшәвен аклаган.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. «Кызыл китап»ны күрсәтү. Балаларга сораулар:

- Бу нинди китап?

- Нәрсә соң ул «Кызыл китап»?

- «Кызыл китап» нинди бүлекләрдән тора? (Бу китапка җир йөзеннән юкка чыгып бара торган хайваннар, кошлар һәм үсемлекләр теркәлгән, алар турында мәгълүматлар бирелгән)

- Ни өчен ул кызыл, кызыл төс нәрсә аңлата? (Кызыл төс кур-

кыныч янауны белдерә, җир йөзендә сирәк калган җан ияләрен саклагыз дип кисәтә, кирәк булган очракта ярдәм итәргә өнди)

- Тыюлыклар ни өчен кирәк?

3. Слайдлар, рәсемнәр карау. «Кызыл китапка нәрсәләр кергән?» (кыр кәҗәсе, чуар болан, ак аю, кондыз, дельфин, кеш; бөркет, аккош, ак чиләнә, лачыннарның бөтен төре һ.б.).

- Юлбарыс турында нәрсә әйтә аласыз?

- Юлбарысның тиресе нинди?

- Кешеләр аны ни өчен аулый?

- Алар дөрес эшлиләрме?

- Юлбарысларны һәм башка хайваннарны, кошларны һәм үсемлекләрне саклап калыр өчен нәрсә эшләргә кирәк?

- Табигатькә зыян салучыларга сез нәрсә әйтер идегез?

4. Дидактик уен «Кем тизрәк җыя?»

Балалар Кызыл китапка кертелгән хайван һәм кошларның рәсемнәрен өлешләрдән җыялар.

5. Үстерешле уен «Кызыл китапта бармы?» (туп белән).

Тәрбияче төрле хайваннарның, кошларның һәм балыкларның исемнәрен әйтә һәм тупны берәр балага ыргыта. Бала җавап бирә һәм тупны кире тәрбиячегә кайтара.

6. Балалар эшчәнлеге: «Мин табигать дусты» (5 – 6 бала сөйли).

Балалар үзләренең ничек итеп кошларга ярдәм итүләре турында сөйлиләр.

### Тема. Әкият эчтәлеген сөйләү: Ф.Зариф. «Татлы җәй»

**Бурычлар:**

1. Җәйге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксыну хисе тәрбияләү.

2. Балаларның сүзлек запасын арттыру, бәйләнешле сөйләм телен, фикерне бер юнәлештә туплый белү сәләтен үстерү.

3. Әкиятләргә кызыксыну уяту, сөйли белү теләге тудыру, аңларга өйрәтү.

**Сүзлек:** татлы, нигъмәтләр, сыйпап, гомумән, игелек, чырылдашкан, нәни йөнтәскәйләр, гаҗәеп.

**Җиһазлар:** уен өчен аю битлеге.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 184 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак.

Кигән киеменең бизәге
Бөтен дөньяны ямьгә бизәде. (Җәй)

2. «Ми чарлау» уены.

- Җәйнең иң эссе вакыты ничек атала? (Чиллә)

- Кояш кайчан суга? (Челләдә яланбаш йөрсәң)

- Җәйге эссе, җилсез көндә офыктагы һаваның калтырап, дулкынланып, җемелдәп торуын бер сүз белән ничек атыйлар? (Рәшә)

- Күк күкрәп, яшен яшьнәп яуган җылы яңгырдан соң нәрсә барлыкка килә? (Салават күпере)

3. Әкият уку: Ф.Зариф. «Татлы җәй».

4. Балаларга сораулар:

- Төлке баласы Шаянга әнисе ни өчен җәйгә рәхмәт әйтергә куша?
- Җәй нинди балаларга гына күренә?
- Акыллы бала нинди була?
- Шаян Шәүләгән баласына ничек ярдәм итә?
- Аю балаларын ул нәрсә өйрәтә?
- Җәй Шаянга үзенең рәхмәтен ничек белдерә?
- Шаян җәйнең татлы икәнен каян белә?

5. Балалар эшчәнлеге (5 – 6 бала сөйли).

6. Тел көрмәкләндергеч «Елама, Җамалый». [ж] авазы.

Җәен җиләк җыйганда
Җиңен ерткан Җамалый.
Елама-елама, Җамалый,
Елап җиңең ямалмый.

7. Сүзле-хәрәкәтле уен «Җиләк җыю».

- Дуслар, кая барасыз?
- Кара урманга барабыз.
- Кара урманда нишлисез?
- Кура җиләк җыябыз.
- Җиләк белән нишлисез?
- Җиләктән как коябыз.
- Аю килсә нишлисез?
- Урман буйлап чабабыз.

Аннан соң барысы бергә күмәкләшеп җырлыйлар:

Җиләк җыям, как коям
Дәү әнигә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән.

Аю яшеренгән җиреннән чыга да, аларны куа башлый.

## Проект. Җиңү алып килде май

### Тема. Сугыш ветераннары белән очрашу. «Бөек Җиңү»

**Бурычлар:**

1. Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.

2. Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкны үстерү.

3. Сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында балаларның белемнәрен арттыру.

**Сүзлек:** Бөек Ватан сугышы, ветеран, хәтер, кыю, батыр, патриот, парад.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Марш» (Р.Еникеев көе), слайдлар, «Хәтер» китабы, «Хәтер көне» күргәзмәсе, чәчәкләр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Көй тыңлау: «Марш» (Р.Еникеев көе).
2. Бөек Ватан сугышы геройлары турында слайдлар карау.
3. Сугышта катнашкан ветераннар чыгышы.
4. Җиңү көненә багышланган шигырьләр тыңлау (4 – 5 бала сөйли).
5. «Хәтер китабы» белән танышу (илебезнең тынычлыгын саклаучы солдат һәм офицерларның кыю, батыр, курку белмәс һәм үз илен, үз халкын яратучы чын патриот булулары турында сөйләшү).
6. «Хәтер көне» дигән рәсем күргәзмәсен карау.
7. Бөек Ватан сугышы ветераннарына чәчәкләр бирү.

### Тема. Шигырь уку: Э.Шәрифуллина. «Минем бабай»

**Бурычлар:**

1. Балаларда патриотик хисләр, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.

2. Шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәсен үстерү.

3. Балаларның бу шигырь аша Бөек Ватан сугышы геройлары турында күзаллауларын киңәйтү.

**Сүзлек:** разведчик, немец тылы, баһадир, ветеран.

**Җиһазлар:** слайдлар, рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 525 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Бөек Ватан сугышы геройлары турында слайдлар карау.

2. Балаларга сораулар:

- Нәрсә ул Җиңү көне?
- Ни өчен һәр елны зурлап билгеләп үтәләр?
- Кемнәр ул ветераннар?
- Сезнең ветеран бабаларыгыз бармы?
- Сез аларны ничек хөрмәтлисез?

3. Шигырь уку: Э.Шәрифуллина. «Минем бабай».

4. Балаларга сораулар:

- Бабай сугышта кем булган?
- Орден, медальләрне бабайга ни өчен биргәннәр?
- Бабай нинди уйлар белән сугышка кергән?
- Җиңү безгә нәрсә китерде?

5. Мәкальләр, әйтемнәр.

а) Ватанга хезмәт – үзеңә хөрмәт.

б) Илнең күрке – тынычлык.

в) Илдә яшисең икән – илеңә хезмәт ит.

г) Ил тыныч булса, без дә тыныч.

Өйдә әти-әниләр белән өйрәнгән мәкаль-әйтемнәрне искә төшерү, аларның эчтәлекләре буенча фикер алышу.

6. «Кем җитез, кем кыю» уены.

Балалар берничә командага бүленә һәм аларга төрле биремнәр бирелә. Беренче булып һәм күбрәк җавап бирүче команда җиңүче була.

## Проект. Чәчәкләр – тормыш яме

### Тема. Уен-викторина. «Чәчәкләр – тормыш яме»

**Бурычлар:**

1. Чәчәкләргә сакчыл караш, туган як табигатен өйрәнү теләге тәрбияләү.

2. Мөстәкыйль фикерләү, фикерне бер юнәлештә туплый

белү сәләтен үстерү.

3. Балаларның чәчәкләр турындагы белемнәрен баету, чәчәкләрне танып белергә, тасвирлап сөйләргә өйрәтү.

**Сүзлек:** энҗе чәчәк, ак чәчәк, тукранбаш, хушбуй, таҗ, мохтаҗ, ышык.

**Җиһазлар:** рәсемнәр, слайдлар, лото.

## Эшчәнлек барышы

1. «Яз килде» уены (лото ярдәмендә).

Балалар яз билгеләренә туры килгән рәсемнәрне тәртип буенча тезеп чыгалар һәм аның турында сөйлиләр.

2. Табышмак:

Төрле-төрле төстә алар,
Бу төсләр каян килгән?
Хушбуй исе аңкыталар,
Кем аны сөртеп йөргән?
Алар нәрсәләр? (Чәчәкләр)

3. Тәрбияче хикәясе (слайдлар, рәсемнәр ярдәмендә).

Яз, җәй көннәрендә, иртә көздә кырларда, болыннарда, урманнарда, бакчаларда чәчәкләр үсә. Алар төрле, чөнки аларның яшәү шартлары бер-берсеннән аерылып тора. Урманда үскән ак чәчәк (ромашка) эре, аның таҗ яфраклары киң була. Ә кырда үскән ак чәчәк вак, таҗ яфраклары тар була. Ни өчен? Чөнки кырда дым аз, ә урманда күп. Урман чәчәкләре ышыкта үсә ...

4. Фикер алышу:

- Кырда, басуда үсә торган чәчәкләрне ничек атыйлар?
- Кыр, урман чәчәкләрен кем тәрбияли?
- Бакча гөлләре нинди шартларда үсә?
- Нинди бакча гөлләрен беләсез?
- Нинди кыр чәчәкләрен әйтә аласыз?
- Урманда нинди чәчәкләрне очратырга мөмкин?
- Чәчәкләрне күп итеп өзәргә ярыймы? Ни өчен?

5. Уен-викторина «Мин кайда үсәм?»

Болын, урман, кыр, чәчәк клумбасы сурәтләнгән зур рәсемнәр эленә. Балалар таратылган чәчәкләрдән берне сайлап алалар, аның турында сөйлиләр һәм урынына урнаштыралар.

6. Җырлы уен «Түгәрәк алан».

Бу аланда чәчәкләр күп,
Кыймыйм ләкин өзәргә.
Умырзая, умырзая,
Чык әле син биергә.

Балалар түгәрәккә басалар, аларга чәчәк исемнәре кушыла. Балалар җырлап, түгәрәк буйлап йөриләр. Исемен ишеткән бала уртага чыгып бии.

## Проект. Алдакчы, саран булма!
### Тема. Хикәя уку: Н.Фәттах. «Велосипедлы Мөнир»

**Бурычлар:**

1. Балаларда саранлыкка кире мөнәсәбәт тәрбияләү.

2. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтара белү күнекмәсен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.

3. Балаларга хикәя геройларына дөрес бәя бирергә ярдәм итү, каршылыкларны мөстәкыйль рәвештә чишәргә өйрәтү.

**Сүзлек:** кырт кисеп, ияр, кыйшайды, коты алынган, зырылдап.

**Җиһазлар:** хикәя эчтәлегенә туры килгән иллюстрацияләр.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Иң матур сүз», 120 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Мәкаль: Кешегә чокыр казысаң, үзең төшәрсең.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Хикәя уку: Н.Фәттах. «Велосипедлы Мөнир».

3. Балаларга сораулар:

- Мөниргә әтисе кибеттән нәрсә алып кайткан?
- Мөнир Илдуска велосипедында йөреп карарга ни өчен рөхсәт иткән?
- Мөнир Илдуска нәрсә вәгъдә иткән?
- Мөнир вәгъдәсен үтәгәнме?
- Ни өчен Илдус Мөнир ташлап киткән?
- Ни өчен велосипедның тизлеге арткан?
- Мөнир ни өчен тормозга басмаган?
- Мөнир куркуыннан кемне искә төшергән?
- Ни өчен велосипедыннан егылып төшкән Мөнир янында берәү дә булмаган?

- Сез хикәяне ничек тәмамлар идегез?
- Сез кайсы малай яклы?

4. Тизәйткеч ятлау. [с] авазы.

Саран Сара
Саный-саный,
Сарыгына салам сала.

Саран гына
Сарыгына
Саламны да
Санап сала.

5. Үртәвеч:

Саран, саран,
Сагынсам да бармам.

# Комплекслы-тематик план

## Мәктәпкә әзерлек төркеме

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| 1. Белем бәйрәме | Мәктәпкә экскурсия. «Исәнме, мәктәп!»<br>Әңгәмә. «Белем бәйрәме»<br>Хикәя уку: М.Хәсәнов. «Сара мәктәпкә бара» | 1<br>1<br>1 |
| 2. Аралашу әдәбе | Әңгәмә. «Тәмле сүз – җан азыгы»<br>Хикәя эчтәлеген сөйләү: В.Осеева. «Тылсымлы сүз» | 1<br>1 |
| 3. Туган ягым – яшел бишек | «Минем туган җирем»<br>Әңгәмә. «Минем гүзәл халкым»<br>«Туган ягым язучылары»<br>«Татарстан буйлап сәяхәт»<br>Әңгәмә. «Чал тарихлы Казаным»<br>Шигырь уку: Ә.Синегулов. «Татарстан җирләре» | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 4. Абдулла Алиш иҗаты | А.Алиш иҗаты белән танышу.<br>Әкиятнең эчтәлеген сөйләү. «Сертотмас үрдәк» | 1<br>1 |
| 5. Алтын көз! | Урман почмагына экскурсия.<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Алтын көз»<br>Шигырь ятлау: М.Җәлил. «Көз житте» | 1<br>1<br>1 |
| 6. Яшелчә, җиләк-җимеш | «Бакчада көзге эшләр»<br>Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Мин уңыш җыйдым»<br>Шигырь уку: Х.Халиков. «Дәү әнием – бакчачы»<br>«Көз күчтәнәчләре»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге эшләр»<br>Шигырь уку: Н.Мадьяров. «Балан» | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 7. Икмәк – яшәү терәге | «Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә»<br>Картина карау. И.Шишкин. «Арыш басуы»<br>Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Ашлар солтаны» | 1<br>1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 8. Гаилә һәм йорт җиһазлары | «Минем өем, өй җиһазлары»<br>Әңгәмә. «Нәрсә ул электр һәм электр җиһазлары?»<br>Иҗади хикәя төзү. «Тату гаилә»<br>Шигырь уку: З.Туфайлова. «Минем гаиләм» | 1<br>1<br><br>1<br>1 |
| 9. Ашамлыклар һәм савыт-саба | Ашханәгә экскурсия.<br>Әңгәмә. «Кунак чакырдык»<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү: С.Сәүбәнова. «Ботка нигә тәмле?» | 1<br>1<br>1 |
| 10. Милли киемнәр | Танышу уены. «Әбиемнең серле сандыгы»<br>Чагыштырып хикәя төзү. «Кием кешене бизи»<br>Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Кәләпүшем, кәләпүш» | 1<br><br>1<br><br>1 |
| 11. Кыш. Кышкы уеннар | Паркка экскурсия. «Килеп җитте матур кыш»<br>Әңгәмә. «Паркта минем күргәннәрем»<br>Шигырь ятлау: Г.Латыйп. «Кыш килде»<br>«Боз һәм бозлыклар»<br>Иҗади хикәя төзү. «Кышкы уеннар»<br>Язма сөйләм. «Кыш бабайга хат» | 1<br><br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 12. Кыргый хайваннар | «Кайда, ничек кышлыйлар?»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Кыш. Тиеннәр» | 1<br>1 |
| 13. Кышлаучы кошлар | Кошларны күзәтү. «Безнең канатлы дусларыбыз»<br>«Кошларга ярдәм итик»<br>Калмык халык әкиятен уку: «Күңелле чыпчык белән күңелсез карга» | 1<br><br>1<br>1 |
| 14. Йорт хайваннары һәм кошлары | «Авылда ишегалды»<br>Картина буенча хикәя төзү: «Йорт хайваннары. Ат белән колын»<br>Әкиятнең эчтәлеген сөйләү: «Үрдәк беренчелекне алган» | 1<br>1<br><br>1 |
| 15.Транспорт, юл йөрү кагыйдәләре | «Транспорт төрләре белән танышу»<br>Әңгәмә. «Юл йөрү кагыйдәләре кирәк безгә һәркөнне»<br>Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Светофор» | 1<br>1<br><br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 16. Һөнәрләр | Балалар бакчасы буйлап сәяхәт: «Безне җырларга кем өйрәтә?»<br>Әңгәмә. «Әти-әниләр һөнәре»<br>Шигырь уку: Э.Мөэминова. «Фокусчы»<br>Укытучы хезмәте белән таныштыру: «Укытучы» | 1<br><br>1<br>1<br>1 |
| 17. Мультфильмда кунакта | Әкиятне дәвам итеп сөйләү. «Күчтәнәч»тә кунакта»<br>Әңгәмә. «Әкиятләр иленә сәяхәт» | 1<br><br>1 |
| 18. Мин дөньяның бер кешесе | Әңгәмә. «Мин бәхетле – мин хокуклы»<br>«Тигез хокук белән яшик бу җирдә» | 1<br>1 |
| 19. Мин һәм минем сәламәтлегем | Шифаханәгә (шәфкать туташы бүлмәсенә) экскурсия. «Шәфкать туташы»<br>Фикер алышу: «Сәламәтлек – зур байлык»<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү: В.Монасыйпов. «Шифалы табиблар» | 1<br><br><br>1<br><br>1 |
| 20. Муса Җәлил. Ил сакчылары | «Кемнәр алар – ил сакчылары»<br>«Муса Җәлил – бөек шагыйребез» (Сәхнәләштерү: М.Җәлил. «Карак песи»)<br>Шигырь уку: Р.Корбан. «Җәлил турында җыр» | 1<br>1<br><br><br>1 |
| 21. Халыкара телләр көне | Фикер алышу. «Дуслык – бөек көч»<br>Әңгәмә. «Россия – безнең илебез»<br>Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Сөйләшсәләр безнеңчә» | 1<br>1<br>1 |
| 22. Бүлмә гөлләре | Тәҗрибә үткәрү. «Ни өчен орлыкларны, үсемлекләрне балчыкка утырталар»<br>Хикәя төзү: «Кактус белән фикус гөлен чагыштыру»<br>Шигырь уку: Ә.Габиди. «Минем гөлләрем» | 1<br><br>1<br><br>1 |
| 23. Ямьле яз | Паркка экскурсия. «Туган якка яз килде»<br>Эчтәлекле рәсемнәр сериясе буенча хикәя төзү. «Яз. Сыерчыклар»<br>Шигырь уку: Н.Мәдьяров. «Көләч яз»<br>Күзәтү: «Ак болытлар ага зәңгәр күктә» | 1<br><br>1<br><br>1<br>1 |

| | | |
|---|---|---|
| 24. Исән-месез, кошкайлар | «Күчмә кошлар безгә яз алып килде»<br>Шигырь ятлау. Г.Юнысова. «Кара» | 1<br>1 |
| 25. Урман. Кызыл китап | «Нәрсә ул Кызыл китап?»<br>Әңгәмә. «Урман – безнең байлыгыбыз»<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү. Р.Төхвәтуллин. «Шомырт нигә елый?»<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү: М.Пришвин. «Алтын болын» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 26. Китап кайдан килә | Китапханәгә экскурсия<br>Бирелгән сүзләрдән хикәя төзү: «Китап кибете»<br>Шигырь уку: Х.Халиков. «Китап докторы» | 1<br>1<br>1 |
| 27. Космос | «Нәрсә ул Кояш системасы?»<br>Әңгәмә. «Космонавтика көне»<br>Шигырь уку: Йолдыз. «Сәлам, галәм!» | 1<br>1<br>1 |
| 28. Спорт | «Казанда Универсиада»<br>Рәсем буенча хикәя төзү. «Спорт мәйданчыгында»<br>Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Зарядкага бас» | 1<br>1<br>1 |
| 29. Г.Тукай иҗаты | Әдәби викторина: «Мультфильмда кунакта»<br>Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Кызыклы шәкерт»<br>Шигырь уку: Г.Тукай. «Эш беткәч, уйнарга ярый»<br>«Г.Тукай һәм балалар» | 1<br>1<br>1<br>1 |
| 30. 9 май – Җиңү көне | Ветераннар белән очрашу. «Алар безгә Җиңү бүләк итте»<br>Хикәянең эчтәлеген сөйләү: Л.Кассиль. «Күңелләрдә мәңге сакланыр» | 1<br>1 |
| 31. Хуш бакчам, исәнме, мәктәп! | «Без барабыз мәктәпкә»<br>Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Һәркем эштә»<br>Шигырь ятлау: Б.Рәхмәт. «Мәктәпкә» | 1<br>1<br>1 |

# Проект. Белем бәйрәме

## Тема. Мәктәпкә экскурсия. «Исәнме, мәктәп!»

**Бурычлар:**
1. Балаларда мәктәп турында уңай мөнәсәбәт тәрбияләү.
2. Мәктәпкә бару теләген формалаштыру.
3. Укучы, укытучы, дәрес, тәнәфес сүзләре белән таныштыру.

**Сүзлек:** укытучы, укучы, тәнәфес, кыңгырау, сыйныф бүлмәсе.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Эче тулы балалар,
Парталар һәм такталар.
Бик тырышып белем бирә
Абыйлар һәм апалар. (Мәктәп)

2. Мәктәп белән танышу (сыйныф бүлмәсен, мәктәп китапханәсен, ашханә, спорт бүлмәләрен һ.б. карау).

3. Балаларга сораулар:
- Ни өчен 1 нче сентябрьне «Белем бәйрәме» дип атыйлар?
- Мәктәпкә баручы балаларның кәефе нинди?
- Мәктәп балаларны ничек каршылый?
- Балаларга белемне кем бирә?
- Укучы сумкасынданиләр бар? Беләсезме?
- Беренче сыйныф укучысы нинди булырга тиеш?

4. Кыңгырауның ни өчен кирәклеген аңлату:

Үзе кечкенә генә,
Ә тавышы яңгырау.
Дәрескә дәшеп,
Чыңлый ... (Кыңгырау)

5. 1 нче сыйныфта дәрестә катнашу.

## Тема. Әңгәмә. «Белем бәйрәме»

**Бурычлар:**
1. Балаларда белем алырга омтылыш тәрбияләү.
2. Логик фикерләү сәләтен, хәтерне үстерү.

3. Балаларны мәктәп тормышы белән таныштыруны дәвам итү, алган белемнәрен системалаштыру.

**Сүзлек:** укучы, укытучы, мәктәп, белем, кыңгырау, глобус.

**Җиһазлар:** интерактив такта, рәсемнәр, сюжетлы-рольле уен өчен кирәк-яраклар, «Укытучы» рәсеме, туп.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 156 бит.

## Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: М.Әхмәтгалиев. «Беренче көн».

2. Үстерешле диалог.

- 1 нче сентябрь ул нинди бәйрәм?
- Без сезнең белән бәйрәмдә нәрсәләр күрдек?
- Беренче тапкыр мәктәпкә килгән балалар нинди иделәр?
- Сезгә бәйрәмдә нәрсә ошады?
- Беренче дәрестә утырганда нинди тойгылар кичердегез?
- Кыңгырау тавышы нәрсә турында хәбәр итә?

3. «Урынын тап!» уены (интерактив тактада яки рәсемнәр ярдәмендә).

Балаларга мәктәптә укытучы һәм китап кибетендә кибетче төшерелгән рәсемнәр таратыла. Уку әсбаплары һәм китап кибетендәге әйберләр буталып бирелә. Бала шул әсбапларның һәм әйберләрнең дөрес итеп урынын билгели. Мәсәлән: мәктәп – глобус, такта, указка, акбур, укучылар, укытучы һ.б.; китап кибете – китап киштәсе, касса, китаплар, кибетче, сатып алучылар һ.б.

4. Проблемалы ситуацияләр чишү: «Белмәсәң бел!»

- Мәктәпкә йоклап калмас өчен нишләргә кирәк?
- Яхшы билгеләр алыр өчен нишләргә кирәк?
- Мәктәптә кәефең күтәренке булсын өчен нишләргә кирәк?
- Әти-әниеңне сөендерер өчен нишләргә кирәк?
- Мәктәптән кайткач, иң элек нишләргә кирәк?

5. Дидактик уен. «Җөмләне тәмамла!» (туп ярдәмендә).

а) Балалар мәктәпкә ... (баралар).

б) Аларны укытучы ... (каршылый).

в) Балалар мәктәптә ... (укыйлар һ.б.).

г) Укытучы апа ... (ягымлы һ.б.).

д) Мәктәп бинасы ... (матур һ.б.).
е) Балалар мәктәптән ... (кайталар).
6. Үстерешле уен «Бирелгән сүзләрдән дөрес җөмлә төзе!»
а) Малай, бүген, бара, мәктәпкә.
б) Бара, мәктәпкә, озата, әнисе, кызны.
в) Каршылый, аларны, укытучы.
г) Чәчәк, тоткан, кулына, укучы.
7. «Киресенчә әйт!» уены (тукмак тәгәрәтү).
Мин әйтәмен «югары»,
Син әйтәсең ... («тәбәнәк»).
Мин әйтәмен «бик куркак»,
Син әйтәсең ... («бик батыр») һ.б.
8. Сюжетлы-рольле уен «Мәктәп».

## Тема. Хикәя уку: М.Хәсәнов. «Сара мәктәпкә бара»

**Бурычлар:**
1. Халык авыз иҗаты аша балаларда белемгә омтылыш тәрбияләү.
2. Балаларда әдәби әсәрләрне тыңлый белү сәләтен үстерү.
3. Хикәя эчтәлеге буенча сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирүләренә ирешү.
**Сүзлек:** ак алъяпкыч, сандал, белем.
**Җиһазлар:** аудиоязмада «Сара мәктәпкә бара» җыры (Б.Рәхмәт сүзләре), схема-рәсемнәр.
**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 534 бит.

### Эшчәнлек барышы
1. Хикәя уку: М.Хәсәнов. «Сара мәктәпкә бара».
2. Балаларга сораулар:
- Ишек алдында нинди яңалык ишеткәннәр?
- Бала-чагалар ни өчен тынып калганнар?
- Сара ничек киенгән?
- Сара ни өчен иптәшләре белән уйный алмам дип уйлаган?
- Сез мәктәпкә ничек итеп әзерләнер идегез?
3. Җыр тыңлау: «Сара мәктәпкә бара» (Б.Рәхмәт сүзләре).

Иртәгә Сара
Мәктәпкә бара,
Кара син аның
Сумкасын, кара.
Әлифбасы да
Бар сумкасында,
Рәсемнәре бар –
Матур барысы да.
Шатланган нинди,
Җырлый да бии.
«Мәктәпкә барам
Иртәгә мин»,- ди.

4. Мәкаль:
Беләге юан берне егар,
Белеме булган меңне егар.
Эчтәлеге буенча фикер алышу.
5. Мәкаль буенча пиктограмма ясау (балалар эшчәнлеге).

## Проект. Аралашу әдәбе

### Тема. Әңгәмә. «Тәмле сүз – җан азыгы»

**Бурычлар:**

1. Уй-фикерләрен, уйларын тартынмыйча, үз сүзләре белән сөйләп бирү һәм тыңлый белү күнекмәләрен тәрбияләү.
2. Балаларның көнкүрешкә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен үстерү.
3. Балаларны төрле ситуацияләрне бәяләргә, аңлаешлы итеп әйтә белергә, катлаулы булмаган нәтиҗәләр ясарга өйрәтү.

**Сүзлек:** мәрхәмәтле, юмарт.

**Җиһазлар:** «Өч кыз» мультфильмы.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку:
Тәмле сүзеңне кызганма,
Син, дустым, сөйләшкәндә.
Ягымлы һәм мөлаем бул,
Кешегә эндәшкәндә.
2. Мәкаль:
Татлы тел тимер капканы ачар.
Эчтәлеге буенча фикер алышу.
3. Хикәя уку: Ф.Бәдретдин. «Рәхмәт».
«Рәхмәт!», «Рәхмәт яусын!», «Рәхмәтләр яусын!» – бик тәмле

сүзләр. Син аларның тәмен үзең дә беләсең, чөнки үзеңә генә аталганнарын гел-гел ишетеп торасың. Ә менә тиешле урында үзең дә рәхмәт әйтә бел. Берәрсе иелеп ботинка бавыңны бәйләсә – рәхмәт әйт. Әниең белән син килеп керүгә автобуста кемдер сикереп торып урын бирсә: «Рәхмәт!»- диген. Өйдә дә, урамда да, бакчада да кемнәрдер сиңа гел яхшылык эшләп тора бит. Берсен дә рәхмәтсез калдырма. Алар: «Дәү үс!»- диярләр. Көненә утыз мәртәбә: «Дәү үс!»- дисәләр, ай үсәсен көн үсә башлыйсың әле ул. Чынлап. Ышанмасаң, сынап кара.

4. Фикер алышу:

- Нәрсә ул тәмле сүз?

- Ни өчен тәмле сүз дип атыйлар?

- Сез нинди тәмле сүзләр беләсез һәм аны кайда кулланасыз?

- Нинди әкият геройлары үзләренең мәрхәмәтлелеге һәм тәмле телле булуы белән кыен хәлләрдән җиңеп чыга?

- Кәҗә кайсы әсәрдә рәхмәт әйтеп сакалын селкетә һәм ни өчен?

- Украин халкының «Башак» әкиятендәге әтәч турында нинди матур сүзләр әйтеп була?

- Татар халкының «Өч кыз» әкиятендәге иң кече кызга нинди мактау сүзләре әйтер идең?

5. «Капма-каршы әйт!» уены. Мәсәлән: «Төлке һәм торна» әкиятеннән яхшы һәм начар сыйфатларны әйтергә.

а) Кунакка чакырышу – яхшы.

б) Ачу саклау – начар.

Үрнәк: Яхшы – начар, тырыш – ялкау, дус – дошман, юмарт – саран һ.б.

6. Җырлы-биюле уен «Наза». [з] хәрефе.

Балалар, парлашып, бер-бер артлы тезелеп басалар. Бер бала парсыз, ул уенчылар каршысына чыгып баса.

Наза дигән кыз баланың
Бөрлегәне түгелгән.
«Наза» дигән уенны без
Уйныйбыз чын күңелдән.

Кушымта: Наза, Наза,
Наза – матур кыз бала.
Наза тырыш, уңган бала,
Зирәк, акыллы бала.

7. «Өч кыз» мультфильмын карау.

## Тема. Хикәянең эчтәлеген сөйләү: В.Осеева. «Тылсымлы сүз»

**Бурычлар:**

1. Матур әдәбият аша балаларның сөйләмендә ягымлы сүзләр куллануларына ирешү.
2. Балаларның хәтер сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.
3. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген дөрес интонация белән сөйләү күнекмәсе тәрбияләү.

**Сүзлек:** тылсымлы, тупас, зинһар, гаҗәпсенеп, тылсымчы, басынкы.

**Җиһазлар:** туп.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 266 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Теле татлының дусты күп.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Хикәя уку: В.Осеева «Тылсымлы сүз».

3. Балаларга сораулар:

- Ни өчен Павликның кәефе юк?
- Ак сакаллы бабай аңа нинди тылсымлы сүз әйткән?
- Павлик тылсымлы сүзне ничек сынап караган?
- Тылсымлы сүз ничек булышкан?

4. Хикәянең эчтәлеген сөйләү (6 – 7 бала сөйли).

5. Сүзле уен «Ягымлы сүзләр» (туп белән).

6. Җырлы-биюле уен «Куш кулым».

Урман буйларына менәм,
Урман буе ямьлегә.
Бир кулыңны, мин дә бирәм
Дус булырга мәңгегә.
Менә сиңа уң кулым,
Менә сиңа сул кулым.

Син бит минем якын дустым,
Менә сиңа куш кулым.
Алма бакчасына кереп,
Алма ашыйсым килә.
Син алмасы, мин чәчәге
Булып яшисем килә.

## Проект. Туган ягым – яшел бишек
### Тема. «Минем туган җирем»

**Бурычлар:**

1. Туган шәһәребезгә (авылыбызга) карата горурлык хисе тәрбияләү.
2. Үстерелешле диалог, сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.
3. Балаларның Ватаныбыз, республикабыз (шәһәр һәм авыл) һәм аның символикасы турындагы мәгълүматларын арттыру.

**Сүзлек:** хат, тугра.

**Җиһазлар:** слайдлар, фотосурәтләр, хат, аудиоязма, тугра.

**Эшчәнлек барышы**

1. Хат уку:

Тәрбияче: «Исәнмесез, балалар! Сезгә Мәскәү балалары хат яза. Без ... шәһәренә (авылына) үзебезнең дусларыбыз янына танышырга килмәкче идек. Сезнең туган шәһәрегез (авылыгыз) белән якыннанрак танышасыбыз килә. Зинһар өчен, булышыгыз әле, балалар!» Балалар, Мәскәү дусларыбызга булышабызмы?

2. Җавап хаты (слайдлар яки рәсемнәр ярдәмендә):

- Хатны ничек башлар идегез?
- Без нинди республикада яшибез?
- Башкалабыз ничек атала?
- Без нинди шәһәрдә (авылда) яшибез?
- Республикабызның тагын нинди шәһәрләрен беләсез?
- Шәһәребездә (авылыбызда) нинди истәлекле, күренекле урыннар бар?
- Шәһәребез (районыбыз) туграсында нәрсә сурәтләнгән, алар нинди төстә, нәрсә аңлата?
- Безнең шәһәр (авыл) нинди елга (тау, урман) буена урнашкан?

3. Балалар эшчәнлеге (алдагы сорауларны кулланып).

Балалар сөйләгәнне тәрбияче язып бара. Кирәк булган очракта, тәрбияче үрнәк бирә.

4. Тел шомарткыч «Борылма». [б] авазы.

| | |
|---|---|
| Бу елгада | Борылма дип |
| Борылма да | Юлдан кире |
| Борылма. | Борылма. |

5. Дидактик уен «Бу урынны таныйсыңмы?» (рәсемнәр белән).

Шәһәрнең яисә авылның матур күренешләре, истәлекле урыннары төшерелгән рәсемнәр күрсәтелеп оештырыла.

6. Җыр тыңлау (туган җир, шәһәр, авыл турында).

## Тема. Әңгәмә. «Минем гүзәл халкым»

**Бурычлар:**

1. Туган җиреӊ, халкыӊ, телеӊ белән горурлану хисе тәрбияләү, Татарстанда яшәгән башка халыкларның мәдәниятен хөрмәтләү.

2. Балаларда халкыбызның туган җиренә, теленә, үткәненә, тарихына, мәдәниятына кызыксыну үстерү.

3. Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл кулланырга өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** рәссам, композитор, җырчы.

**Җиһазлар:** рәсемнәр, яшел яулык.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Халыкның бер йорты бар:
Ул да булса – туган ил.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. «Башын мин әйтәм, ахырын син әйт!» уены:

а) Кош канаты белән, ... (кеше дуслары белән көчле).

б) Дустың булмаса, эзлә, ... (тапсаң югалтма).

в) Күмәк күтәрсә – ... (күлне күчерер).

г) Ялгыз агачны ... (җил сындыра).

3. Дидактик уен «Мин сөйлим, син танып әйт!» (рәсемнәр буенча).

Тәрбияче балаларга төрле милләт вәкилләренең (татарлар, чувашлар, руслар, удмуртлар, марилар, башкортлар, мордвалар) тормыш-көнкүреше, милли ризыклары, киемнәре, яратып уйный торган уеннары һәм бәйрәмнәре турында сөйли. Балалар,

шулардан чыгып, тәрбияченең кайсы милләт халкы турында сөйләвен билгеләргә тиешләр.

4. Викторина. «Күренекле шәхесләр».

- Милләтебезнең сандугачлары (җырчылары) кемнәр ул?
- Татарстанда яшәүче нинди рәссамнарны беләсез?
- Татарстанның нинди күренекле композиторлары бар?
- Нинди татар язучыларын беләсез?
- Спортта зур уңышларга ирешкән шәхесләрне беләсезме?

5. Җырлы уен «Яшел яулык» (татар халык уены).

Балалар түгәрәк ясап басалар. Кулларын артка куялар. Санамыш ярдәмендә яулык салучы билгеләнә. Аның кулында кульъяулык. Ул, түгәрәктән чыгып, җырлап йөри:

Кульяулыгым яшел, яшел,<br>
Яшел чирәм астында.<br>
Сиздермичә ташлап китәм<br>
Бер иптәшем артына.

Сүзләрне әйткәндә, бер баланың уч төбенә яулыкны калдырып китә, үзе түгәрәк эченә кереп баса. Яулыклы бала, тиз генә артка чыгып, сүзләрне әйтә-әйтә, уенны дәвам итә. Әгәр ул тоткарланып торса яки яулык салганны сизмәсә, аңа җәза бирелә.

## Тема. «Туган ягым язучылары»

**Бурычлар:**

1. Балаларда язучыларыбыз иҗатына карата кызыксыну уяту, аларга карата ихтирам тәрбияләү.
2. Табышмак, мәкальләр ярдәмендә логик фикерләү, хәтер сәләтен үстерү.
3. Сорау – җавап тибында аралашу вакытында баланы булган белемнәренә таянып фикер йөртергә, гомумиләштерергә, аерым карарга килергә һәм берләштерергә өйрәтү.

**Сүзлек:** викторина, белем чишмәсе.

**Җиһазлар:** тартма, рәсемнәр.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Тавышсыз, кулсыз булса да,
Күп сүзле, күп рәсемле.
Нинди тылсымлы әйбер ул?
Син, дускай, беләсеңме? (Китап)

2. Мәкальләр:

а) Китап – һәр кешенең якын дусты. Ул һәркемгә дә кирәк.

б) Китап – белем чишмәсе.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

3. Әдәби викторина:

- Сезгә нинди әкиятләр, хикәяләр, шигырьләр ошый?
- Аларны кемнәр яза? (Язучылар, шагыйрьләр)
- Сез нинди язучыларны беләсез?
- Өйдә нинди әкиятләр, хикәяләр укыйсыз?
- Иң яраткан әкият, хикәягез бармы?

4. Дидактик уен «Тылсымлы тартма» (рәсемнәр белән).

Тартмада таныш әкиятләргә, шигырьләргә иллюстрацияләр салынып куела. Балалар шул тартмадан кулларына алган рәсемнәрнең кайсы әсәрдән икәнен һәм кем язганын аңлаталар.

5. Төбәк язучылары һәм шагыйрьләре белән танышу:

Төбәк язучылары һәм шагыйрьләре (мәсәлән: Яр Чаллы шәһәре язучылары – З.Гомәрова, Н.Мәдьяров, М.Сафин, М.Газизов һ.б.) хикәяләреннән һәм шигырьләреннән өзекләр укыла.

6. «Без бәләкәй язучылар» уены:

Балалар үзлектән, берничә тыңланган әкияттән геройлар сайлап алып, бер әкият яки хикәя төзеп сөйлиләр.

## Тема. «Татарстан буйлап сәяхәт»

**Бурычлар:**

1. Татарстан шәһәрләренең (авылларының) үзенә генә хас булган үзенчәлекләрен күрә һәм соклана белү хисе тәрбияләү.
2. Татарстан шәһәрләре (авыллары) турында балаларның белемнәрен киңәйтү, кызыксынучанлыкларын, хәтер сәләтен үстерү.
3. Шәһәрләрнең (авылларның) нәрсә белән данлыклы булулары турында белем бирү.

**Сүзлек:** Түбән Кама, Алабуга, Әлмәт, Чистай.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Мин яратам сине, Татарстан» җыры (Р.Байтимеров сүзләре, Р.Яхин көе), слайдлар, рәсемнәр, альбомнар, туп.

**Эшчәнлек барышы**

1. Җыр тыңлау: «Мин яратам сине, Татарстан» (Р.Байтимеров сүзләре, Р.Яхин көе).

2. Татарстан картасы буенча балаларга сораулар:

- Без нинди республикада яшибез?
- Татарстан Республикасының башкаласы нинди шәһәр?
- Татарстанда тагын нинди шәһәрләр (авыллар) бар?
- Бу шәһәрләр нәрсә белән дан казанган? (Яр Чаллы, Түбән Кама, Чистай, Болгар һ.б.)

3. Татарстан шәһәрләре (авыллары) турында слайдлар яки рәсемнәр, альбомнар карау.

- Болгар җире нәрсә белән танылган? (Изге җир һ.б.)
- Борынгы Болгар шәһәрендә яңарышларны башлап җибәрүче кеше кем? (М.Ш.Шәймиев)

4. Дидактик уен «Сүзләр чылбыры» (Татарстанның шәһәр һәм авыллары исемен әйтү).

Тәрбияче нинди дә булса шәһәр яисә авыл исемен әйтә һәм тупны балага ыргыта. Ул, исемнең соңгы авазына башланган шәһәр яисә авыл исеме әйтеп, тупны тәрбиячегә кайтара. Мәсәлән: Түбән Кама – Арча – Актаныш – Шәмәрдән һ.б.

5. Мәкальләр:

а) Туган-үскән җирдән дә матур җир булмас.
б) Үз илем – үземә кадерле.
в) Туган җирдәй җир булмас, Туган илдәй ил булмас.
г) Туган илем – туган өем.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

6. Җырлы-сүзле уен «Татарстанның елга-күлләре».

Балалар кара-каршы басып, ике командага бүленәләр. Бер команда икенче командага елга исемен әйтеп җырлый-җырлый килә һәм бер баланы алып үз урынына баса. Икенче команда аталмаган елга исемен җырлап командага каршы килеп бер баланы алып китә. Елга исемен әйтә алмаган команда җиңелә.

| | |
|---|---|
| Агыйделнең суларында | Зәңгәр чәчәк җыя-җыя, |
| Ак чиләгем күмелде. | Зәңгәрләттем кулымны. |
| Әйдә, дустым, безнең якка, | Бергә-бергә уйныйк әле, |
| Безнең яклар күңелле. | Бир, дускаем, кулыңны. |

Мәсәлән: Идел, Ык, Мишә, Зөя, Казансу, Чулман, Карабаш һ.б.

## Тема. Әңгәмә. «Чал тарихлы Казаным»

**Бурычлар:**

1. Балаларда тарихи үзаң, башкалабыз Казан турында күбрәк белергә теләк тәрбияләү.
2. Балаларның уй-фикерләү сәләтләрен үстерү.
3. Татарстан Республикасы символикасында төшерелгән рәсемнәрнең, төсләрнең мәгънәсен аңлату.

**Сүзлек:** Ител, ачыргаланып, риваять, Казан, тугра, барс, манара, мәчет.

**Җиһазлар:** Казанның тарихи урыннары турында слайдлар, фотосурәтләр, казан, тугра, байрак, аудиоязмада Татарстан Республикасы гимны.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 290 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Риваять сөйләү: «Казан».

Тәрбияче: Бер кыз, юарга дип алып төшкән казанын Иделгә төшереп җибәргәч, ачыргаланып: «Казан, ай, казан!»- дип кычкырган. Аның үзәк өзгеч тавышын тирә-юньдә яшәүчеләр дә ишеткәннәр. Тиздән бу тирәдә яшәүче халык үзе торган җирне, үсеп килүче каланы «Казан» дип атый башлаган. Бу исем бөтенесенә ошаган. Шул ерак заманнардан бирле безнең башкалабыз Казан дип атала. Исеме казан кебек чыңлап, зыңлап тора.

2. Слайдлар яки фотосурәтләр карау. «Казанның иң тарихи урыннары».

3. Балаларга сораулар. «Тарих буйлап сәяхәт».

- Идел елгасы элек ничек аталган?
- Ител елгасы тирәсендә кайсы милләт кешеләре яшәгән?
- Татар халкы Идел елгасы тирәсендә генә яшәгәнме?

- Аларны ничек атаганнар?

- Алар нинди телдә аңлашканнар, сөйләшкәннәр?

- Халык ничек яшәгән?

4. «Җавабын әйт!» уены.

а) Татар халкының чисталык символы. (Сөлге)

б) Җырларга күчкән елга исеме. (Идел)

в) Татар халкының милли бәйрәме. (Сабантуй)

г) Казандагы күл исеме. (Кабан)

д) Милли татар ризыгы. (Чәк-чәк)

е) Татар халкының ханбикә исемен йөртә изге тарихи, истәлекле урыны. (Сөембикә манарасы)

ж) Казан Кремленың манарасы. (Спас манарасы)

з) Казанның йөзек кашы булган мәчетенең исеме ничек? (Кол Шәриф)

и) Татарстанда дөньякүләм нинди чаралар узды һәм уза?

5. Шигырь уку: Ф.Яруллин. «Татарстан байрагы».

6. Балаларга сораулар:

- Татарстан байрагыниләр сөйли?

- Безнең намус төсебез нинди төстә?

- Яшәү төсе нинди төс?

- Кызыл төстә нәрсә чагыла?

- Татарстан байрагы кайда, кайсы вакытларда эленә?

7. Татарстан Республикасы гимнын тыңлау:

- Гимн нинди вакыйгалар вакытында башкарыла?

- Гимнны ничек тыңлыйлар?

- Ир балалар баш киемен салырга тиешме?

8. Татарстан Республикасының туграсын (герб) карау.

- Татарстан Республикасының туграсында нәрсә сурәтләнгән, ул нәрсәне аңлата?

- Ни өчен Барс канатлы?

- Кашкарый чәчәге нәрсәне аңлата?

- Ни өчен Барс кояш җирлегендә урнашкан?

- Кызыл кояш нәрсәне аңлата?

## Тема. Шигырь уку: Ә.Синегулов. «Татарстан җирләре»

**Бурычлар:**

1. Туган ил, туган йортны ярату, аның белән горурлану хисләре тәрбияләү.
2. Балаларның фикерләү сәләтен, диалогик сөйләм телен үстерү.
3. Әсәрнең төп идеясен аңлый, геройларның кылган эшләренә дөрес бәя бирә белергә өйрәтү.

**Сүзлек:** фонтан, дәрья, приказ, указ, көпшәк.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 374 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Туган ил ул була бер генә,
Туган илнең кадерен бел генә.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Шигырь уку: Ә.Синегулов. «Татарстан җирләре».

3. Балаларга сораулар:

- Автор Татарстанның нинди шәһәрләре турында сөйли?
- Кайсы шәһәрләрдә нефть фонтаннары күренә?
- Самолёттан ул нинди елгаларны күрә?
- Автор бу шигырьне нинди хисләр белән язган?
- Ни өчен бөтен җир шатлыкка күмелгән?

4. Дидактик уен «Мин һәм минем илем» (интерактив такта яки рәсемнәр белән).

Нинди шәһәрләр нәрсә белән дан казана, шул шәһәр рәсемнәре тиешле рәсемгә туры китерелә. Мәсәлән: Яр Чаллы – КамАЗ, Кукмара – итек, Әлмәт – нефть һ.б.

5. «Татарстанда нинди елгалар беләсең?» уены.

Бер адым ясала һәм елга исеме әйтелә. Адым саен шулай кабатлана.

6. «Көлдереш» уены.

Балалар түгәрәкләнеп утыралар һәм бер көлдерүче сайлыйлар.

Указым, указым
Казаннан килгән, приказым:

Алга-артка карамаска,
Елмаймаска, көлмәскә,
Елга, күлгә тимәскә,
Әйе һәм юк димәскә.

Мәсәлән: Чаллыда көпчәк заводыннан кәлүш аласыңмы? Балалар җавабы: Чаллыда көпчәк заводы булмагач, кәлүш ала алмыйм һ.б.

## Проект. А.Алиш иҗаты

### Тема. А.Алиш иҗаты белән танышу

**Бурычлар:**

1. А.Алиш әсәрләре буенча балаларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү.
2. Әкиятләр, хикәяләр ярдәмендә балаларның сөйләм телен үстерү.
3. А.Алиш китаплары һәм иллюстрацияләр аша әсәрләрен искә төшерү, сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** начар хәл, атна, оста.

**Җиһазлар:** А.Алиш әкиятләре һәм иллюстрацияләр, «Тукмар белән Чукмар» мультфильмы.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку: А.Алиш. «Үзем турында җыр».

Әйтсәләр дә: барып тор син, дип,
Дөньяның иң рәхәт җиренә.
Әйтер идем: кирәк түгел, дип,
Кайтам мин, дип, туган илемә.
Сатмас егет илен алтын-көмешләргә,
Әгәр югалтмаса вөҗданын;
Алтынны ул чүпкә санар,
Иң кыйммәтле күрер Ватанын.

(А.Алиш турында кыскача мәгълүмат).

2. Үстерешле уен «Бу кайсы әкият герое?» (А.Алиш әкиятләре буенча рәсемнәр яки слайдлар карау).

3. «Тукмар белән Чукмар» мультфильмын карау.

4. «Башын әйтәм, азагын тап!» уены.

а) Бала – бәгырь ... (җимеше).

б) Бала күргәнен ... (эшләр).

в) Балалы кеше – ... (бай кеше).

г) Хикмәт – ... (тәрбиядә).

д) Иркә бала ... (ир булмас).

е) Үзе егылган бала ... (еламас).

5. Зиһен үстерешле уен «Уйла һәм әйт!»

«Менә сине куркытучы нәрсә шушы инде»,- дигән. («Бикбатыр белән Биккуркак»)

«Инде һәрвакыт әти-әни сүзен тыңлармын»,- дигән. («Бик яхшы сабак алды ябалак»)

«Аягың төзәлгәч, киез итекләрне инде салкын көннәрдә бер дә салма, әниеңнең сүзен тыңла, тагын начар хәлгә калма»,- дигән. («Куян кызы»)

«Ишеттеңме бер яңа хәбәр? Сиңа гына сер итеп сөйлим»,- дип башлап җибәрә торган булган ул сүзен. («Сертотмас үрдәк»)

«Осталарның да остасы икәнсең, мондый шәп савытны ничек ясый алдың?- дигән. («Ялкаулык – хурлык, тырышлык – зурлык»)

«Борыныма кадәр барып җитә, димәк, чебеннәргә моннан соң көн бетә»,- ди. («Койрыклар»)

«Батырның тавыш-тыны юк, өенә бикләнде, ахры»,- дип көлделәр. («Мактанчык чыпчык белән тыйнак сыерчык»)

«Ай, кызым Гөлгенәм килгән икән, бик сагындырдың, бер атна бит инде сине күргән юк»,- диде. («Әбиләрдә кунакта»)

«Батам, батам, коткарыгыз»,- дигән. («Алдакчы Наил»)

«Табигатьтә барысы да кирәкле, улым,- диде ачылып килә торган офык читенә күз төшереп». («Кемгә кирәк, кемгә кирәкми»)

«Син акыллым, ашны да аз ашыйсың, вакытында йокламыйсың, һавада уйнамыйсың, ахры, шуңа күрә бик ябык, буең да кечкенә, шунлыктан велосипедка да аягың җитми, хәзергә өеңә кайтып тор, зур үскәч килерсең»,- дигәннәр. («Каз белән аккош»)

6. Хәрәкәтле уен «Төлке һәм казлар».

Мәйданчыкның бер башында – казлар өе, икенчесендә көтүче өе билгеләп куела. Бу өйдән читтәрәк – төлке өе; буш урын – болын була.

- Казлар, казлар!
- Га-га-га!
- Ашыйсыгыз киләме?
- Бик килә, шул, бик килә!
- Алай булса, кайтыгыз!
- Без бит кайта алмыйбыз,
Тау астында төлке бар,
Ул безне тотып ашар.
- Сезнең бар канатыгыз –
Очып кына кайтыгыз.

Казлар, канатларын җәеп, болын өстеннән өйгә таба очалар, аларга төлке каршы чыга һәм казларны тотарга тырыша. Тотылган казларны төлке үз өенә алып китә.

## Тема. Әкиятнең эчтәлеген сөйләү.
## А.Алиш. «Сертотмас үрдәк»

**Бурычлар:**

1. А.Алиш әкияте буенча балаларда әхлакый сыйфатлар (серне саклый белү, иптәшләреңне авыр хәлдә калдырмау сыйфатларын) тәрбияләү.
2. Балаларның монологик сөйләм телен үстерү, тыңлап аңлау сәләтен ныгыту.
3. Балаларда әкиятнең төп идеясен аңларга, әкият геройларының кылган эшләренә дөрес бәя бирә белергә һәм әкиятнең эчтәлеген эзлекле итеп сөйләргә өйрәтү.

**Сүзлек:** бүрекле, төкле, сертотмас, гәүһәр.

**Җиһазлар:** рәсемнәр, туп, «Сертотмас үрдәк» мультфильмы.

**Матур әдәбият:** Р.Ш.Халикова. «Раушан көзге», 208 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Рәсемнәр карау (А.Алиш әсәрләре буенча).
2. Әкият уку: А.Алиш. «Сертотмас үрдәк».
3. Балаларга сораулар:

- Йорт хуҗасы, этен ияртеп урманга киткәндә, нәрсә әйтеп калдырган?

- Ни өчен хайваннар хуҗаны эзләргә үрдәкне җибәргәннәр?

- Үрдәк беренче булып нәрсәне очраткан һәм аңа нәрсә сөйләгән?

- Керпе үрдәккә нинди киңәш биргән?

- Керпедән соң үрдәккә нәрсә очраган?

- Аю, хуҗа юктан файдаланып, ни эшләргә уйлаган?

- Бүре хуҗа өенә нинди уй белән киткән?

- Төлке белән үрдәк нәрсә турында сөйләшкән?

- Ни өчен үрдәк һәлакәткә юлыккан?

- Кыргый хайваннар ни өчен хуҗага зыян сала алмаганнар?

- Күп сөйләшү, серне саклый белмәү нәрсәгә китергән?

4. Мультфильм карау: «Сертотмас үрдәк».

5. Әкиятнең эчтәлеген сөйләү (6 – 7 бала сөйли).

6. «Үрдәккә туры китер!» уены.

Уртада зур түгәрәк сызыла. Ул үрдәкләр йөзә торган күл вазыйфасын үти. Түгәрәкнең тышына кара-каршы ике аучы баса, калган балалар үрдәк булып, күл эчендә йөриләр. Ике аучы чиратлашып бер туп белән икесе ике яктан күлдәге үрдәкләргә бәрәләр. Туп тигән үрдәк күлдән чыга бара, ахырда түгәрәк эчендә бер генә бала кала. Аучылар бу үрдәккә чиратлашып ун мәртәбә аталар. Әгәр тидерә алсалар, аучылар җиңүче, тидерә алмасалар, ул бала герой үрдәк була.

## Проект. Алтын көз

### Тема. Урман почмагына экскурсия

**Бурычлар:**

1. Балаларда табигатькә һәм үз исәнлегенә сак караш тәрбияләү.

2. Сөйләшү барышында мәкальләр кулланып, балаларның логик фикерләү сәләтен һәм сөйләм телен үстерү.

3. Тере табигать белән тере булмаган табигать арасындагы бәйләнешләрне аңларга өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** буталчык, куак, сентябрь, октябрь.

Эшчәнлек табигатьтә уза.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак:
Үзе тук була,
Елап яшь коя.
Кошны, гөлләрне
Еракка куа. (Көз)

2. Мәкальләр:
а) Көнгә-көн охшап тумас,
Көн саен кояш булмас.
б) Көзге көннең көлүе,
Көлүе дә елавы.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

3. Үстерешле диалог:

- Бүген һава торышы нинди?
- Күк йөзе нинди төстә?
- Октябрь аендагы табигать торышы сентябрь аендагыдан аерыламы, нәрсәсе белән?
- Иң беренче һәм иң соңгы булып җылы якка нинди кошлар китә?
- Агачларда нинди үзгәрешләр күрәсез?
- Безнең сәламәтлеккә табигатьнең тәэсире нинди?
- Табигать кочагында үзеңне ничек тотарга кирәк?

4. Дидактик уен «Буталчык» (күрсәткән яфракның кайсы агачтан икәнен билгеләү).

5. Хәрәкәтле уен «Кем кая кача?» (үзең качкан куакның яки агачның исемен атау).

## Тема. Рәсем буенча хикәя төзү. «Алтын көз»
### *(И.Н.Мурашковска методикасы буенча)*

**Бурычлар:**

1. Балаларда башкаларны тыңлый белү, кирәк урында үз фикерләрен аңлаешлы итеп җиткерә белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның игътибарлылыгын, фикерләү сәләтен үстерү, сүз байлыгын арттыру, авазларның дөрес әйтелешен активлаштыру.

3. И.Н.Мурашковска методикасын кулланып, рәсем буенча хикәя төзеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** өрәңге, тоясың.

**Җиһазлар:** «Алтын көз» рәсеме.

**Эшчәнлек барышы**

1. Тел төзәткеч. [а] авазы (кат-кат әйтү).

Мин әйтә алам,
Кем әйтә ала?
Әхмәт, син әйтеп кара.

2. Рәсем карау: «Алтын көз».

3. Рәсем буенча фикер алышу:

Беренче адым: Кем нәрсә күрә?

Икенче адым: Балалар эчтәлеге туры килгән ике рәсемне кушалар.

Өченче адым: Нинди тавыш ишетәсең?

Дүртенче адым: Нинди исләр тоясың?

Бишенче адым: Рәсемдәге әйбернең сыйфатларын әйтү.

Алтынчы адым: Хикәя төзү (балалар эшчәнлеге, 6 – 7 бала сөйли).

4. Көзге сынамышлар:

а) Сентябрь аяз булса, кыш салкын булыр.

б) Көз озын килсә, яз соң килер.

в) Көз көне тычкан күп булса, кыш җылы килер.

5. Дидактик уен «Нәрсә артык?» (көзге чәчәкләр арасыннан язгы чәчәкләрне аерып алу).

6. Бармак уены:

Бер, ике, өч, дүрт, биш.
Алтын сары яфракларны
Кулга җыябыз ич.
Бу – каен яфрагы,
Бу – имән яфрагы,
Бу – өрәңге яфрагы,
Бу – юкә яфрагы,
Бу – миләш яфрагы.
Яфракларны җыябыз,
Кәрзиннәргә салабыз.

## Тема. Шигырь ятлау: М.Җәлил. «Көз җитте»

**Бурычлар:**

1. Көз фасылының үзенә генә хас булган матурлыгын һәм гүзәллеген күрә белү, соклану хисләре тәрбияләү.

2. Балаларның игътибарлылыгын арттыру, хәтер сәләтен үстерү.

3. Шигырьнең эчтәлеген, таныш булмаган сүзләрнең мәгънәсен аңлату, шигырьне яттан, сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** кибеп сулдылар, уйсу җир.

**Җиһазлар:** «Алтын көз» рәсеме.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 124 бит.

## Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Кырлар буш кала,
Яңгырлар ява.
Җирләр дымлана, –
Бу кайчак була? (Көз)

2. Дидактик уен «Көз билгеләрен әйт!»

3. Шигырь уку: М.Җәлил. «Көз җитте».

4. Балаларга сораулар:

- Урман-кырларда, болыннарда нинди үзгәрешләр булды?
- Көзен сулар нишләде?
- Ни өчен кошлар безне калдырып китте?
- Укучылар өчен нинди вакыт җитте?

5. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала сөйли).

6. Сүзле уен «Көз».

- И балалар, күрегез,
Тышта әнә килде көз.
- Әйе, әйе, күрәбез,
Көз килгәнен беләбез.
- Я әйтегез, сөйләгез,
Ничек килә икән көз?
- Кошлар оча көньякка,
Канат кагып еракка.
Аюлар өн казыды,
Бик тирән итеп базны.
Балыклар да тындылар,
Су төбенә чумдылар.
Агачлар ялангачлар,

Җилләрдә чайкалалар.
Тик безгә күңелле көз,
Без бакчага йөрибез.

## Проект. Яшелчә, җиләк-җимеш

### Тема. «Бакчада көзге эшләр»

**Бурычлар:**

1. Күмәк эшләрдә башкалар белән беррәттән катнашу теләге, тирә-юньдәгеләр өчен кирәкле кеше булу, билгеле бер нәтиҗәләргә ирешү омтылышы тәрбияләү.

2. Диалогик һәм монологик сөйләмне камилләштерү, образлы фикерләү сәләтен үстерү.

3. Эзлекле һәм сәнгатьле итеп әдәби текстларның эчтәлеген сөйләргә, сәхнәләштерергә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** татлы, баз.

**Җиһазлар:** «Көзге эшләр» рәсеме, шалкан әкиятенә костюмнар.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 277 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Тизәйткеч:
Үзе яхшының
Эше дә яхшы.
Үзе яхшыга
Кеше дә яхшы.
2. Мәкаль:
Эшләп ашасаң, һәр ризык балдай татлы була.
Эчтәлеге буенча фикер алышу.
3. Шигырь уку: Н.Гайсин. «Уңыш җыю».
4. Балаларга сораулар:
- Бакчадан нинди уңышлар җыеп алдыгыз?
- Өлкәннәргә сез ничек булыштыгыз?
- Җыйган уңышларны кайда саклыйлар?
- Киләсе елга да уңышлар күп булсын өчен, нишләргә кирәк?
5. Уен «Дәвам ит!»
а) Яз килде – ... (кошлар кайтты).

б) Җәй җитте – ... (тау башында җиләк пеште).
в) Көз килде – ... (өстәлләр байлык белән тулды).
г) Кыш җитте – ... (җир өсте ап-ак карга күмелде).
6. Дидактик уен. «Эшләү өчен кемгә нәрсә кирәк?» (рәсемнәр белән). Бакча эш коралларының исеме һәм ни өчен кулланылуы әйтелә.
7. Өстәл театры. «Башак». Украин халык әкияте.

## Тема. Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Мин уңыш җыйдым»

**Бурычлар:**

1. Балаларны өлкәннәр хезмәтенә һәм үз хезмәтләренә хөрмәт тәрбияләү.
2. Эзлекле, бәйләнешле фикерләү һәм хәтер сәләтен, кызыксынучанлык, иҗади монологик сөйләмне үстерү.
3. Бирелгән план буенча тәҗрибәдән чыгып, хикәя сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** кайнатма, куш кулым.

**Җиһазлар:** «Көзге эшләр» рәсеме, яшелчә, җиләк-җимеш муляжлары, тәлинкә, чәнечке.

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: «К лар тулган бакчага». [к] авазы.

Бу бакчага ни булган?
Карлыган һәм кәбестә,
Кишер, карбыз һәм кабак,
Крыжовник һәм кукуруз,
Кыяр, кавын, кузгалак ...
Әйдә, рәхим итегез,
Авыз итеп китегез!

2. «Кем күбрәк әйтә?» уены ([к] авазы кергән сүзләр әйтү).
3. План буенча үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Мин уңыш җыйдым».

- Урамда кайсы вакыт?
- Бакчада нинди эшләр башкардылар?
- Нинди яшелчә, җиләк-җимешләр җыйдылар?

- Балалар ничек итеп зурларга булышты? (6 – 7 бала сөйли).

4. «Тәмле!» уены:

Өстәл өстенә куелган вазаларда җиләк-җимеш муляжлары. Чакырылган бала, өстәл янына килеп, үзе теләгән җимешне сайлап ала һәм аны мактап, реклама ясый.

5. «Тәме буенча бел!» уены:

Балага күзе йомылган килеш яшелчә кисәге каптырыла, бала аның нәрсә икәнен һәм тәмен әйтергә тиеш.

6. Җырлы-биюле уен «Куш кулым».

Урман буйларына менәм
Урман буе ямьлегә.
Бир кулыңны, мин дә бирәм,
Дус булырга мәңгегә.
Менә сиңа уң кулым,
Менә сиңа сул кулым.
Уң кулым да, сул кулым,
Менә сиңа куш кулым.
Алма бакчасына кереп,
Алма ашыйсым килә.
Син алмасы, мин чәчәге
Булып яшисем килә.

## Тема. Шигырь уку: Х.Халиков. «Дәү әнием – бакчачы»

**Бурычлар:**

1. Өлкәннәргә карата ихтирам, игътибарлылык, изгелек күрсәтү сыйфатлары тәрбияләү.
2. Балаларның логик фикерләү сәләтен, кызыксынучанлыкларын, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
3. Балаларның безнең җирлектә үсүче яшелчәләр турындагы белемнәрен арттыру, матур әдәбият әсәрләрен укырга теләк уяту.

**Сүзлек:** бакчачы, парник, һөнәр, буш вакыт, булышам, дәү булгач, дәвам итәм.

**Җиһазлар:** «Бакчачы» рәсеме, дегустация өчен киселгән яшелчәләр, муляжлар, бер зур кәрзин, ике кәстрүл, өч урындык.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 398 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Күзгә сынамышлар:

а) Күз бик озак торса, ашлык уңмый.

б) Күз озын килсә, яз соң килер.

в) Суган кабыгы калын булса, кыш салкын килә.

2. «Кем зирәк, әйт тизрәк!» уены.

а) Озын яшел – түтәлдә,
Сары, тозлы – кисмәктә. (Кыяр)

б) Җир астында алтын казык,
Алдык без аны казып. (Кишер)

в) Итләч, йомры яшелен,
Өзеп алдым, яшердем.
Гаҗәпләндем бераздан,
Кояшсыз да кызарган. (Помидор)

г) Ормый, сукмый,
Үзе кешене елата. (Суган)

д) Төрле-төрле төстә алар,
Бу төсләр каян килгән?
Хушбуй исе аңкыталар
Кем аны сөртеп йөргән?
(Чәчәк)

3. Шигырь уку: Х.Халиков. «Дәү әнием – бакчачы».

4. Балаларга сораулар:

- Дәү әни нинди һөнәр иясе?
- Ни өчен аның һөнәре бакчачы дип атала?
- Оныгы аңа ничек итеп булыша?

5. Дидактик уен «Мин башлыйм, син дәвам ит!»:

Ган, ган – ачы суган.
Сак, сак – ачы сарымсак.
Ге, ге – сары бәрәңге.
Дер, дер – кызыл чөгендер.
Шер, шер – озынча кишер.
Рыч, рыч – бик тәмле борыч.
Яр, яр – яшел кыяр.

6. Дидактик уен «Исемен бел».

Өстәлгә яшелчәләр куела. Катнашучы балаларның күзләре яулык белән бәйләнә. Алар исе буенча сарымсак, суган, ә тәме буенча тозлы кыяр, кәбестә, помидор һ.б. атыйлар.

7. Хәрәкәтле уен «Яшелчә ашы һәм җимеш суы әзерлибез».

Балалар ике командага бүленә. Зур кәрзингә яшелчәләр, җиләк-җимешләр салына. Беренче команда – яшелчә ашы, икенче команда – җимеш суы әзерләү өчен кирәкле яшелчә һәм җиләк-җимешләрне генә сайлап, урындыкка куелган кәстрүлгә ташый.

## Тема. «Күз күчтәнәчләре»

**Бурычлар:**

1. Үз сәламәтлекләре турында кайгырту, аны саклау сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның яшелчәләрнең файдалы яклары белән кызыксынучанлыкларын, уйлау сәләтләрен үстерү.

3. Балаларның үз җирлегендә үсә торган яшелчәләр турында белемнәрен арттыру, аларның сәламәтлек өчен нинди файда китерүләрен ачыклау.

**Сүзлек:** каротин, микроб, винегрет, борыч.

**Җиһазлар:** кәрзин, яшелчә муляжлары, рәсемнәр, салат савыты.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 513 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Яшелчәләр бәхәсе».

2. Балаларга сораулар:

- Яшелчәләрнең безнең сәламәтлегебез өчен файдасы бармы?
- Суган һәм сарымсакны, әче булса да, ни өчен ашарга кирәк?
- Кыяр ашауның нинди файдасы бар?
- Ни өчен кешеләр помидорны яратып ашыйлар?
- Чөгендернең файдасы нинди?
- Бәхәстә нинди яшелчә җиңгән?

3. Сүзле-хәрәкәтле уен:

Кәрзиннәрне алабыз,
Без бакчага барабыз.
Бабайга булышабыз,
Әбигә булышабыз.
Яшелчәләр җыябыз,
Ә нәрсәләр җыйганны
Табышмактан беләбез.

а) Турыйсың-турыйсың,
Тураганда елыйсың. (Суган)

б) Төбе алмалы,
Башы чалмалы. (Бәрәңге)

в) Җир астында картыгыз,

Сакалыннан тартыгыз. (Шалкан)

г) Кызыл кызы җир астында,

Чәчләре җир өстендә. (Кишер)

д) Үскәндә яфрагын ашыйлар,

Үскәч тамырын ашыйлар. (Суган)

Табышмакның җавабын әйткәч, бала яшелчә муляжын алып кәрзингә сала.

4. Үстерешле уен «Мин башлыйм, син дәвам ит!» (кабатлау).

Ган, ган – ачы суган.

Сак, сак – ачы сарымсак.

Ге, ге – сары бәрәңге.

Дер, дер – кызыл чөгендер.

Шер, шер – озынча кишер.

Рыч, рыч – бик тәмле борыч.

Яр, яр – яшел кыяр.

5. «Иң тәмле салат» уены (интерактив тактада яисә рәсем муляжлары белән).

Балаларга винегрет салаты ясарга тәкъдим ителә. Бу салатка кергән яшелчәләрне балалар сайлап алырга тиеш. Өстәлгә салатка кермәгән яшелчәләр дә куела.

## Тема. Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге эшләр»

**Бурычлар:**

1. Яшелчәләргә, җиләк-җимешләргә карата сак караш, аларның витаминнарга бай булуын аңлап, сәламәт тормыш алып бару теләге тәрбияләү.
2. Балаларның тәрбиячене ишетү һәм сорауларга тулы итеп җавап бирә белү осталыкларын, логик фикерләү сәләтен үстерү.
3. Балаларның рәсем буенча хикәя төзүләренә ирешү.

**Сүзлек:** кызыл эчле, алмасы тамырында.

**Җиһазлар:** «Көзге эшләр» рәсеме.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмаклар.

а) Кызыл эчле яшел өй,
Тәрәзәсез, ишексез.
Авыз итеп карасаң,
Балдан татлы һичшиксез!
(Карбыз)

в) Чәчәге агачында,
Алмасы тамырында. (Бәрәңге)

г) Ашка салсаң, тәм кертә,
Борынга керсә, төчкертә.
(Борыч)

б) Озын-озын агачлар,
Агачларда оялар,
Ояларда кошчыклар. (Борчак)

2. Рәсем карау: «Көзге эшләр».

- Кайсы ел фасылы сурәтләнгән?
- Бакчада нинди җиләк-җимешләр, яшелчәләр өлгергән?
- Көз көне бакчада нинди эшләр эшлиләр?
- Өлкәннәр хезмәте турында нәрсәләр әйтә аласыз?
- Балалар өлкәннәргә ничек ярдәм итәләр?
- Рәсемгә нинди исем бирер идегез?

3. Рәсем буенча балалар хикәясе (алдагы план-сорауларга таянып, 6 – 7 бала сөйли).

4. Арифметик табышмак «Чиясез калмыйммы?»

Ун чиянең
Өчесе энемә,
Икесен ашатам
Бәләкәй энемә.
Дусларга өләшсәм
Әгәр дә дүртесен,
Чиясез калмыйммы
Шуннан соң мин үзем? (Үзенә бер чия кала)

5. «Кәбестә» уены.

Балалар үзләре арасыннан әби сайлап куялар. Калганнары бер сафка тезелеп утыралар. Алар кәбестәләр була. Әби: «Кәбестә алырга дип килгән идем, яхшыларын сайлап алыйм әле»,- дип, кәбестәләрнең нык итеп иңбашларына басып-басып китә. Кем егылып китә, ул черек кәбестә була һәм уеннан чыгарыла. Әби моны кабат-кабат эшли. Иң ахыргача нык утырган бала яхшы кәбестә була. Шуны әби үзенә алып китә.

## Тема. Шигырь уку: Н.Мадьяров. «Балан»

**Бурычлар:**

1. Балаларда табигатькә сакчыл караш тәрбияләү, витаминлы ризыклар белән кызыксыну теләге уяту.
2. Балаларның фикерләү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү.
3. Матур әдәбият, рәсемнәр аша урман җиләк-җимешләре турындагы белемнәрен баету, тулыландыру.

**Сүзлек:** балан, бөрлегән, кара җиләк.

**Җиһазлар:** җиләк-җимеш рәсемнәре, җиләк-җимеш муляжлары.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 434 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Рәсемнәр карау (урман җиләк-җимешләре һәм аларның файдасы турында сөйләү).
2. Шигырь уку. Н.Мадьяров «Балан».
3. Балаларга сораулар:

- Балан җимеше кайда үсә?
- Бәлешне нәрсәдән пешердек?
- Әнинең туган көненә нинди бүләк булды?

4. Дидактик уен «Тәме буенча бел!»

Балага, күзен йомган килеш, берәр җиләк-җимеш каптыралар. Ул ни ашаганын тәме буенча белергә тиеш. Таныгач, бу җимешкә реклама ясый. Мәсәлән: Бу алма. Ул түгәрәк, кызыл, баллы, тәмле йомшак, файдалы. Алма тешләрне ныгыта, анда тимер күп. Алма ашаган бала сәламәт була.

5. Бармак уены.

Баш бармак – балан,
Имән бармак – карлыган,
Урта бармак – бөрлегән,
Атсыз бармак – алма,
Чәнти бармак – чия,
Кем күбрәк җимеш җыя?

6. «Дуслар, кая барасыз?» уены.

Бер бала бүре итеп билгеләнә. Калган балалар бүлмәдә урманга бару хәрәкәтләре ясыйлар.

- Дуслар, кая барасыз?
- Карурманга барабыз.
- Карурманда нишлисез?
- Кура җиләк җыябыз.
- Җиләк белән нишлисез?
- Җиләктән как коябыз.
- Бүре килсә, нишлисез?
- Урман буйлап чабабыз.

Аннан соң барысы да җиләк җыю хәрәкәтләре ясыйлар һәм җырлыйлар:

Җиләк җыям, как коям
Дәү әнигә бүләккә.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк икән.

Бүре яшеренгән җиреннән чыга да, балаларны куа башлый. Бүре куып тоткан бала бүре була.

## Проект. Икмәк – яшәү терәге

### Тема. «Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә»

**Бурычлар**:

1. Балаларга көзге байлыкның халыкка шатлык, куаныч китерүен төшендерү, бу байлыкларны тудыручы игенчеләр хезмәтенә карата хөрмәт тәрбияләү.
2. Балаларның бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
3. Игенченең мактаулы һәм авыр хезмәте, икмәкнең нинди юллар аша табынга килүе турында тасвирлап сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** бөртек, һөнәр, механизатор.

**Җиһазлар:** «Комбайнчы», «Тракторчы», «Машина йөртүче» рәсемнәре.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Һәр иген бөртегендә – кеше хезмәте.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Шигырь уку: Ә.Ерикәй. «Уңыш».

Үсеп утыра арыш,
Һәр башагы бер карыш.
Бодай үсә ургылып,
Дулкынланып, зур булып.
Әгәр күрсәң солысын –
Исең китеп торырсың.

Әнә кара тарыга,
Үрмәли югарыга.
Зәңгәр чәчәкле җитен –
Читләтеп үтү читен.
Киндер аеруча уңган,
Әйтерсең, кара урман.

3. Дидактик уен «Кем нәрсә эшли?»

Тәрбияче балаларга зур рәсемнәр өләшә, кечкенәләре аның үзендә кала. Зур рәсемдә теге яки бу һөнәр иясе сурәтләнгән. Зур рәсем янында кечкенә рәсемнәр белән тутырыла торган алты буш шакмак урнашкан. Тәрбияче кечкенә рәсемнәрне ача һәм сорый:

- Кем җир сөрә?
- Кем җирне тырмалый?
- Кем орлык чәчә?
- Кем икмәк ура?
- Кем иген ташый?
- Җир эшләренә кем җаваплы?
- Сезнең нинди һөнәр иясе буласыгыз килә?

Балалар сөйләме үрнәге: җирне тракторчы сөрә һ.б. Шакмакларны беренче тутырып бетергән бала җиңүче була.

4. «Бер сүз белән әйт!» уены (классификацияләргә өйрәтү). Мәсәлән: тракторчы, комбайнчы, чәчүче, ташучы һ.б. бер сүз белән ничек әйтелә? (Механизаторлар)

5. Такмаза:

Бардым борчакка,
Төядем корсакка.
Килеп чыкты иясе,
Инде ни диясе?
Килеп чыкты Фазлый,
Мине ничек каезлый,
Килеп чыкты Миргали,
Менә миңа биргәли.

## Тема. Картина карау: И.Шишкин. «Арыш басуы»

**Бурычлар:**

1. Рәсем сәнгате аша балаларда туган ягыбызны ярату хисләре, игенче хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

2. Сөйләмдә үз тәэсирләрен аңлату сәләтен, эстетик тойгыларын үстерү.

3. Рәсем сәнгате турында балаларның белемнәрен киңәйтү, сәнгать әсәрләрен хис белән кабул итәргә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** бөртек, бөртеклеләр, арыш, алтынсу, ялгыз.

**Җиһазлар:** «Арыш басуы» картинасы, бөртеклеләр салынган кечкенә савытлар.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Икмәк – табынга нур сибүче,

Кешегә, илгә – көч, куәт бирүче.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Дидактик уен «Исемен дөрес әйт!»

Балаларга бөртеклеләр салынган кечкенә савытлар тәкъдим ителә. Алар һәр бөртекнең үзенчәлекле якларын билгелиләр, исемнәрен атыйлар. Мәсәлән: бодай, арыш, солы, арпа.

3. Дидактик уен «Икмәк нинди юл үтә?»

Балалар рәсемнәрне тәртип буенча куеп чыгалар.

4. Картина карау: И.Шишкин. «Арыш басуы».

- Рәссам бу рәсемдә елның нинди фасылын сурәтләгән?
- Арыш басуын нәрсәгә тиңлисез?
- Басу уртасындагы юл нинди?
- Күк йөзе турында ничек әйтер идегез?
- Басудагы наратлар нәрсәгә охшап тора?
- Сез бу рәсемгә нинди исем куяр идегез?

5. Тәрбияче хикәясе.

Табигатьнең бик матур вакыты. Арыш өлгергән чак. Җәйге җылы җил исеп-исеп китеп, арыш басуын дулкынланып торган диңгезгә охшата. Арыш басуы буйлап сузылган юл серле дә, сихри дә дөньяга алып китәр кебек. Басу түрендә үскән горур

наратлар илаһи бер матурлык биреп, күренешне бизиләр. Басу читендәге яшел үлән өстендә карлыгачлар уйнап очалар, гүя алар ак чәчәкләр белән качышлы уйныйлар. Күк йөзе яшькелт-зәңгәр төсе белән арыш басуын тагын да матуррак итеп күрсәтә.

6. Җырлы уен «Ак калач».

Балалар, кулга-кул тотынышып, бер түгәрәк ясыйлар. Берсе уртага чыгып баса. Түгәрәктәге балалар, сүзләргә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар.

Булатның туган көненә,
Без пешердек ак калач;
Менә шулай ул биек,
Менә шулай тәбәнәк,
Менә шундый киңлеге,
Менә шундый тарлыгы,
Ак калач, ак калач,
Теләгәнеңне сайлап кач!

Ул үз урынына берәүне сайлап чыгара да түгәрәктәгеләргә кушыла. Уен шулай дәвам итә.

## Тема. Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Ашлар солтаны»

**Бурычлар:**

1. Балаларда эстетик тойгылар, икмәккә һәм башка ризыкларга сак караш тәрбияләү.

2. Балаларның әдәби әсәрне тыңлый, сәнгатьле сурәтләү чараларын күрә белү сәләтен, диалогик сөйләмен үстерү.

3. Балаларның әдәби багажын шигырьләр, табышмаклар, тизәйткечләр белән тулыландыру.

**Сүзлек:** ашъяулык, солтан, бөккән, хәйран калу, ләззәт, бәхәс.

**Җиһазлар:** милли ризык муляжлары, аудиоязма.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 275 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Үстерешле уен «Тылсымлы ашъяулык» (табышмаклар әйтелә, җавабын тапкан бала милли ризык муляжларын өстәлгә куеп бара).

а) Чыж иттереп саласың,
Бик тиз генә аласың,
Балга манып кабасың.
Ул нәрсә? (Коймак)
б) Вак-вак кына итеп кисеп
Өяләр аны таудай.
Чак-чак кына алып, өзеп
Аша, дустым, син шулай. (Чәк-чәк)
в) Йомырка белән онны
Бутап, камыр басканнар.
Бәрәңге, ит, тоз салып,
Почмаклар ясаганнар. (Өчпочмак)

г) Үзе түгәрәк,
Урыны түрдәрәк,
Эче тулы күзәнәк.
Әчкелтем дә төчкелтем, –
Бар нәрсәдән кадерлерәк.
(Икмәк)
д) Менә мине әйткәндә,
Мин бит төрлечә булам.
Бер пешкәндә – ит белән,
Бер алма белән тулам.
(Бөккән)

2. Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Ашлар солтаны».
3. Балаларга сораулар:
- Шигырьдә сүз нинди ризыклар турында бара?
- Ләвәш ашлар солтаны дип нинди ризыкны атый?
- Кунак ашлары арасында нинди бәхәс чыга?
- Ни өчен игенче ипине иң кадерле ризык дип атый?
- Ризыклар ни өчен бәхәсләшүдән туктыйлар?
- Алар ипине ничек каршы алалар?
4. Зиһен үстерү уены. «Мәкальне тәмамла!»
а) Ил табыны ... (икмәктән башлана).
б) Икмәкне җир уңдырмый ... (тир уңдыра).
в) Икмәк – ил ... (тоткасы).
г) Икмәкне әрәм-шәрәм итү – ... (зур гөнаһ).
5. «Парлашып калу» уены.
Көй уйнаганда, балалар таралып биеп йөриләр. Көй туктагач, парлашып басалар. Кем парсыз кала – ул татар халык ашлары турында сораулар бирә.
6. Тизәйткеч өйрәнү. [ч] авазы.
Чәк-чәк белән чәй эчкәндә,
Чак-чак кабып чәк-чәкне.
Чәй эчү бигрәк тәмле,
Чәшкеләре чәчәкле.

## Проект. Гаилә һәм йорт җиһазлары
### Тема. «Минем өем, өй җиһазлары»

**Бурычлар:**

1. Балаларда гаилә әгъзаларына карата ихтирамлы мөнәсәбәт, йорт җиһазларына сакчыл караш тәрбияләү.

2. Балаларның йорт җиһазлары турындагы белемнәрен баету, тирәнәйтү, мөстәкыйль һәм гомумиләштереп фикерләү сәләтен үстерү.

3. Балаларны, үз тәҗрибәләренә таянып, тәрбияче тәкъдим иткән темага сөйләргә өйрәтү.

**Сүзлек:** утыргыч, аркасы, түше, түбә, йорт җиһазлары, ашъяулык.

**Җиһазлар:** рәсемнәр, йорт җиһазлары, туп, геометрик фигуралар.

**Эшчәнлек барышы**

1. «Табышмаклар әйтәм – җавап табыгыз!» уены.

а) Аягы бар, кулы юк
Аркасы бар, түше юк. (Урындык)

б) Дүрт туган бер ашъяулык (түбә) астында. (Өстәл)

в) Калын түшәк салынган,
Мендәр, юрган куелган.
Бик уңайлы бу урын,
Рәхәтләнеп мен дә ят.
Исеме аның ... (карават)

г) Беләсезме бу өйне?
Сыйдырган бар киемне. (Киемнәр шкафы)

2. Үстерешле диалог (табышмаклар ярдәмендә).

- Балалар, болар барысы бергә ничек дип атала?
- Алар ни өчен кирәк?
- Йорт җиһазларын нинди материаллардан ясыйлар?
- Сезнең өйләрегездә нинди йорт җиһазлары бар?

3. Дидактик уен «Минем өем».

Балаларга йорт җиһазлары төшерелгән рәсемнәр таратыла. Алар аны бүлмәгә төре буенча дөрес итеп урнаштырырга

тиешләр. Мәсәлән: газ плитәсен аш-су бүлмәсенә, караватны йокы бүлмәсенә һ.б.

4. Сүзле уен «Мин тасвирлыйм, син әйт!»

Урындык, өстәл, кәнәфи, диван, савыт-саба шкафы һәм кием шкафы турында бер бала тасвирлый, ә икенчесе җавабын таба. Мәсәлән: агачтан ясалган, аның дүрт аягы, утыргычы һәм аркасы бар (Урындык).

5. Туплы уен «Тиз уйла!»

Балалар түгәрәктә, уенны алып баручы уртада, кулында туп. Алып баручы, йорт җиһазын әйтеп, бер балага тупны ыргыта. Бала, бу йорт җиһазының сыйфатын атап, тупны кире кайтара. Балалар өчкә кадәр кычкырып санийлар. Шул вакытка баланың җавабы әзер булмаса, ул уеннан чыга.

6. «Бу фигура кайсы җиһазны хәтерләтә?» уены.

Балаларга геометрик фигуралар таратыла, алар үз фигураларының нинди җиһазга ошаганын әйтәләр яки бүлмәдән табып күрсәтәләр.

7. Бармак уены «Йорт җиһазлары».

Баш бармак – диванда,<br>
Имән бармак – идәндә,<br>
Урта бармак – урындыкта,<br>
Атсыз бармак – караватта,<br>
Чәнти бармак – кәнәфидә,<br>
Барысы да бүген өйдә.

## Тема. Әңгәмә. «Нәрсә ул электр һәм электр җиһазлары?»

**Бурычлар:**

1. Кеше кулы белән эшләнгән әйберләргә карап соклана, хезмәт нәтиҗәләрен күреп горурлана белү хисләре тәрбияләү, электр җиһазларын кулланганда сак булырга өйрәтү.

2. Балаларның фикерләрен бер юнәлештә туплый белү, алган белемнәрен көнкүрештә куллана белү сәләтен үстерү.

3. Эш урынында кешенең хезмәтен җиңеләйтүче, өйдә кеше өчен уңайлыклар тудыручы предметлар турында белемнәрен камилләштерү.

**Сүзлек:** электр тогы, электр җиһазлары.

**Җиһазлар**: уен өчен парлы рәсемнәр, схема-рәсемнәр, ватман, төсле карандашлар.

## Эшчәнлек барышы

1. «Табышмак әйтәм – җавап көтәм» уены.

а) Төймәсе челт итә,
Үзе гөлт итә. (Лампочка)

б) Табаным утлы булса да,
Тукымадан йөрим мин.
Җыерык кына йөзләрне дә
Матурлыйм, тигезлим мин. (Үтүк)

в) Чүп-чар, тузан йота ул,
Өйне чиста тота ул. (Тузан суырткыч)

г) Өй эчендә базым бар,
Баз эчендә бозым бар.
Керер идем, сыялмыйм,
Бозларында шуалмыйм. (Суыткыч)

д) Бер көзгегә дөнья сыйган. (Телевизор)

е) Бар хезмәте бармакта,
Ак кәгазьгә язмакта. (Компьютер)

2. Үстерешле диалог.

- Табышмакта әйтелгән әйберләрне бер сүз белән ничек атарга була?
- Электр җиһазлары безгә ни өчен кирәк?
- Ни өчен аларны электр җиһазлары дип атыйлар?
- Электр җиһазларының нинди уңай һәм куркыныч яклары бар?
- Электр чыбыгын кул белән тотарга ярыймы?
- «Электр җиһазлары саклыкны ярата» дигән гыйбарәне сез ничек аңлыйсыз?
- Ут чыккан очракта нишләргә кирәк?

3. «Кем тизрәк?» уены.

Балалар ике төркемгә бүленәләр. Аларга карандашлар һәм зур ватман тәкъдим ителә. Беренче команда ут сүндерү машинасын, икенче команда ашыгыч ярдәм машинасын ясый. Һәр команда үз машинасы турында сөйли.

4. Үстерешле уен «Бел!» (төрле рәсемнәр бирелә, балалар аларны парлап куялар).

Язу машинасы – компьютер.

Шәм – электр лампасы.

Себерке – тузан суырткыч.

Күмер үтүге – электр үтүге.

Таз, сабын – кер юу машинасы.

Телефонның иске варианты – кәрәзле телефон.

Энә, җеп – электр тегү машинасы.

Мич – микродулкын миче.

5. «Кагыйдәне онытма!» уены (схема белән).

- Электр җиһазларын үзең генә кабызма!
- Электр чыбыгын кул белән тотма!
- Электр җиһазын озак эшләтмә!
- Электр җиһазлары ватык булса, кулланма!
- Розеткага әйберләр тыкма!
- Ут чыккан очракта электр җиһазларына су сипмә!
- Янгын чыкса, «01» гә шалтырат!

## Тема. Иҗади хикәя төзү. «Тату гаилә»

**Бурычлар:**

1. Гаиләдә бер-берсенә игътибарлылык, ярдәмләшү һәм дуслык, үзара хөрмәт хисләре тәрбияләү.
2. Балаларның мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү.
3. Сөйләмдә гаилә әгъзаларын белдерә торган сүзләрне куллану күнекмәләре бирү, иҗади хикәя төзергә өйрәтү.

**Сүзлек:** горурланам, тату, нәсел, язма яздым.

**Җиһазлар:** «Тату гаилә» темасына балалар ясаган рәсемнәр.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Ана җылысы – кояш җылысы.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Шигырь уку: Н.Мирхазова. «Горурланам гаиләм белән!»

Мин бәхетле гаиләм белән,

Яшимен әти-әнием белән!
Татулык – гаиләбез нигезе!
Әби-бабай – иң кадерле кеше!
Мин бәхетле гаиләм белән,
Яшимен туганнарым белән!
Нәселебез дәвамчысы – мин, беләм,
Горурланам гаиләм белән!

3. «Тату гаилә». Балаларга сораулар:
- Сез кемнәр белән яшисез?
- Гаиләдәге якын кешеләрегезгә ничек эндәшәсез?
- Гаиләдә кем нинди эш башкара?
- Гаиләдә тату яшисезме?
- Үз гаиләгез турында нинди матур сүзләр әйтер идегез?

4. Тәрбияче хикәясе:

Бу – минем әни. Ул дәфтәрләр тикшереп утыра. Әни мәктәптә укытучы булып эшли. Аны балалар бик ярата. Мин дә әнине бик яратам. Бу – минем әти. Ул энемә китап укый. Ә менә монысы – бабай, ул телевизор карый. Әби диванда оекбаш бәйләп утыра. Ә бу – мин. Мин шакмаклар белән уйныйм. Без бик тату яшибез.

5. Балалар эшчәнлеге (ясаган рәсемнәр буенча 6 – 7 бала сөйли).

6. Бармак уены.

- Бармак, бармак,
Кайда булдың?
- Бу абый белән
Баланга бардым.
- Бу абый белән
Ярма ярдым.
- Бу абый белән
Чәй эчтем.
- Бу энем белән
Биергә төштем.

**Тема. Шигырь уку: З.Туфайлова. «Минем гаиләм»**

**Бурычлар:**

1. Балаларда гаилә әгъзаларына ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү.

2. Балаларда матур әдәбият әсәрләрен игътибар белән тыңлый белү, логик фикерләү сәләтен үстерү.

3. «Тату гаилә» дигән төшенчәнең асылын бирү.

**Сүзлек:** бишек, әрәм булу, бәрәкәт.

**Җиһазлар:** рәсемнәр, фотоальбомнар.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 367 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Фотоальбомнар карау: «Безнең гаилә».

- Сезнең гаиләдә кемнәр яши?
- Алар нәрсә белән шөгыльләнә?
- Әтиең (әниең) кем булып эшли?
- Әби-бабаң турында нәрсә әйтә аласың?

2. Шигырь уку: З.Туфайлова. «Минем гаиләм».

3. Балаларга сораулар:

- Ни өчен өйгә тәмле ис тулган?
- Әби белән әни нәрсә пешергән?
- Бу гаиләдә кемнәр яши?
- Бу гаилә ни өчен матур?

4. «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!» уены.

- Әниеңнең энисенә син ничек дәшәсең?
- Әниеңнең этисе кем була?
- Әниеңнең улының (кызының) исеме ничек?
- Гаиләгездә иң өлкән кеше кем?
- Әгәр дә эти энидән өлкәнрәк булса, эни ... (яшьрәк).
- Г.Тукай шигырендәге җиденче гаилә әгъзасын әйт.

5. «Мәкальне тәмамла!» уены.

а) Әнкәм йорты – ... (алтын бишек).

б) Әткәй – шикәр, ... (әнкәй – бал).

в) Өйнең яме – ... (ана белән).

г) Олыласаң олыны, ... (олыларлар үзеңне).

д) Ата-ананы тыңлаган адәм булган, тыңламаган – ... (әрәм булган).

е) Бердәм өйдә – ... (бәрәкәт була).

ж) Тату туганнар ... (таштан койма корганнар).

6. «Тимербай» уены.

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнәләр. Бер бала уртага чыга. Түгәрәктәге балалар хор белән такмак әйтеп әйләнәләр:

- Тимербайның биш баласы,
Бар да матур, күз карасы;
Агым суда коендылар,
Ап-ак итеп юындылар,
Өс-башларын киенделәр,
Рәхәтенә тиенделәр.
Тезелеп кайтып киттеләр,
Ашамадылар, эчмәделәр,
Бер-берсенә караштылар –
Менә шулай эшләделәр.

Такмак бетүгә уртадагы бала нинди дә булса берәр хәрәкәт ясый. Түгәрәктәге балалар шунда ук аның кыланышларын кабатлыйлар. Кем кабатлый алмый, аны уртага кертәләр һәм уен яңадан башлана.

## Проект. Ашамлыклар һәм савыт-саба

### Тема. Ашханәгә экскурсия

**Бурычлар:**

1. Балаларда өлкәннәр хезмәтенә ихтирам тәрбияләү.
2. Көндәлек туклану режимы турында төшенчә бирү, һәр төр ашка туры килүче ризыклар, аларның сәламәтлеккә тәэсирен ачыклау, логик фикерләү сәләтен үстерү.
3. Өйрәнелгән сүзләрнең сөйләмдә кулланылышын активлаштыру, гомумиләштерүче сүзләрнең мәгънәсен аңларга өйрәтү.

**Сүзлек:** ашханә, пешекче.

**Җиһазлар:** «Пешекче» рәсеме, сюжетлы-рольле уен өчен кирәк-яраклар.

### Эшчәнлек барышы

1. Такмак. [ә] авазы.

И әбекәй, әбекәй,
Пешер миңа тәмлекәй.

Пешер бераз әлбә дә,
Янына куй хәлвә дә.

2. Ашханәгә экскурсия.

3. Табышмаклар.

а) Эче куыш, тышы таш,
Түбәтәе орчыкбаш. (Чәйнек)

б) Бәләкәй генә тай,
Төбе чеп-чи май. (Таба)

в) Ике туган суга бара,
Берсен-берсе уза бара. (Чиләкләр)

г) Колагы бар, башы юк,
Ашамаган ашы юк. (Кәстрүл)

4. Фикер алышу:

- Сезне ашханәдә кемнәр каршы алды?
- Пешекчеләр сезгә нинди ризыклар пешерәләр?
- Пешекчеләргә нинди матур сүзләр әйтер идегез?
- Ризыклар пешергәндә, пешекчеләр нинди савыт-сабалар кулланалар?
- Нәрсә ул дөрес туклану?
- Сезгә нинди ризык төре ошый?
- Сез табын артында утыру кагыйдәләрен беләсезме?

5. Шигырь уку: Б.Рәхмәт. «Аш вакыты».

Тәлинкә, кашыклар,
Чәнечке, пычаклар
Тарата дежурный –
Аш урыны хәзерли.
Бик ипләп йөртә ул,
Ватмыйча кертә ул,
Эштә бик оста ул,
Тәлинкә, кашыкның
Битләрен сөртә ул.
Тәртипне беләбез:

Әйбәтләп кенә без
Ашыйбыз, эчәбез,
Бер сүз дә дәшмибез,
«Апа, бик рәхмәт»,- дип
Урыннан торабыз,
Авызны чайкыйбыз.
Кулларны юабыз,
Ә урындыкларны
Урынына куябыз.

6. Уен-реклама «Кем күбрәк мактый?»

Балалар бер ризыкны сайлап алып мактыйлар. Мәсәлән: дөге боткасы – бик тәмле, ул файдалы. Ботканы ашасаң, сәламәт, таза буласың. Ботка майлы, баллы, йомшак һ.б.

7. Сюжетлы-рольле уен «Ашханә».

## Тема. Әңгәмә. «Кунак чакырдык»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кунакчыллык, кунакларга карата хөрмәт сыйфатлары тәрбияләү.
2. Балаларның игътибарлылыгын, диалогик сөйләмен үстерү.
3. Сөйләм әдәбе кагыйдәләрен өйрәнүне дәвам итү, кунаклар белән аралашу, үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен ныгыту, өстәл әзерләү күнекмәләре булдыру.

**Сүзлек:** тартынмагыз, кыстап-кыстап, авыз итегез, гаеп итмәгез.

**Җиһазлар:** савыт-саба, милли ризык муляжлары, аудиоязмада «Кунаклар» җыры (Ш.Галиев сүзләре, С.Сабирова көе).

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Балалар бакчасы», 511 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Хикәя уку: Ф.Бәдретдин. «Хуш киләсез, рәхим итегез!»
2. Фикер алышу:

- Сез кунакны ничек каршылыйсыз?
- Татар халкы кунакны ничек итеп сыйлый?
- Ничек итеп озатып кала?
- Кунакчыл хуҗа булу нәрсә дигән сүз?
- Юмарт хуҗа нинди була?
- Эчкерсез хуҗа дип кемне атыйлар?
- Әдәпле хуҗа булу ничек була?
- Ә тәрбияле хуҗа дип кемне атыйбыз?
- Сез үзегезне нинди хуҗа дип атар идегез?

3. Үстерешле уен «Кунак көтәбез».

Балалар табын әзерлиләр. Моның өчен башта савыт-саба исемнәрен ачыклыйлар, ә аннары ашъяулык ябып, савыт-сабаларны тиешенчә урнаштыралар.

4. Зиһен уены «Өстәлгәниләр килде?»

Милли ризыклар турында табышмаклар әйтелә. Исемен әйткән бала шул ризык муляжын өстәлгә китереп куя.

5. Җыр тыңлау: «Кунаклар» (Ш.Галиев сүзләре, С.Сабирова көе).

Без әзерлибез табын,
Китереп бөтен ягын:
Уртага куйдык чәчәк,
Чәчәк янына чәкчәк.
Бавырсак һәм кош теле.
Ризыклар төрле-төрле:
Сумса, бәлеш, өчпочмак,
Гөбәдия һәм коймак.
Һәркемгә чыгар өлеш:
Бар кыстыбый, бар бәлеш!
- Җитешегез, кунаклар,
Кыстатмагыз, кунаклар!
Өйгә кайтып китәргә
Ашыкмагыз, кунаклар!

6. Эндәш ятлау. [з] авазы.

Әйдә, безгә килегез!
Капкалардан керегез.
Капкалардан керегез,
Өебезгә үтегез.
Өебезгә үтегез,
Кунак булып китегез.
Кунак булып китегез, –
Гөрләп бәйрәм итегез!

### Тема. Хикәянең эчтәлеген сөйләү: С.Сәүбәнова. «Ботка нигә тәмле?»

**Бурычлар:**

1. Балаларда сөйләм әдәбе, бер-берсен тыңлый белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Күрсәтмә образлы фикерләү сәләтен үстерү.

3. Балаларга әкиятнең эчтәлеген аңларга һәм хәтердә калдырырга ярдәм итү, текстның эчтәлеген тулы итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** тап-таза, сау-сәламәт, калак, капкалап.

**Җиһазлар:** песнәк рәсеме.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 321 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Тел шомарткыч:

Мә сиңа калак,
Утырма карап.
Аша капкалап,
Ирененңне ялап.

2. Мәкаль:

Эшләп ашасаң, һәр ризык балдай татлы була.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

3. Хикәя уку: С.Сәүбәнова. «Ботка нигә тәмле?»

4. Балаларга сораулар:

- Кыз нәрсә ашарга яраткан?
- Кыз нәрсә дип әнисенә ялганлаган?
- Әнисе кызны кая алып барган?
- Кыз тагын нинди хәйлә тапкан?
- Кыз нин еларга тотынган?
- Әнисе, акчасы беткәч, нинди ботка пешергән?
- Кыз манный боткасы турында ни дигән?
- Ни өчен әни кызына «песнәккә әверел», дигән?
- Кыз, чын песнәкләр кебек, бөҗәкләр чүпли алганмы?
- Песнәк, ачыккач, кая кайткан һәм нишләгән?
- Ашаганда нәрсәләр әйтеп сайраган?
- Ничек уйлыйсыз, кыз әнисен бүтән борчымасмы?

5. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала сөйли).

6. Тизәйткеч «Беләсеңме?»

Үзе яхшының<br>
Эше дә яхшы.<br>
Эше яхшыга<br>
Кеше дә яхшы.

7. «Кап та коп» уены.

Балалар бер түгәрәк булып утыралар, бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш, йодрыкларын йодрык өстенә куеп, кулларны күтәреп-төшереп әйтәләр:

Без-без, без идек,<br>
Без унике кыз идек.<br>
Базга төштек – бал каптык,<br>
Келәткә кердек – май каптык,<br>
Кап та коп,<br>
Кара Якуб,<br>
Тимер туп,

Авызыңны ач та йот!- диләр дә, бар да берьюлы авызларын йомалар. Уйнаучылар берсе дә авызын ачмаска, көлмәскә, сөйләшмәскә тиеш. Алар бер-берсен көлдерү өчен төрлечә кы-

ланалар, күз-йөз белән төрлечә ымнар ясыйлар. Кем элек авызын ачса йә көлеп җибәрсә, аңардан:

- Күктән кем өй башына төштең?- дип сорыйлар. Ул берәр таныш өйне атый. Ул өйдә ничә кеше бар (көлүченең үзен дә кушып), һәрбер уйнаучы бу көлгән кешенең кулына я маңгаена шулар санынча чиертеп ала. Уен тагын башлана.

## Проект. Милли киемнәр

### Тема. Танышу уены: «Әбиемнең серле сандыгы»

**Бурычлар:**

1. Балаларда татар милли киемнәренә һәм бизәнү әйберләренә кызыксыну тәрбияләү.
2. Бәйләнешле фикерләү сәләтен үстерү, сөйләмдә парлы, кушма, ясалма сүзләр куллану күнекмәләре бирү.
3. Милли киемнәрнең исемнәрен, бизәлешләрен сөйләмдә куллануны системалаштыру.

**Сүзлек:** бәби итәкле күлмәк, камзул, күкрәкчә, түбәтәй, йөзек, беләзек, чулпы.

**Җиһазлар:** Казан сынлы сәнгать музее залын сурәтләгән слайдлар яки рәсемнәр, милли киемнәр ясалган рәсемнәр, аудиоязмада «Авыл көе», «Кәләпүш» җыры (Р.Вәлиева сүзләре, Л.Батыр-Болгари көе).

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: («Авыл көе» яңгырый).

Әбиемнең күңел сандыгы!
Нинди серләр саклый икән ул?
Гомер буе җыйган хәзинәме,
Әллә инде күңел бизәгеме,
Нинди серләр саклый икән ул?
Әбиемнең күңел сандыгын
Бер ачасы иде, ачасы ...
Әби-бабам белгән йолаларны,
Халкыбызның күңел җәүһәрләрен
Бер ачасы иде, ачасы.

Әбиемнең матур сандыгы
Кызыктыра инде күптәннән.
Ач, әбием, безгә күңелеңне,
Яшь буынга мирас булып калсын,
Бер хәзинә калсын үткәннән.

2. Слайдлар яки рәсемнәр карау (Казан сынлы сәнгать музее залы; татар халкының милли киемнәре һәм бизәнү әйберләре белән танышу: бала (бәби) итәкле күлмәк, камзул, алъяпкыч, күкрәкчә, калфак, түбәтәй, йөзек, беләзек, чулпы һ.б.).

3. «Милли киемнәр турында сөйлә!» уены.

Тәрбияче милли киемнәр рәсемнәре тарата. Балалар үзләрендә булган рәсемдәге кием турында сөйлиләр. Мәсәлән: бу – бик матур күлмәк. Ул яшел төстә, аска таба киңәеп киткән, бәби итәкле, озын җиңле. Күлмәк өстеннән чигүле ак алъяпкыч ябылган ...

4. Дидактик уен «Табышмаклар әйтәм – җавабын тап!»

а) Яңа гына идем итек,
[ч] өстәгәч булдым ... (читек)

б) Әнием, ак сәйлән тезеп,
Чиккән яшел бәрхетне.
Бар түбәмдә ... (түбәтәем)
Мин бүген бик бәхетле.

в) Җырлый-җырлый сәхнәләрдә
Аларның биер чагы.
Кызларга бик килешә
Башындагы ... (калфагы)

5. Җыр тыңлау: «Кәләпүш» (Р.Вәлиева сүзләре, Л.Батыр-Болгари көе).

6. «Түбәтәйле» уены.

Уртада 5 – 6 урындыкта түбәтәйләр тора. Балалар урындыклар тирәли түгәрәккә басалар һәм көй башлануга җиңелчә йөгерә башлыйлар. Көй туктауга, балалар түбәтәйләрен киеп урындыкларга утырырга тиешләр. Кем урынсыз кала, шул уеннан чыга. Икенче мәртәбә уенны кабатлаганда, уртада өч урын кала, уйнаучылар саны артыграк. Азакта калган бала җиңүче була.

## Тема. Чагыштырма хикәя төзү. «Кием кешене бизи»

**Бурычлар:**

1. Балаларда матурлыкны күрә һәм аны саклый белү сыйфаты, зәвыклылык тәрбияләү.

2. Балаларның акыл, хәтер, күзаллау, фикер йөртү сәләтен, бәйләнешле сөйләмен үстерү.

3. Татарстан Республикасындагы төрле халыкларның дус һәм тату яшәүләре турындагы белемнәрен камилләштерү.

**Сүзлек:** башмакчы, кунак кызы.

**Җиһазлар:** предметлы рәсемнәр, татар һәм рус киемендәге курчаклар.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Кунакны киеменә карап каршы алалар, акылына карап озаталар.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. «Кунак кызларын каршы алыйк» (татар һәм рус киеме кигән курчаклар кунакка килә).

- Безгә кунакка кемнәр килгән?
- Алар бер-берсенә ошаганмы?
- Кайсы яклары белән ошаганнар?
- Кайсы яклары белән аерылып торалар?
- Татар кызының күлмәге нинди төстә, ничек киенгән?
- Рус курчагының костюмында күбрәк нинди төсләр кабатлана?
- Рус кызының башында нәрсә, ул калфактан кайсы ягы белән аерылып тора?
- Бу бизәкләрне тагын кайда күреп була?
- Сезнең төркемгә нинди милләт балалары йөри?
- Сез дус яшисезме?

3. Дидактик уен «Нинди сүз төшеп калган?»

Тәрбияче милли киемнәр төшерелгән рәсемнәрне балаларга тарата, һәр рәсемгә карап җөмлә төзи. Җөмлә төзегәндә бер сүз төшереп калдырыла. Балалар шул сүзне табарга тиеш. Мәсәлән: Бу татар кызының ... (читеге). Бу ... (татар кызының) күлмәге. Татар кызының күлмәге ... (алсу) төстә.

4. Җырлы-сүзле уен «Башмакчы»:
Итек, читек, энә, без
Матур итеп тегәбез,
Башмак башы чигәбез.
Кирәкмиме, алмыймсыз,
Әллә киеп карыймсыз?
Түгәрәктәгеләр аңар каршы:
И башмакчы, башмакчы,
Үзең оста такмакчы,
Син сайрама такмагың,
Бир кияргә башмагың,- диләр.

Түгәрәктәгеләр бер якка таба әйләнеп йөгерә башлыйлар. Башмакчы, утырган урыныннан торып, аларны куа башлый. Тотылган бала уеннан чыга.

### Тема. Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Кәләпүшем, кәләпүш»

**Бурычлар:**

1. Балаларда матур әдәбият аша милли киемнәргә карата кызыксыну уяту, аларның үзләренә генә хас булган нәфис бизәлешенә, уңайлылыгына соклану хисләре тәрбияләү.
2. Халкыбызның күңел бизәкләре белән якыннан таныштыру; сөйләм телен, фикерләү сәләтен, танып белү активлыгын үстерү.
3. Милли киемнәрне аера һәм аларның исемнәрен, үзенчәлекләрен әйтә белергә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** кәләпүш, укалы, энҗе, мәрҗән.
**Җиһазлар:** кисмә рәсемнәр, түбәтәй.
**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 498 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:
Әнием, ак сәйлән тезеп,
Чиккән яшел бәрхетне.
Ул үзем кебек бәләкәй,
Ә исеме – ... (түбәтәй).

2. Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Кәләпүшем, кәләпүш».

3. Балаларга сораулар:

- Дәү эти туган көнгә нәрсә алып килгән?
- Татар малае нинди була?
- Кәләпүш ничек итеп эшләнгән?
- Малай нинди һөнәрләр белә?
- Әнисе ни өчен сөенгән?
- Дәү этисенең бүләге малайга ошаганмы?
- Кәләпүш сүзен нинди сүз белән алыштырып була? (Түбәтәй)

4. Дидактик уен «Дөрес итеп милли киемнәрне җый!»

Балалар кисмә рәсемнәрдән милли кием рәсемнәрен җыялар.

5. Үстерешле уен. «Кем күбрәк белә?» (милли киемнәрне санау). Мәсәлән: кәләпүш, калфак, читек, чүәк һ.б.

6. Җырлы-биюле уен «Түбәтәй».

Балалар түгәрәкләнеп басалар. Түбәндәге җырны җырлый-җырлый, түбәтәйне бер-берсенә бирәләр:

Түбәтәеңне кигәнсең,
Бик ераклардан килгәнсең,
Төскә матурлыгың белән
Шаккаттырыйм, дигәнсең.
Кушымта. Түп-түп, түбәтәй,
Түбәтәең укалы.
Чиккән матур түбәтәең
Менә кемдә тукталды.

Җыр ахырында, түбәтәй кемдә калса, шуңа җәза бирелә: бии, җырлый, әтәч булып кычкыра һ.б. Уен шулай дәвам итә.

## Проект. Кыш. Кышкы уеннар

### Тема. Паркка экскурсия. «Килеп җитте матур кыш»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кызыксыну уяту, табигатькә сак караш, экологик бәйләнешләрне күрә белү сыйфаты тәрбияләү.
2. Чагыштырып тасвирлый белү күнекмәләрен үстерү.
3. Балаларның кыш, кар үзенчәлекләре турында белемнәрен баету.

**Сүзлек:** сафландыра, тәңкә кар, өермә, сырган буран, буран тургае.

**Җиһазлар:** чаналар, җимлек, җим, «Буран» мотоциклы рәсеме.

**Эшчәнлек барышы**

1. «Табышмак әйтәм – җавабын тап!»

Урамнарны агарта,
Бар дөньяны яңарта.
Сафландыра кешене,
Ничек аның исеме? (Кыш)

2. Тизәйткеч. [ы] авазы.

Ыш-ыш-ыш,
Килеп җитте
Матур кыш.

3. Фикер алышу:

- Кыш айлары нинди айлар?
- Бу айларда кояш турында нәрсәләр әйтә аласыз?
- Җир өстен нәрсә каплаган?
- Кыш көне һава торышы нинди була?
- Ни өчен агач төпләренә кар өяргә кирәк?
- Җимлеккә нинди кошлар очып килә?
- Ни өчен чыпчыклар, песнәкләр йоннарын кабартып утыралар?
- Ни өчен кыш көне кошлар кешеләр яши торган урыннарга күбрәк киләләр?

4. «Сорау – җавап» уены.

- Нәрсә ул болытлардан ява торган, туңган су кристаллары? – ... (кар)
- Нинди карлар була? – ... (беренче кар, җепшек кар, ябалак кар, тәңкә кар)
- Кар нигә шыгырдый? – ...
- Карның файдасы, зыяны бармы? – ...
- Кыш көне нинди бураннар була? – ... (җәяүле буран, карлы буран, өермә буран, сырган буран)
- Буранның файдасы (зыяны) нидә?
- «Буран»га утырып йөреп буламы? – ... (Кар өстеннән йөри

торган мотоцикл бар. Ул яныңнан бер узып китсә, аның артыннан бураннар уйнап кала. Шуңа күрә аны «Буран» дип атаганнар. Димәк, «Буран»га утырып йөреп була)

5. Шигырь уку: Р.Миңнуллин. «Буранда».

Беркем чыкмый урамга,
Буранлы көн булганга.
Буран ала бөтереп,
Салкын ала өттереп!
Кошлар гына һавада
Чайкалалар һаман да.
Рәхәтләнеп очарга
Бик кыендыр кошларга.

6. «Сүз эчендә энҗе бар!» Мәсәлән: кар көрте, кар тоту, кар атышлы, кар шуышу, буран туздыру – бик каты җилләнеп бию, буран тургае – кызылтүш һ.б.

7. Хәрәкәтле уен «Чаналарга!»

Чаналарны мәйданчыкның бер ягына урнаштыралар. Аларның саны уйнаучылардан бергә кимрәк булырга тиеш. Мәйданчыкның икенче каршында балалар йөгереп йөриләр, әйләнәләр, сикергәлиләр. Тәрбияче: «Чаналарга!»- дип сигнал бирә, балалар чаналарга таба йөгерәләр һәм тиз генә берәр чанага утыралар. Иң соңгы килгән бала урынсыз кала.

## Тема. Әңгәмә. «Паркта минем күргәннәрем»

**Бурычлар:**

1. Балаларда үсемлекләргә, кошларга, хайваннарга карата сак караш тәрбияләү.
2. Экологик фикер йөртү, иҗади хыял сәләтләрен үстерү.
3. Табигатьтә ел фасыллары буенча барган үзгәрешләр турындагы белемнәрен системалаштыру һәм тирәнәйтү.

**Сүзлек:** кар бабай, җирне коча, кызылтүш, тиңсез хәзинә.

Эшчәнлек табигатьтә үтә.

### Эшчәнлек барышы

1. Үстерелешле диалог.

- Табигать – тиңсез хәзинә (байлык) дигән сүзне ничек аңлыйсыз?

- Парктагы күренеш сезгә ошадымы?

- Кыш көне табигатьтә нинди үзгәрешләр күзәтелә?

- Паркта йөргәндә, иң истә калганы нәрсә булды?

- Нинди кар белән кар бабай ясыйлар? (Җепшек кар)

- Мамык кебек җиңел, күпереп торган эре бөртекле карны нинди кош исеме белән атыйлар? (Ябалак кар)

- Сез нинди кышлаучы кошларны беләсез?

2. Дидактик уен «Дөрес тасвирла!»

Балалар кош исемнәрен, үзенчәлекләрен атыйлар: песнәк, чыпчык һ.б. Мәсәлән: чыпчык – кечкенә, хәрәкәтчән, чыдам, көрән төстә һ.б.

3. Сүзле-хәрәкәтле уен «Кышкы паркта».

Кышкы паркка килдек,
Матур урыннар күрдек.
Тун кигән каен унда,
Ямь-яшел чыршы – сулда.
Кар бөртекләре оча,
Әйләнеп, җирне коча.
Кызылтүшләр очалар,
Бигрәк матур алар.
Паркта рәхәт булса да,
Өйгә кайтыйк, балалар.

4. Үстерешле уен «Фотога төшер!» (паркта күргән кызыклы вакыйгаларны күзаллап сөйләү).

5. Тизәйткеч «Шуа-шуа шомара».

Чаңгычының чаңгысы
Шуа-шуа шомара.
Чаңгың шомарсын дисәң,
Кирәк ешрак шуарга.
Шаһидәнең чаңгысы
Шома әнә шуңарга.

## Тема. Шигырь ятлау: Г.Латыйп. «Кыш килде»

**Бурычлар:**

1. Балаларда шигырь юллары аша кышкы табигатькә соклану хисләре, мәхәббәт тәрбияләү.

2. Балаларның хәтерен, сәнгатьле сөйләмен үстерү.

3. Шигырьнең эчтәлеге буенча куелган сорауларга дөрес җавап алуга ирешү; халык сынамышларына кызыксыну уяту.

**Сүзлек:** мамык, шыгырдый, йомарлаган, саф, йомшак, кырлач, бәс.

**Җиһазлар:** матур тартма, кәгазь кар бөртекләре.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 278 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:
Колак, борынны уып,
Өеңә кертә куып. (Салкын)
2. Мәкаль:
Җылы – сөяк сындырмый.
Эчтәлеге буенча фикер алышу.
3. Шигырь уку: Г.Латыйп. «Кыш килде».
4. Балаларга сораулар:
- Ак мамыктай кар кая төшә?
- Карның нинди сыйфатларын беләсез?
- Кар нигә шыгырдый?
- Салкын кыш аен ничек каршылыйбыз?
- Кышын һава нинди?
- Йомшак тун киеп, кунакка кем килде?
5. Шигырьне яттан сөйләү (6 – 7 бала сөйли).
6. Сынамышлар «Халык әйтсә – хак әйтә».
а) Кыш бәс, томан булса, җәй иген уңа.
б) Кыш карсыз булса, җәй ярлы була.
в) Кар калын булса, ашлык уңар.
г) Каз аягын күтәреп торса, салкын булыр.
д) Төтен җиргә төшсә, кышын кар явар.
е) Кояш бик еракта булып күренсә, салкын булыр.

ж) Тау башларында кар күп булса, җиләк күп булыр.

7. Хәрәкәтле уен «Кар бөртекләре җыю».

Бүлмә идәненә кар бөртекләре сибелә. Уенда ике бала катнаша. Аларга матур тартма бирелә. Тәрбияче сигналы буенча, балалар кар бөртекләрен җыеп, тартмаларга салалар. Алдан кайсы җыеп бетерсә, шул бала җиңүче була.

## Тема. «Боз һәм бозлыклар»

**Бурычлар:**

1. Балаларда табигать күренешләрен белергә омтылыш, үз фикерен әйтә белү сыйфаты тәрбияләү.

2. Балаларның табигать объектлары белән кызыксынучанлыкларын, диалогик сөйләм күнекмәләрен, сүз байлыкларын үстерү.

3. Балаларның табигать турындагы күзаллауларын киңәйтү, әйләнә-тирә чынбарлыкка нәфасәти мөнәсәбәт формалаштыруны дәвам итү.

**Сүзлек:** бозлавык, шугалак, тайгак, тайгаклык, айсберг.

**Җиһазлар:** слайдлар яки рәсемнәр.

### Эшчәнлек барышы

1. Зиһен ачкычы – табышмак:

а) Исе юк, төсе юк,
Аннан башка тормыш юк. (Су)

б) Йолдыз-йолдыз вак кына,
Ак мамык сымак кына.
Өс киеменә куна,
Тәнгә тисә, су була. (Кар бөртеге)

в) Ишегалдында таш була,
Өйгә керсә, су була. (Боз)

2. Фикер алышу:

- Суның нинди өч халәтен беләсез?
- Кардан боз ясап буламы?
- Нәрсә ул бозлык?
- Бозның нинди үзенчәлекләрен әйтә аласыз? (Шома, кытыршы, үтә күренмәле, каты, уалучан ...)

- Бозның нинди файдасы бар? (Шугалак, төрле фигуралар-сыннар ясыйлар, косметикада, медицинада кулланалар)

3. Тәрбияче хикәясе (слайдлар яки рәсемнәр ярдәмендә):

Бозлык – күп еллар буена тупланып килгән боз катламы. Бозлыклар җир шарында 10 процент коры җирне каплап торалар. Аларның иң зур өлеше Гренландия утравында, Антарктидада, Көньяк һәм Төньяк полюсларда тупланган, ә калганы биек тау башларында. Бозлыкларның барысы да хәрәкәт итә. Боз катламы бик калынайса, ул авырлыгы белән кузгала башлый. Океаннарда йөзеп йөрүче айсберглар шушы боз кисәкләре инде.

Беркемнең дә океанда
Килми ялгыз каласы.
Ә ул йөзә, дөнья гизә
Зур бозлыкның «баласы».

Айсберглар суда йөзгән корабльләргә куркыныч тудыра. Бозлыкларның кеше өчен файдасы да бар. Алар зур күләмдәге төче су запасын саклаучылар. Тау елгалары коры климатлы урыннарда уңдырышлы җирләрне сугаралар.

4.Үстерешле уен. «Сүз эчендә энҗе бар».

- Җир өстенең боз белән каплануы – ... (бозлавык)
- Боз белән капланган өслек – ... (шугалак)

5.Тизәйткеч ятлау. [з] авазы.

Оз-оз-оз-оз,
Асылташ боз.
Оз-оз-оз-оз,
Ялтырый боз.

6. Хәрәкәтле уен «Бозлы фигуралар».

Балалар талгын музыка астында ирекле хәрәкәтләр ясыйлар. Музыка туктауга, балалар матур фигуралар ясап туктап калалар. Иң матур фигура ясаучы балага фишка бирелә. Иң күп фишка алган бала җиңүче була.

### Тема. Иҗади хикәя төзү. «Кышкы уеннар»

**Бурычлар:**

1. Эшчәнлектә үзара дустанә мөнәсәбәт тәрбияләү, тыңлый

белү күнекмәләрен камилләштерү.

2. Балаларның таныш булган вакыйгалар турында тулы җөмләләр белән сөйли белү күнекмәләрен үстерү.

3. Бирелгән сораулар аша диалогик сөйләм формаларын камилләштерү.

**Сүзлек:** җепшек, каравыл, кәшәкә.

**Җиһазлар:** парлы рәсемнәр, туп.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку: Д.Гарифуллин. «Кар бабай ясадык».

Җыелып җепшек кардан
Кар бабай ясап куйдык.
Матурлап аның күзләрен,
Авызын хәтта уйдык.
Нинди эш кушыйк аңа, дип,
Кичен уйлап тордык та, –
Каравылга дип калдырдык
Бер таяк тоттырдык та.

2. Фикер алышу (балалар җавабы схема рәвешендә тактага беркетелеп барыла):

- Саф һавада кыш көне нинди уеннар уйнарга була?
- Сез нинди уеннар уйныйсыз?
- Уен вакытында сез нинди куркынычсызлык кагыйдәләрен үтисез?

3. Иҗади хикәя төзү: «Кышкы уеннар».

- Нинди кышкы уеннар беләсез?
- Иң яраткан уеныгыз нинди?
- Бу уенда нинди атрибутлар кулланасыз?
- Уенны ничек итеп уйныйсыз?
- Сез яраткан уенның иң кызыклы өлеше нинди?

4. Дидактик уен «Парын тап» (бирелгән сүзләрне мәгънәләре буенча туры килерлек итеп парлаштыру). Мәсәлән: чаңгы – таяк, туп – кәрзин, кәшәкә – шайба, чана – тау, кыш – кар, боз – тимераяк һ.б.

## Тема. Язма сөйләм. «Кыш бабайга хат»

**Бурычлар:**

1. Балаларда бәйрәмнәргә карата уңай мөнәсәбәт, үз фикереңне бер юнәлештә туплый һәм аны башкаларга җиткерә белү сыйфаты тәрбияләү.

2. Бәйләнешле сөйләм телен, иҗади күзаллауларын үстерү.

3. Балаларда хат яза белү күнекмәләрен, үз тәҗрибәсеннән чыгып бәйрәм турында әйтә алу мөмкинлекләрен камилләштерү.

**Сүзлек:** эри, юлдаш, гөр килә, иңенә салып.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Бу – Кыш бабай» җыры (Җ.Тәрҗеманов сүзләре, С.Сабиров көе), конверт, каләм, кәгазь.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

а) Елга ул тик бер килә,
Ул килсә, җир гөр килә.
Яшел чыршы әйләнә
Якты заллар күркенә. (Яңа ел)
б) Кыш бабайның юлдашы,
Аның белән гел бергә.
Шуңа аны җәй көне
Мөмкин түгел күрергә.
Җәй көне ул бөтенләй
Мөмкин хәтта эрергә,
Суга әверелергә. (Кар кызы)
в) Килә бары кыш җиткәч,
Иске ел үтеп киткәч.
Үзе белән һәрвакыт
Яңа ел алып килә.
Бүләк тулы капчыгын
Иңенә салып килә. (Кыш бабай)

2. Фикер алышу:

- Яңа ел бәйрәме кайсы ел фасылында була?
- Сезгә бу бәйрәм ошыймы? Ни өчен?
- Яңа елның тылсымлы кичендә нинди әкият геройлары килә?

- Сез бу бәйрәмгә ничек әзерләнәсез?
- Бу бәйрәмгә кемнәрне чакырыр идегез?
- Бәйрәм турында Кыш бабайга ничек хәбәр итәргә була?

3. Кыш бабайга хат язу:

- Хатны ничек башлар идегез?
- Без аны нинди бәйрәмгә чакырабыз?
- Кыш бабайны ни өчен чакырабыз?
- Кыш бабайны бәйрәмгә кемнәр белән чакырасыз?
- Сез Кыш бабайга нәрсәләр әзерләдегез?
- Кыш бабайдан нинди бүләкләр сорар идегез?
- Кыш бабай сезне ничек табар?

4. Хат язу:

Балалар әйтеп тора, тәрбияче яза. Кирәк булган очракта, тәрбияче үрнәге кулланыла.

5. Җырлы-сүзле уен «Бу – Кыш бабай» (Җ.Тәрҗеманов сүзләре, С.Сабиров көе).

Кемнең кигән киемнәре
Энҗе кар бөртекләре?
Кемнең көмештәй сакалы,
Чәчләре, керфекләре?
Бу – Кыш бабай, Кыш бабай,
Безгә бик таныш бабай.
Кем соң безгә шундый ямьле
Яңа ел алып килә?
Матур кәгазь капчыкларга
Күчтәнәч салып килә?
Бу – Кыш бабай, Кыш бабай,
Безгә бик таныш бабай.
Чаңгы, чанада шуарга,
Булды шома тавыбыз.
Кем безгә аны ясаган?
Кем икән ул, табыгыз.
Бу – Кыш бабай, Кыш бабай,
Безгә бик таныш бабай.

## Проект. Кыргый хайваннар

### Тема. «Кайда ничек кышлыйлар?»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кыргый хайваннарга карата кызыксыну һәм сакчыл караш тәрбияләү.
2. Мөстәкыйль фикерләү сәләтен үстерү.
3. Балаларны кыргый хайваннар, аларның тышкы билгеләре, яшәү рәвешләре белән таныштыруны дәвам итү.

**Сүзлек:** букча, сикергән.

**Җиһазлар:** кыргый хайваннар һәм йорт хайваннары рәсемнәре, кроссворд.

**Эшчәнлек барышы**

1. Дидактик уен «Дөрес сайла!»

Рәсемнәрдән кыргый хайваннарны сайлап алу, йорт хайваннарыннан аермаларын ачыклау: тышкы билгеләре, нәрсә белән туклanулары, өннәре нинди булуы, кайда кышлаулары, үз-үзләрен һөҗүмнәрдән саклау рәвешләре. Мәсәлән: керпе – төнге ерткыч җәнлек. Аның аяклары кыска, ләкин тиз йөри. Азыкны тиз генә, борынын сузып эләктерә. Суалчан, кондыз, тычкан, әкәмтөкәмнәр белән туклана. Башка ерткыч хайваннардан саклануда энәләре нык ярдәм итә. Кышны өнендә йоклап үткәрә.

2. «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!»

- Җәнлекләр патшасы – ...
- Буй-буй майка кигән ат – ...
- Балны бик яратса да, умарта асрамый – ...
- Нәрсәнең мөгезе борынында?
- Букчалы (сумкалы) сикергәк – ...
- Елгаларда плотина төзүче җәнлек – ...

3. Дидактик уен «Нәрсә кайда яши?»

Беренче рәттәге рәсемнәрне икенче рәттәге рәсемнәр белән парларга.

1 нче рәт: аю, бүре, тиен, тавык, эт, бал корты, тычкан, сыер, карлыгач, яңгыр суалчаны.

2 нче рәт: абзар, кетәклек, өн, агач куышы, оя (гнездо), эт оясы, туфрак, умарта, бүре өне.

4. Кроссворд «Кыргый хайваннар».

1) Урманнан чыгар,
Корсак асты чуар.
Койрыгы сырлы,
Хәйләсе күптөрле. (Төлке)

2) Өсте җылы тунлы,
Җир астыннан юлы.
Сызгырып җибәрсә,
Яңгырата кырны. (Йомран)

3) Сорыдыр төсе,
Үткендер теше.
Урманда йөри,
Бозаулар күзли. (Бүре)

4) Асрамый да умарта,
Балны бик-бик ярата.
Кышын сөя йокыны,
Язгача тормый ята. (Аю)

5) Кош түгел, оча.
Ябалактан курка.
Чикләвекне ярата.
Сызгырса, урманны яңгырата. (Тиен)

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1 | | | К | | | |
| 2 | | | | А | | | |
| | | | 3 | Б | | | |
| | | | 4 | А | | | |
| | 5 | | | Н | | | |

5. «Хәйләкәр төлке» уены.

Балалар түгәрәккә тезеләләр. Түгәрәктән читтә сызык белән төлке өе билгеләнә. Балалар күзләрен йомалар, ә тәрбияче түгәрәкне әйләнеп чыга һәм балаларның берсенә кулы белән кагыла. Бу бала хәйләкәр төлке була. Аннан соң тәрбияче балаларга, күзләрен ачып, бер-берсенә игътибар белән карарга тәкъдим итә. Балалар өч тапкыр: «Хәйләкәр төлке, син кайда?»- дип сорыйлар һәм бер-берсенә карап торалар. Өченче тапкыр сораганнан соң, хәйләкәр төлке тиз генә түгәрәк уртасына чыгып баса да, кулларын югары күтәреп: «Мин монда!»- ди һәм балаларны куа башлый.

## Тема. Рәсем буенча хикәя төзү. «Кыш. Тиеннәр»

**Бурычлар:**

1. Хайваннарны кызгану, алар турында кайгыртучанлык хисләре уяту.

2. Эвристик (уйлап табуга юнәлтелгән) фикер йөртү алымнарын үстерү.

3. Балаларның урман җәнлекләре, яшәү рәвешләре турындагы белемнәрен баету, рәсем буенча хикәя төзүләренә ирешү.

**Сүзлек:** яңгырата, соры, җитез, койрык.

**Җиһазлар:** «Кыш. Тиеннәр» рәсеме, җәнлекләр яраткан азык муляжлары, койрыклар гына төшерелгән рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы**

1. «Бер табышмак әйтәм, кем җавабын табар?»:

Кош түгел, оча.

Ябалактан курка.

Чикләвекне ярата.

Сызгырса, урманны яңгырата. (Тиен)

2. Рәсем карау: «Кыш. Тиеннәр».

3. Балаларга сораулар:

- Рәсемдә нинди җәнлекләр күрәсез?
- Тиеннәрне нәрсә куркыткан?
- Беренче тиен ничек итеп кача?
- Икенче тиен нишли?
- Тиеннәрнең дошманы нәрсә? (Сусар)
- Ул тиеннәргә ничек итеп карап тора?
- Бу рәсемгә нинди исем кушар идегез?

4. Тәрбияче хикәясе:

Бу рәсемдә кышкы урман сурәтләнгән. Зур наратта сусар утыра. Бер тиен, агачтан – агачка сикереп, сусардан кача. Икенчесе әкрен генә агач башына үрмәли, чөнки сусар аларның дошманы. Ул игътибар белән аларның кайсысын тотып алыйм икән дип карап тора. Мин бу рәсемгә «Җитез тиеннәр» дип исем кушар идем.

5. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала сөйли).

6. «Уйлап тап!» уены (кыргый хайваннар турында табышмак уйлап табу).

7. «Кем нәрсә ярата?» уены (кыргый хайваннарның нәрсә белән туклануларын әйтү). Мәсәлән: куян – кишер, кәбестә ашый һ.б.

8. Дидактик уен «Танып бел!» (койрыклар сурәтләнгән рәсемнәр буенча кыргый хайваннарны танып әйтү).

## Проект. Кышлаучы кошлар

### Тема. Кошларны күзәтү. «Безнең канатлы дусларыбыз»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кошларга карата мәрхәмәтлелек, кайгыр-

тучанлык хисе тәрбияләү, аларны рәнҗетмәскә кирәклеген төшендерү.

2. Тышкы билгеләренә (төсе, зурлыгы), үз-үзләрен тотышларына, тавышларына карап, кышлаучы һәм күчмә кошларны аерып күрсәтә белү күнекмәләрен үстерү.

3. Балаларның кышлаучы кошлар турындагы белемнәрен ныгыту.

**Сүзлек:** сыртлы, күгелҗем.

**Җиһазлар:** кош тавышлары язылган аудиоязма, кош рәсемнәре.

## Эшчәнлек барышы

1. Көйләр тыңлау: «Кошлар тавышы».

2. Ситуация. «Кошларны танып бел!» (рәсемнәр буенча кошларны танып белү, үзенчәлекле якларын тасвирлау).

3. «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!»

- Кошларны хайваннардан ничек итеп аерып була?
- Ак сыртлы кош ул – ...
- Кызыл күкрәкле кош ул – ...
- Оча торган барабанчы ул – ...
- Хат ташучы кошлар – ...
- Нинди кош, сәгате булмаса да, вакытны әйтә?
- Дөньядагы иң зур кош нәрсә?
- Нинди кош судан коры чыга?
- Нинди кош көндез йоклый, төнлә оча, кешеләрне куркыта?

4. Әйтемнәр:

а) Кош оясын туздырма, башың авыртыр.
б) Кошларга таш атма, күзең сукыраер.
в) Сыерчыкларга оя яса, эшең уңар.
г) Кош йомыркаларын ватма, күз яшеңне түгәрсең.

5. Табышмаклар:

а) Көләч түтәй гөлдерәп,
Кызыл читек, күк күлмәк.
Җим сибәбез күргәчтен
Бу кем була? ... (Күгәрчен)
б) Җәй шакылдый бу чүкеч,

Кыш шакылдый бу чүкеч.
Ничек чыдый бу чүкеч? (Тукран)
в) Чырык-чырык чыркылдый,
Бер җиргә дә ул китми.
Безнең белән дус яши,
Әйтегезче, ул ни? (Чыпчык)
г) Кырау булсын,
Кырпак булсын,
Китмәс дустым.
Җәен-кышын
Салмый сары
Алъяпкычын. (Песнәк)
д) Ала чапан киенгән,
Мал суйганга сөенгән,
Шунда төшеп йөгергән. (Саескан)
6. Театрлаштырылган уен «Кошлар белән уйныйбыз».
Кошлар берәм-берәм сайрыйлар. Калган балалар кошларны таныйлар.
Балалар: Кошлар – безнең дусларыбыз,
Сайрасалар таныйбыз.
Кошлар: Ярар, ярар, сайрарбыз,
Таныйсызмы, карарбыз.
Күгәрчен: Гөлдерү-гөлдерү, гөлдерү
Күк күгелҗем, миндер бу!
Балалар: Әйе, әйе, таныдык,
Күк күгәрчен, син бит бу.
Тукран: Тук-тук, тук итәм,
Агачтагы кортларны юк итәм.
Балалар: Тукран бит бу.
Урман докторын, әнә
Бар агачлар да дус итә.
Чыпчык: Чык-чырык, чык-чырык,
Ник көләсең шырык-шырык?
Балалар: Көлмичә, түзим ничек?
Таныдык, син бит – чыпчык.
Ярканат: З-ррр, з-ррр, ...

Балалар: Менә шулай көйләп оча,
Төнлә ул ауга чыга.
Исеме була ярканат,
Каравылчы каравылдан азат.
Уен шулай дәвам итә.

## Тема. «Кошларга ярдәм итик»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кошларга карата сак караш, кайгыртучанлык сыйфатын тәрбияләү.

2. Уйлап табуга юнәлтелгән фикер йөртү сәләтен үстерү.

3. Кошларга кешеләрнең ярдәме бик әһәмиятле булуын аңлату.

**Сүзлек:** зәһәр, саклау, куышлы агач, өшетә, зирәк, күгелҗем.

**Җиһазлар:** җимлек, кышлаучы кошлар рәсеме, кошларның битлекләре, төрле тартмалар.

### Эшчәнлек барышы

1. Тизәйткеч:
Ша-ша-ша – менә сиңа тамаша.
Шә-шә-шә – су тулы шешә.
2. «Сүзләр ясa» уены:
Аш-аш – ... (баш).
Эш-эш – ... (бәлеш).
Шы-шы – ... (чыршы).
Ыш-ыш – ... (кыш).
Ош-ош – ... (кош).
3. Үстерешле диалог «Кошларга ярдәм итик».
- Урамда кайсы вакыт?
- Һава торышы нинди?
- Кышлаучы кошларга нинди кошлар керә?
- Алар кышның зәһәр суыкларына ничек җайлашалар?
- Нинди кош кыш көне бала чыгара?
- Кышын кошларга нинди азык бирергә була?
- Кошларга ничек ярдәм итәргә мөмкин?
- Кешеләр ярдәм итмәсә, кошлар кышын нишләрләр иде?

4. Гамәли күнегү «Җимлек ясыйбыз» (кисеп ябыштыру эшчәнлеге; төрле тартмалардан кошларга җимлекләр ясау).

5. «Кайсы кош җим эзли?» уены (җимлек рәсеменә кошларның сурәтләрен ябыштыру).

6. «Иҗади табышмак» (кошлар турында табышмаклар уйлап әйтү).

7. Зирәклекне сынау:

- Песнәк түбәгә оялый аламы? (Әйе)

- Чыпчык үзен «мин кош» дип әйтә аламы? (Юк, ул сөйләшә алмый)

- Кара карга койрыгын өшетә аламы? (Юк, ул көньякта кышлый).

8. «Ни өчен шулай атаганнар?» уены. Мәсәлән: зирәк – песнәк, күгелҗем – күгәрчен, авыр хәрәкәтле – ябалак, купшы – ала карга һ.б.

9. Хәрәкәтле уен «Читлектәге кошлар».

Читлектәге кошлар музыка көенә түгәрәктә очып йөриләр. Музыка туктауга, кошлар да туктыйлар: «Безне иреккә чыгарыгыз, без читлектә ямансулыйбыз»,- диләр. Читлек булып торган балалар: «Сакланыгыз, каргалар, чыпчыклар, күгәрченнәр, сезне песи тотар!»- диләр һәм, тотынган кулларын өскә күтәреп, кошларны иреккә чыгаралар.

### Тема. Калмык халык әкиятен уку: «Күңелле чыпчык белән күңелсез карга»

**Бурычлар:**

1. Әкиятнең эчтәлегенә төшенергә булышу, матур әдәбият геройлары аша төрле начар сыйфатларга карата тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү.

2. Күрсәтмә-образлы, фикерләү сәләтен һәм үзара аралаша белү күнекмәләрен үстерү.

3. Балаларны әкият эчтәлеге буенча сорауларга тулы җавап бирергә өйрәтү, кошлар турында белемнәрен камилләштерүне дәвам итү.

**Сүзлек:** пырхылдап, күңел, көнче, төшенкелек, көенеч, чал, чук, читлек, тәкәббер, чырае сытылган.

**Җиһазлар:** кошларның койрыгы ясалган рәсемнәр, кошлар

битлекләре.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 212 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмаклар:

а) Урмый, чәчми,

Ил өстендә көн итә. (Чыпчык)

б) Нинди кош иртәдән кичкә кадәр үзенең исемен әйтеп кычкыра? (Карга)

2. Калмык халык әкиятен уку: «Күңелле чыпчык белән күңелсез карга».

3. Балаларга сораулар:

- Чыпчык ничек яши?
- Чыпчыкның күңеле ни өчен шат?
- Карга нигә кәефсез утыра?
- Чыпчык кара каргага ничек җавап биргән?
- Көнчелектән кара карга нишли?
- Тормышта төшенкелеккә бирелергә ярыймы, ни өчен?
- Сез каргага нинди киңәшләр бирер идегез?

4. «Мәкаль нәрсә турында?» уены.

а) Кеше кулындагы калач зур күренә.

б) Көнче көне көенеч.

в) Көнченең күңеле тар булыр.

г) Күрше тавыгы күркә булып күренер.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

5. «Нәрсә койрыгы?» уены.

Нинди дә булса бер кош койрыгы ясалган рәсем күрсәтелә. Шул рәсемгә карап, кош исеме әйтелә.

6. Уен-реклама «Яраткан кошым».

7. Хәрәкәтле уен «Читлектәге кошлар» (кабатлап уйнау).

Читлектәге кошлар музыка көенә түгәрәктә очып йөриләр. Музыка туктауга, кошлар да туктыйлар: «Безне иреккә чыгарыгыз, без читлектә ямансулыйбыз»,- диләр. Читлек булып торган балалар: «Сакланыгыз, каргалар, чыпчыклар, күгәрченнәр, сезне песи тотар!»- диләр һәм, тотынган кулларын өскә күтәреп, кошларны иреккә чыгаралар.

## Проект. Йорт хайваннары һәм кошлары
### Тема. «Авылда ишегалды»

**Бурычлар:**

1. Балаларда үз фикерләрен дустының фикере белән чагыштырып карый белү, бер-берсен игътибар белән, бүлдермичә, сабыр гына тыңлый белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Тышкы билгеләренә (зурлыгы, үз-үзләрен тотышларына, тавышларына) карап, кыргый һәм йорт хайваннарын аерып күрсәтә белү күнекмәләрен үстерү.

3. Үзләренең белгәннәрен бәйләнешле итеп, хикәя формасында сөйләргә өйрәтү эшен дәвам итү.

**Сүзлек:** бәйләнгән кофта, йон оек, йозак, мылтык.

**Җиһазлар:** «Сыер савучы», «Кошчы» рәсемнәре, аудиоязмада «Йорт хайваннарының тавышлары», интерактив такта, Г.Тукайның «Кәҗә белән сарык» әкияте буенча мультфильм.

### Эшчәнлек барышы

1. Аудиоязма тыңлау: «Йорт хайваннарының тавышлары».

2. Үстерешле диалог.

- Сез нинди тавышлар ишетәсез?
- Сез үзегезне кайда дип хис иттегез?
- Йорт хайваннарын кешеләр ни өчен асрыйлар?
- Кешеләр алар турында ничек кайгырта?
- Авыл кешеләре шәһәр кешеләренә нинди ярдәм күрсәтә?
- Йорт хайваннарының һәм кыргый хайваннарның нинди аермалары бар?

3. Эрудит уен (интерактив такта яки рәсемнәр белән).

Мәсәлән: сөт, эремчек, сыр, каймак һ.б. – сыер.

Итек, йон, бияләй, оекбаш һ.б. – сарык.

Йозак, мылтык һ.б. – эт.

Йөкле арба, кымыз һ.б. – ат.

4. Дидактик уен «Нәрсә артык?» (йорт хайваннары рәсемнәре арасына кыргый хайваннар, йорт кошлары рәсемнәре куела).

5. Артикуляция гимнастикасы: «Ватык телевизор» (иреннәр, тел һәм тешләр ярдәмендә, тәрбияче күрсәткән рәсемгә карап,

йорт хайваннарының тавышларын чыгару).

6. Мультфильм карау. «Кәҗә белән сарык» әкияте.

### Тема. Рәсем буенча хикәя төзү. «Йорт хайваннары. Ат белән колын»

**Бурычлар:**

1. Балаларда үз фикерләрен башкаларга төгәл итеп җиткерә алу, бер-берсен тыңлый белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның күзәтүчәнлеген, кызыксынучанлыгын, бәйләнешле сөйләмен үстерү.

3. Рәсем буенча эзлекле хикәя төзү, җөмләдә сүзләрне яраштырып сөйли белү күнекмәләрен камилләштерү, йорт хайваннарының яшәү рәвеше турында белемнәрен системалаштыру.

**Сүзлек:** ял, тырпая.

**Җиһазлар:** «Ат белән колын» рәсеме, аудиоязмада «Авыл иртәсе», туп.

### Эшчәнлек барышы

1. Аудиоязма тыңлау: «Авыл иртәсе» (нинди тавышлар ишеттегез?).

2. Туп белән уен «Баласын әйт!» Мәсәлән: сарык – бәрән, сыер – бозау, ат – колын, эт – көчек, песи – песи баласы, кәҗә – кәҗә бәтие һ.б.

3. Табышмак:

Тимерче дә түгел,
Балта остасы да түгел,
Үзе авылда беренче эшче. (Ат)

4. Рәсем карау: «Ат белән колын».

- Бу рәсемдә нәрсәләр күрәсез?
- Ат нинди?
- Ат белән колын бер-берсенә охшаганмы?
- Кайсы яклары белән алар аерылып тора?
- Атлар кешегә нинди файда китерә?
- Сез бу рәсемгә нинди исем бирер идегез?

5. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала сөйли).

6. Сүзле-хәрәкәтле уен «Тавыш бирче, ишетим!»

Балалар түгәрәккә басалар, уртада бер бала тора. Уртадагы күзе бәйләнгән бала:

Әй, эзлимен, эзлимен,
Күзем бәйле, күрмимен.
Аткаем (сыеркаем, кәҗәкәем һ.б.),
Кайда син?
Тавыш бирче, ишетим!

Тәрбияче күрсәткән бала йорт хайваннарының тавышын чыгара. Күзе бәйләнгән бала танып, ул баланың исемен әйтергә тиеш була. Дөрес әйтсә, урыннарын алышалар.

7. Үстерешле уен «Адашкан сүзләр» (бирелгән сүзләрдән дөрес җөмләләр төзү).

а) Ярата, ашарга, солы, ат.
б) Ташыйлар, төрле, атлар, йөкләр.
в) Китерә, зур, кешегә, файда, атлар.
г) Яратам, атларны, мин, бик.

## Тема. Әкиятнең эчтәлеген сөйләү.
## «Үрдәк беренчелекне алган»

**Бурычлар:**

1. Әкият геройларының гамәлләре аша төрле начар сыйфатларга: мактануга, кыланчыклыкка карата тискәре мөнәсәбәт тәрбияләү.

2. Балаларны игътибар белән тыңларга, сорауларга тулы җөмләләр ярдәмендә җавап бирергә күнектерү, иҗади уйлау, фикерләү сәләтләрен үстерү.

3. Балаларны тыйнак, итагатьле булырга өйрәтүне дәвам итү, монологик сөйләм күнекмәләрен камилләштерү.

**Сүзлек:** хәбәр, һөнәр, хәйран, игътибар, шаркылдап, көлгән, чалыш атлап, мәтәлеп киткән, гөр килеп, ләгән.

**Җиһазлар:** әкият эчтәлеге буенча рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 489 бит.

## Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Мактану һәркемне хур итә,
Тыйнак булуга ни җитә.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Табышмаклар:

а) Канаты бар,
Аягы бар,
Йөзә алмый (Тавык)

б) Су төбенә төшә,
Чыланмыйча чыга (Үрдәк)

в) Үлән ашый, май ташый (Сыер)

г) Сакалы бар, акылы юк (Кәҗә)

3. Әкият уку: «Үрдәк беренчелекне алган».

4. Балаларга сораулар:

- Тавык белән үрдәк нинди яңа хәбәр белдергәннәр?

- Йорт хайвашлары һәм кошлары ничек итеп һөнәрләрен күрсәткәннәр?

- Комиссия әгъзалары Аю белән Төлкегә үрдәкнең һөнәре ни өчен ошаган?

- Булдыра алмаган эшкә алыну кирәкме?

5. Әкиятнең эчтәлеген сөйләү (6 – 7 бала сөйли).

6. Санамыш «Мактанчыкка – буш капчык»:

Арыш-бодай игәбез,
Аны болай бүләбез:
Тигез, уңган, таза, нык,
Ялкау, чытык, мактанчык,
Мактанчыкка – буш капчык,
Буш капчык, уеннан чык!

7. Уен «Энә, җеп, төен».

Балалар, кулга-кул тотынып, түгәрәккә басалар. Бер бала – энә, икенчесе – җеп, өченчесе – төен булып, бер сафка тезеләләр. Энә, балалар арасыннан төрлечә йөреп, җеп белән төенне адаштырырга тырыша. Калган балалар, бер-берсеннән калмыйча, аның артыннан йөриләр. Әгәр берсе адашып калса, аның урынында икенче бала уйный. Ә адашкан бала түгәрәккә баса.

## Проект. Транспорт. Юл йөрү кагыйдәләре
### Тема. «Транспорт төрләре белән танышу»

**Бурычлар:**

1. Балаларда транспорт йөртүче һөнәр ияләренә карата хөрмәт, ихтирам һәм урамда, транспортта үз-үзләрен дөрес тоту сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның иҗади активлыгын, фикерләү сәләтен үстерү.

3. Коры җир, су һәм һава транспорты чараларын аера белергә, аларны чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтүне дәвам итү, һәр төр транспорт турындагы күзаллауларын киңәйтү.

**Сүзлек:** юрга, машинист.

**Җиһазлар:** «Машина йөртүче», «Машинист», «Очучы», «Регулировщик» рәсемнәре, төрле транспорт рәсемнәре, жезл, регулировщик киеме.

**Эшчәнлек барышы**

1. Үстерешле диалог.

- Сез балалар бакчасына нәрсә белән киләсез?
- Безнең шәһәрдә (авылда, авылдан авылга, авылдан район үзәгенә) нәрсәләргә утырып йөриләр?
- Нинди транспорт төрләре бар?
- Аларны кем йөртә?
- Нинди һава транспортын беләсез?
- Су транспортларын беләсезме?
- Нинди транспортны җир өсте транспорты дип атыйлар?

2. «Табышмак әйтәм – җавабын тап!» (балалар нинди төр транспорт икәнен әйтәләр).

а) Тәгәрмәчләр өстендә
Зур гына арбасы бар.
Арбаның эченә салып,
Бик күп йөкләр ташыйлар. (Машина)

б) Тәрәзәле һәр ягы,
Җиргә тими аягы.
Сыртында бар дугасы,
Я, бу нинди юрга соң? (Трамвай)

в) Канаты бар, җилпеми,
Эче җылы – җил тими.
Корыч йөрәкле кош ул,
Безнең яраткан дус ул. (Самолёт)
г) Уф-пуф сулар,
Уфтанса да алып китәр,
Барыр җиренә җитәр. (Поезд, тепловоз)
д) Аяклары түгәрәк,
Куышалар тәгәрәп.
Үзем утырам, үзем чабам
Теләсә кая таба. (Велосипед)
е) Үзе бара – эзе юк,
Маңгаенда күзе юк. (Көймә)

3. «Булсаң зирәк – әйт тизрәк!»

- Ашап булмый торган баранка ни ул?
- Җир асты тимер юлы ничек атала?
- Нигә барлык автомобильләрдә дә тормоз бар?
- Поезд килер алдыннан ни өчен шлагбаум төшерелә?
- Юл нинди өлешләргә бүленә?
- Очкычны (самолётны) кем йөртә?
- Транспорт һәм җәяүлеләр хәрәкәтен төсле сигналлар белән көйләүче кем?
- Светофорның төсләре нәрсә аңлата?

4. Мәкальләр:

а) Юлда йөргәндә дә акыл кирәк.
б) Юлда йөрсәң, уяу йөр.
в) Ашыккан ашка пешкән, йөгергән суга төшкән.
г) Үзең кабалансаң, атың да абына.
д) Урау булса да, юл яхшы.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

5. Дидактик уен «Дөрес җавап бир!» (төрле транспорт чаралары арасыннан билгеле бер транспортны табу). Мәсәлән:

- Төзелештә кайсы транспорт кирәк?
- Янгын сүндерү өчен нинди машина кирәк?
- Кайсы машина юлда тәртип саклый?
- Ашыгыч медицина машинасы ... ?

6. Хәрәкәтле уен «Регулировщик».

Урам чатлары ясала, анда җәяүле юлы билгеләнә, уртада регулировщик басып тора. Балалар ике төркемгә бүленәләр: машиналар һәм җәяүлеләр. Алар сигнал буенча хәрәкәтләнәләр. Кагыйдә бозылса, регулировщик сыбызгысын сызгырта һәм кагыйдә бозучыга аңлатма бирә.

## Тема. Әңгәмә: «Юл йөрү кагыйдәләре кирәк безгә һәр көнне»

**Бурычлар:**

1. Әдәплелек кагыйдәләрен саклау, үз-үзеңне тоту культурасы формалаштыру.

2. Балаларның юл йөрү кагыйдәләре турында фикерләү сәләтен, игътибарын үстерү.

3. Балаларның юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен киңәйтү, юл йөрү билгеләрен һәм яңа терминнар өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** регулировщик, тукталыш, пассажир, бүлү полосасы, урам чаты, шлагбаум.

**Җиһазлар:** балалар санынча рульләр, төсле флаглар, слайдлар (рәсемнәр), рәсем-схемалар.

### Эшчәнлек барышы

1. Әйтем «Юлларда сак булырга кирәк!»

2. Тел чарлау:

- Транспортта баручы ничек дип атала? (Пассажир)
- Кечкенә балаларны машинада йөртү өчен нәрсә таләп ителә? (Балалар кәнәфие)
- Электр белән нинди төр транспорт йөри? (Трамвай, троллейбус)
- Юл чатында нәрсә тора? (Светофор)
- Светофорны кайбер вакытта кем алыштыра? (Регулировщик)
- Транспортның туктавын кайда көтәләр? (Тукталышта)
- Юл йөрү кагыйдәләре ни өчен кирәк? (Бәлагә юлыкмас өчен, аварияләр булмасын өчен)

3. Слайдлар яки рәсемнәр карау. «Юл йөрү билгеләре белән танышу».

Кисәтүче билгеләр: «Балалар», «Җәяүле», «Куркыныч борылыш», «Бүлү полосасы», «Ике яклы хәрәкәт», «Юл эшләре», «Шлагбаумлы тимер юл».

Тыючы билгеләр: «Йөк машиналарына керү тыела», «Узу тыела», «Велосипедта йөрү тыела», «Җәяүлеләр керү тыела», «Хәрәкәт тыела», «Уңга (сулга, кирегә) борылу тыела».

Мәгълүмат бирүче билгеләр: «Телефон», «Ашыгыч ярдәм пункты», «ДАИ посты», «Техник ярдәм пункты», «АЗС», «Туклану пункты», «Туктау урыны».

4. Хәрәкәтле уен «Төсле машиналар».

Балалар бүлмәнең бер ягында торалар. Алар машиналар. Һәр балага бер төсле руль бирелә. Тәрбияче уртада төсле флаг күтәрә, балалар шуңа карап юл буенча хәрәкәтләнәләр, юл кагыйдәләрен үтиләр. Икенче төстәге флаг күтәрелгәч, машиналар гаражга кайталар.

5. Уен. «Транспортта үз-үзеңне тоту кагыйдәләре» (рәсем-схемалар кулланып).

а) Автобус, трамвай, троллейбуска арткы ишектән керергә кирәк.

б) Автобустан чыкканда алгы ишектән чыгарга кирәк.

в) Транспорт эчендә тыныч утырырга, кычкырып сөйләшмәскә кирәк.

г) Өлкәннәргә урын бирергә онытмаска кирәк.

6. Мәкальләрне кабатлау:

а) Юлда булсаң, уяу йөр.

б) Юлда йөргәндә дә акыл кирәк.

в) Урау булса да, юл яхшы.

г) Ашыккан – ашка пешкән, йөгергән суга төшкән.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

## Тема. Шигырь ятлау. Г.Юнысова «Светофор»

**Бурычлар:**

1. Балаларда урамда, юлда үз-үзләрен дөрес тоту, бер-берсенә игътибарлы булу, сабырлык кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләү.

2. Шигырь аша светофор турындагы белемнәрен ныгыту, сәнгатьле уку күнекмәләрен үстерү.

3. Шигырьне яттан сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** фәрман, озын агай.

**Җиһазлар:** «Милиционер-регулировщик» рәсеме, светофор рәсеме, юл билгеләре.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 413 бит.

## Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Алмаш-тилмәш өч күз яна:
Яшел, сары һәм кызыл.
Урамда исән йөрергә
Булыша ул көнозын. (Светофор)

2. Шигырь уку: Г.Юнысова. «Светофор».

3. Балаларга сораулар:

- Озын агайның нинди өч күзе бар?
- Икесе сүнеп торганда, берсе нишли?
- Юл аша чыкканда ни өчен күзләргә карыйбыз?
- Сары күз нинди сүз әйтә?
- Кызыл күз нинди сүз әйтә?
- Яшел күз нәрсә әйтеп елмая?

4. Шигырьне яттан сөйләү (6 – 7 бала сөйли).

5. Хәрәкәтле уен «Светофор утлары».

Светофорда – кызыл ут!
Юл хәтәр – үтү юк!
Ә сары утны күрсәтсә –
«Әзерлән»,- дип кисәтә.
Яшел утны ул алды –
Чыга башла, юл бушады.

Бу уенда барлык балалар да – җәяүлеләр. Хәрәкәт көйләүче светофорда сары сигнал күрсәтә – балалар тезелешеп хәрәкәт башларга әзерләнәләр. Яшел ут янгач, йөрергә, сикерергә мөмкин. Кызыл ут янгач, барысы да урыннарында туктап калалар. Ялгышучы уеннан чыгарыла.

## Проект. Һөнәрләр

### Тема. Балалар бакчасы буйлап сәяхәт.
### «Безне җырларга кем өйрәтә?»

**Бурычлар:**

1. Балаларда борынгы бабаларыбыз уйнаган уен коралларына карата кызыксыну, сакчыллык сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлекләрен үстерү.

3. Музыка җитәкчесенең хезмәте турында белемнәрен тирәнәйтү.

**Сүзлек:** гомерлек, сәнгать остасы, милли, думбра, скрипка, быргы, курай.

**Җиһазлар:** музыка кораллары яки рәсемнәр, аудиоязмада «Үз җырыбыз» (Ә.Яруллина сүзләре, Ф.Галимов көе).

**Эшчәнлек барышы**

1. Дидактик уен «Сүзләр кайсы авазлар белән аерыла?» Мәсәлән: кош – көч, кач – каш, иҗек – ишек, җир – чир, шәл – җәл һ.б.

2. Балаларга сораулар: «Кем ул?» (слайдлар яки рәсемнәр карау).

- Кем тәмле ашлар пешерә?
- Кем матур күлмәкләр тегә?
- Кем авыруларны дәвалый?
- Кем пианинода, гармунда уйный?
- Кем кызыклы тестлар үткәрә?
- Кем балаларны күп нәрсәләргә өйрәтә?
- Кем җырларга өйрәтә?

3. Музыка залына сәяхәт.

- Хезмәт итү, эшләү – нәрсә ул?
- Сез бакчада нишлисез?
- Бакчада эшләүче апалар нәрсәләр эшлиләр?
- Бу нинди бүлмә? Ни өчен кирәк?
- Музыка залында кем эшли?
- Музыка җитәкчесе балаларны нәрсәгә өйрәтә?
- Нинди музыка кораллары була?

- «Җыр, музыка – кешенең гомерлек юлдашы» дип әйтелә халык телендә, ә сез ничек уйлыйсыз?

- Татар халкының сәнгать осталарыннан (җырчы һәм композиторлар) кемнәрне беләсез?

- Элек-электән татар халкы нинди милли музыка коралларында уйнап моңланган? (рәсемнәр яки уен кораллары карау).

4. Тапкырларга – табышмак.

а) Җебенә тисәң – елый,
Колагын тартсаң – чыңлый. (Думбра)

б) Сары сандык сатып алдым,
Үзе нәни генә.
Төрле тавышка җырлый белә. (Скрипка)

в) Эче буп-буш,
Тавышы дөньяга сыймый. (Барабан)

г) Авызы юк – кычкыра,
Теле юк – чакыра. (Быргы)

д) Тартма өстендә таяк,
Таякта җиде җеп.
Җиде җептә –
Җитмеш сайрар кош. (Гитара)

е) Сырлы-сырлы, сырлы ул,
Безнең кулда җырлый ул. (Гармун)

ж) Авызы бар – теле юк,
Тавышы бар – сүзе юк. (Курай)

5. Шигырь уку: Ф.Яруллин. «Моңлы курай».

Уйнар идем, гармуным юк,
Җырлар идем – тавышым.
Кисеп алып, курай иттем
Елгабызның камышын.
Әйтәләр миңа кешеләр:
«Моңлы»,- диләр уйнавың.
Минем монда катнашым юк –
Үзе моңлы кураем.

6. Әйтемнәр.

а) Барабан тавышы ерактан яхшы.

б) Кубыз биетми, моңы биетә.

в) Скрипка искергән саен яхшырыр.

г) Ярык курай уйнамас.

д) Өзелгән кылдан өзек җыр чыга.

е) Һәр заманның үз көе.

7. Җыр тыңлау: «Үз җырыбыз» (Ә.Яруллина сүзләре, Ф.Галимов көе).

## Тема. Әңгәмә. «Әти-әни һөнәре»

**Бурычлар:**

1. Балаларда хезмәткә хөрмәт тәрбияләү.
2. Төрле һөнәр ияләренә карата кызыксынучанлыкларын үстерү.
3. Рәссам-дизайнер һөнәре турында балаларның белемнәрен арттыру.

**Сүзлек:** һәйкәл, һөнәр, ялкау, мал, белемле, уңган, тырыш, иренү, дошман.

**Җиһазлар:** «Тегүче», «Буяучы», «Рәссам», «Хат ташучы», «Сатучы», «Чәчтараш», «Китапханәче», «Төзүче» рәсемнәре, слайдлар.

## Эшчәнлек барышы

1. Уен. «[h] син кайда?»

- [h], син кайда?

- Шәһәрдә... (һавада, һәйкәлдә, һәрвакытта, һөнәрдә, һәркемдә h.б.).

2. Кызык мәзәк: «Ул да эшли».

Иртә белән барысы да ашыгып эшкә барырга җыеналар. Кечкенә кыз Сәлимә болай ди: «Мин дә эшкә барам». «Ә кайда эшлисең соң син?»- дип сорыйлар. «Балалар бакчасында»,- дип җавап бирә Сәлимә.

3. Әңгәмә. «Әти-әни һөнәре» (слайдлар яки рәсемнәр ярдәмендә).

- Нәрсә ул һөнәр?

- Нинди кеше генә башлаган эшен азагына кадәр җиткерә ала?

- Андый кешеләр турында халыкта нәрсә диләр?

- Тырышлыкның иң зур дошманы нәрсә?
- Нәрсә ул ялкаулык?
- Нинди хезмәт хөрмәткә лаек?
- Әти-әниегез нинди эштә эшли?
- Сез кем булыр идегез?

4. Тәрбияче хикәясе: «Рәссам-дизайнер һөнәре» (слайдлар яки рәсемнәр ярдәмендә).

Алиянең әтисе рәссам-дизайнер булып эшли. Дизайнер – төрле өлкәләрдә кешенең иҗтимагый таләпләрен зәвыклы итеп тормышка ашыручы. Дизайнерлар төрле өлкәләрдә эшлиләр: өй җиһазлары, кием-салым, аяк киемнәре, автомобиль сәнәгатендә, архитектура өлкәсендә, фасадларны, ландшафтларны, флористика-чәчәкләрне зәвыклы итеп бизәү өстендә эшли. Рәссам-дизайнер программалар, эскизлар, макетлар төзи. Журналлар, буклетлар матурайтуны тормышка ашыра. Бу һөнәр бүгенге җәмгыятьтә икътисадның үсешендә иң кирәкле һөнәрләрнең берсе булып тора.

5. Дидактик уен «Мәкальгә нинди сер яшерелгән?»

а) Кешенең кешелеге сүз белән түгел, эш белән.

б) Эш яратудан осталык туа.

в) Эшсез үткән бер көнең – елдан да озынрак.

г) Зур максатың барында, эшеңне ял дип сана.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

6. «Сикергеч сүзләр» уены.

Тәрбияче сүзләр әйтә, балалар сүзне тиешле басым белән иҗекләп әйтә-әйтә, иҗек санынча сикерәләр. Мәсәлән: тө-зү-че, пе-шек-че, укы-ту-чы һ.б.

## Тема. Шигырь уку: Э.Мөэминова. «Фокусчы»

**Бурычлар:**

1. Балаларда һөнәр осталарының матур эшләренә соклану, аларның хезмәтенә хөрмәт, горурлык хисләре тәрбияләү.

2. Яңа сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүзлек запасын баету, диалогик сөйләм үстерү.

3. Бирелгән шигырь аша фокусчының хезмәте турындагы

белемнәрен киңәйтү.

**Сүзлек:** фокус, ышанмастай, аждаһа, хәйләли.

**Җиһазлар:** фокусчы киеме, өч стакан, өч төрле буяу, икегә бүленгән озынча тартма, чәчәк, яулык, әфлисун, алма.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 399 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Тел шомарткыч:

Це-це-це – концерт.

Ци-ци-ци – Люция.

Ци-ци-ци – цирк.

2. «Табышмак әйтәм – җавабын тап!»:

Башкалабыз Казанда

Зур тәлинкә бар анда.

Аю бии, арыслан сикерә,

Бу нинди җир була? (Цирк)

3. Шигырь уку: Э.Мөэминова. «Фокусчы».

4. Балаларга сораулар:

- Бар кешегә фокусчы нәрсә күрсәтә?
- Нинди эшләрне ышандырырлык итеп эшли?
- Салкын су нәрсәгә әверелә?
- Фокусчы тагын нинди фокуслар күрсәтә?
- Фокусчы хәйләли беләме?
- Ул ничек итеп үз эшенең остасы булган?
- «Тырышкан табар, ташка кадак кагар» дигән мәкальнең эчтәлеген ничек аңлыйсыз?

5. Фокус алымнары:

а) Өч үтә күренмәле стаканның төбендә – өч төрле буяу. Шул стаканнарга су саласың. Тылсымлы сүз әйтәсең. Мәсәлән: «Әфсен-төфсен, могҗизалар килеп чыксын!» Өч төрле төстә су барлыкка килә.

б) Озынча тартма икегә бүленгән. Тартманың бер ягына чәчәк куелган, ә икенче ягы буш. Тылсымчы тартманың буш ягын күрсәтә һәм, тылсымлы сүз әйтеп, тартманы әйләндерә. Шуннан соң чәчәкле ягын күрсәтә.

в) «Алмалы әфлисун буламы?» Фокусчы әфлисун күрсәтә,

аннары аны яулык белән каплап: «Әфсен-төфсен, фокус килеп чыксын»,- ди дә, яулыкны күтәреп, читкә алып куя. Өстәлдә әфлисун урынында алма ята. Фокусның сере: бу фокуска алдан әзерләнергә кирәк. Кабыгын бозмыйча, әфлисунны чистартырга, аннары кабык эченә кечерәк алманы яшерергә кирәк. Яулыкны алган вакытта, беркемгә дә сиздермичә, кабыкны да алырга кирәк.

6. Үстерешле уен «Ышанам, ышанмыйм, чөнки ...».

Тәрбияче: «Кыш көне кояш кыздыра». Бала: «Ышанмыйм, чөнки кыш көне кояш кыздырмый, ә яктырта гына».

## Тема. Укытучы хезмәте белән таныштыру. «Укытучы»

**Бурычлар:**

1. Балаларда белем алуга омтылыш, укытучы хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.
2. Балаларның фикерләү сәләтен, бәйләнешле сөйләм телен үстерү.
3. Балаларны укытучы хезмәте белән таныштыруны дәвам итү.

**Сүзлек:** хушлашу, кое казу, кызыксынучан, чыдам, ышанычлы, указка.

**Җиһазлар:** «Укытучы» рәсеме, сюжетлы-рольле уен өчен кирәк-яраклар.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 533 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Укырга да өйрәтә,
Язарга да өйрәтә,
Аны белә һәр кеше –
Ул була ... (Укытучы)

2. Шигырь уку: Б.Рәхмәт. «Мәктәпкә».

3. Фикер алышу:

- Балалар 1 нче сентябрьдә кая баралар?
- Мәктәпкә баручы балаларны кем дип атыйлар?

- Аларны кем укыта?

- Укучылар нинди билгене бик яраталар?

- «Уку – энә белән кое казу» мәкален сез ничек аңлыйсыз?

4. Үстерешле уен «Сүз эчендә энҗе бар».

«Укытучы» сүзенә кергән авазларга туры китереп, укытучыга хас матур сыйфатларны әйтеп чыгу. Мәсәлән:

У – уңган ...

К – кешелекле, кызыксынучан ...

Ы – ышанычлы ...

Т – тәрбияле, тырыш, түземле ...

У – укымышлы ...

Ч – чыдам ...

Ы – ышандыручан ...

5. Уен-реклама: «Нинди дәрес кирәклерәк?»

Түгәрәктә баскан балаларга көй уйнаганда указка җибәрелә. Көй туктагач, кулында указка калган бала үзе сайлап алган дәресне мактап сөйли. Мәсәлән: физкультура – сәламәтлекне ныгыта, төз, матур буласың. Йөгереп, сикереп була. Физкультураны яратыгыз!

6. Җырлы-биюле уен «Кәрия-Зәкәрия».

Балалар, кулга-кул тотынышып, түгәрәкләнеп басалар. Уртага бер бала чыга. Түгәрәктәгеләр бер якка хәрәкәт итеп җырлыйлар. Җырларда уртадагы баланың җыр-биюдә, хезмәттә, укуда булган сәләте, уңганлыгы мактала:

Бу бик яхшы биюче,

Бу бик яхшы биюче, }2 тапкыр.

Аның биюе матур,

Аннан үрнәк алыгыз. }2 тапкыр.

Җырдан соң түгәрәктәгеләр туктап калалар, кул чабып такмак әйтәләр:

Кәрия, Зәкәрия, коммая,

Кәрия, Зәкәрия, коммая.

Кәри комма, Зәкәр комма,

Зәкәрия, коммая ... } 2 тапкыр. Бу вакытта уртадагы бала бер иптәшен алып, әйләнеп тора.

7. Сюжетлы-рольле уен «Мәктәп».

## Проект. Мультфильмда кунакта
### Тема. Әкиятне дәвам итеп сөйләү. «Күчтәнәч»тә кунакта»

**Бурычлар:**

1. Балаларда матур әдәбият белән кызыксыну һәм аны ярату хисләре тәрбияләү.

2. Үз фикерен ана телендә эзлекле, җыйнак, төгәл һәм матур итеп әйтеп бирә белү, иҗади фикерләү сәләтен үстерү.

3. Сорауларга тулы, төгәл җавап бирергә, геройларның кылган эшләренә, әхлакый сыйфатларына бәя бирә белергә, әкиятләрне һәм мәзәкләрне сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** рәссам, тылсым, сихер, үтенеч, күчтәнәч.

**Җиһазлар:** эчтәлекле рәсемнәр, буталган мультфильм геройлары турында рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак:

Бу ясалма тәрәзәгә
Дөнья хәлләре сыя.
Кичләрен ул үз алдына
Бөтен гаиләне җыя. (Телевизор)

2. Фикер алышу:

- Сез телевизордан нинди тапшырулар карарга яратасыз?
- «Күчтәнәч» тапшыруын караганыгыз бармы?
- Ул нинди көннәрдә, кайсы вакытта һәм нинди телдә алып барыла?
- Бу тапшыруны кемнәр алып бара? Анда нәрсә күрсәтәләр?
- Татар мультфильмнарының кайсылары сезгә охшый?

3. Үстерешле уен «Табышмак – рәсем».

- Рәсемдә нинди мультфильм геройлары бар?
- Әкиятләрнең авторлары кем?
- Рәссам нинди хаталар җибәргән? (Шүрәле кулында алтын тарак, төлке белән торна бер казаннан ашыйлар, су анасының маңгаенда мөгезе бар һ.б.)

4. Дидактик уен «Тылсым ияләре».

Тылсым ияләре геройларының тылсымнарын искә төшерү.

Мәсәлән: Убырлы карчык – сихер ярдәмендә кешеләрне төрле кыяфәткә кертергә сәләтле, Чуртан – Емеляның үтенечләрен үти, Алтын балык – һ.б.

5. «Мин башлыйм, син дәвам ит!» уены.

«Күчтәнәч» тапшыруына әкият уйлап табу. Тәрбияче башлый, балалар әкиятне үзләре уйлап тәмамлый. Мәсәлән: борын-борын заманда Актырнак белән Мыраужан исемле ике дус яшәгәннәр. Актырнак йортны чит кешеләрдән, ә Мыраужан өйне күселәрдән саклаган. Алар ашаганда да, йоклаганда да бергә булганнар. Бу дуслыкларын хуҗалары да яраткан, намуслы хезмәтләре өчен аларны тәмле ризыклар белән сыйлаган. Бер көнне ...

6. Балалар иҗаты (6 – 7 бала сөйли).

7. Җырлы-биюле уен «Йөзек яшереш».

Балалар түгәрәккә басып җырлыйлар:

Сөләйманның йөзеген
Дию кызы урлаган.
Каф тавының артында
Алтын сандыкка салган.
Көтүче: Йөзек анда калмаган,
Аннан песи урлаган.
Киң дәрьяны чыкканда
Суга төшереп калдырган.
Күмәк җыр: Инде йөзек югалган,
Табалмассың, уңмаган.
Көтүче: Киң дәрья туңмаган,
Йөзек синдә булмаган!- дип, берәүнең кулын тота. Әгәр дә йөзек ул баладан чыкса, ул көтүче була. Әгәр дә йөзек ул баладан чыкмаса, баштагы көтүче үз урынында кала.

### Тема. Әңгәмә. «Әкиятләр иленә сәяхәт»

**Бурычлар:**

1. Бергә уйный торган иптәшләренең фикере белән исәпләшә, бәхәсләрне гадел хәл итә белүчәнлек тәрбияләү.

2. Балаларның иҗади күзаллауларын үстерү.

3. Балаларда яхшы һәм начар төшенчәләрен формалаштыру, үзен һәм башкаларны дөрес бәяли белергә, уңай һәм тискәре якларны күрә белергә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** бакылдык, чыелдык, куркаккай, хәйләбай, соры колак, камыт аяк.

**Җиһазлар:** хат белән конверт, интерактив такта яки рәсемнәр, магнитлы такта, костюмнар, аудиоязмада «Шүрәле» балетыннан музыка(Ф.Яруллин).

## Эшчәнлек барышы

1. Саесканнан килгән хат уку.

Тәрбияче: «Хөрмәтле балалар! Безнең әкиятләр иленә афәт килде. Явыз тылсымчы килеп, бөтен әкияттәге геройларны бутап китте. Хәзерге көндә нәниләребезгә әкият күрсәтә дә, сөйли дә алмыйбыз. Сездән зур ярдәм сорап: барлык әкият геройлары».

2. Дидактик уен «Дөрес сайлап ал!» (интерактив тактада яки рәсемнәр белән).

Буталып беткән әкият геройлары рәсемнәрен дөрес аерып куярга һәм кем язганын әйтергә кирәк. Мәсәлән: Г.Тукай – «Шүрәле», «Кәҗә белән сарык», «Су анасы», А.Алиш – «Койрыклар», «Сертотмас үрдәк» һ.б.

3. Әдәби викторина:

- Әкиятләр, гадәттә, ничек башлана?
- Әкияттә нинди холыклы геройлар була?
- Чуар тавык әби белән бабайга нинди вәгъдә биргән?
- Былтыр исемле егет кайсы әкият герое?
- Өч кызның кайсысы игелекле булган?
- Сыерчыкның мактанчык күршесе нинди кош?
- Нинди кошлар кечкенә малайны канатларына утыртып алып киткәннәр?
- Боздан салынган өй ныкмы, әллә кайрыдан салынганымы?
- Бүре башыннан курыкмаган нинди йорт хайваннарын беләсез?
- Эт белән тычкан арасындагы шалкан тартырга булышучы нәрсә?
- Куян кызы ни өчен елый?

4. Үстерешле уен «Бел!»

- Әкиятләрдә аларны ничек атыйлар?

| | |
|---|---|
| Бака – ... (бакылдык) | Төлке – ... (хәйләбай) |
| Тычкан – ... (чыелдык) | Бүре – ... (соры колак) |
| Куян – ... (куркаккай) | Аю – ... (камыт аяк) һ.б. |

5. Режиссёр уены: «Мин әкиятче» (өстәл театры).

Балалар үзләре уйлап тапкан әкияткә исем кушып сәхнәләштерәләр.

6. «Ялгышма» уены.

Тәрбияче хәрәкәтләрне куллар белән чәбәкләп чиратлаштыра. Балалар тәрбияче күрсәткән хәрәкәтләрне ялгышмыйча кабатлый. Уен азагында хәрәкәтләр ешрак алышына һәм катлауландырыла.

7. Конкурс: «Актёрлык осталыгы».

1 нче бирем. Сорауларга җавап бирегез.

- Чаллы (Казан, Әлмәт …) шәһәрендә нинди театрлар бар?

- Сезнең кайсы театрда булганыгыз һәм нинди спектакльләр караганыгыз бар?

2 нче бирем. «Иң оста башкаручы». Төлке, күбәләк, әби, теше сызлаган кеше һәм башкаларның образларын мимика һәм төрле хәрәкәт аша күрсәтегез.

3 нче бирем. Җырлы-биюле уен «Түбәтәй».

4 нче бирем. Ф.Яруллинның «Шүрәле» балетыннан өзек тыңлап, күз алдына килгән әйберне сурәтләгез.

5 нче бирем. Һәр адым саен белгән әкият исемен әйтегез.

## Проект. Мин дөньяның бер кешесе

### Тема. Әңгәмә. «Мин бәхетле, мин хокуклы»

**Бурычлар:**

1. Балаларда әхлакый сыйфатлар, әти-әнигә хөрмәт тәрбияләү.

2. Игътибар белән тыңларга, сорауларга тулы җөмләләр белән җавап бирергә күнектерү, фикерләү сәләтен үстерү.

3. Балаларның гаиләдәге хокуклары турындагы белемнәрен ныгыту, аларның ялга, уенга хокуклы булуларын аңлату.

**Сүзлек:** хокуклы, яшәү урыны, саклыйлар, яклыйлар, кай-

гырталар, иҗат үзәге.

**Җиһазлар:** телевизор макеты, яшел яулык, сюжетлы рәсемнәр (балалар мәктәптә, балалар бакчасында, иҗат үзәгендә), указка, «Ике кыз» мультфильмы.

**Эшчәнлек барышы**

1. Телевизор карау: «Һәрберебез хокуклы».

Тәрбияче: Исәнмесез! Сезнең белән телестудиядә очрашуга бик шатмын. Әңгәмәләр вакытында актив катнашырсыз дип ышанып калам. Без сезнең белән хокуклар турында сөйләшүне дәвам итәрбез. Хокук ул – кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салу, үз-үзеңне тоту кагыйдәләре. Без иң элек гаиләдәге хокукларыбыз турында сөйләшербез.

2. Балаларга сораулар:

1 нче хокук. Һәр бала туганнан алып исемле булуга хокуклы.

- Сез моны ничек аңлыйсыз? (Мин тугач та әти белән әни миңа исем кушканнар. Минем исемем ...)

- Исемең нәрсәне аңлата? Беләсеңме?

- Синең фамилияң, әтиеңнең исеме ничек?

2 нче хокук. Һәр кеше әти-әниле булырга хокуклы.

- Бу хокукны ничек аңлыйсыз? (Һәр кеше үз әтисен, әнисен һәм аларның исем-фамилияләрен белергә тиеш)

- Әти-әниләрегез сезне ничек яраталар, саклыйлар, яклыйлар, кайгырталар? (Әти-әни безне киендерә, ашата, балалар бакчасына йөртә, кинотеатрларга алып бара һ.б.)

- Безгә яшәү өчен ни кирәк? (Йорт, өй һ.б.)

3 нче хокук. Һәр бала яшәү урынлы булуга хокуклы. (Яшәү урынын һәр кеше үзе сайларга хокуклы. Кеше тели икән – шәһәрдә, тели икән – авылда, тели икән – күпкатлы йортларда, тели икән – үзләренең шәхси йортларында яшәргә хокуклы)

- Ә сез кайда яшисез? (Урам, адрес, телефон номерын әйтәләр)

3. Рәсемнәр карау:

- Сез бу малайларны, кызларны кайда дип беләсез? (Мәктәптә, бакчада, балалар бакчасында, иҗат үзәгендә)

- Алар нишлиләр? (Җырлыйлар, бииләр, рәсем ясыйлар)

4. Тәрбияче хикәясе:

Һәр бала иҗадилыкка, ялга, спорт һәм сәнгать белән шөгыльләнергә, белем һәм тәрбия алырга хокуклы. Балалар бакчасында алар төрле шөгыльләрдә: рәсем ясау, кисеп ябыштыру, әвәләү, конструкцияләү, җыр җырлау, спорт белән шөгыльләнү, иң гади математик күзаллаулар формалаштыру, бала һәм әйләнә-тирә дөнья, сөйләм үстерү буенча белем алалар.

- Әйтегез әле, безнең балалар бакчасында бу хокук үтәләме соң? (Без уйныйбыз, вакытында йоклыйбыз, шөгыльләрдә белем алабыз, спорт белән шөгыльләнәбез, түгәрәкләргә йөрибез, биибез һәм җырлыйбыз)

5. Мультфильм карау: «Ике кыз» (Кайсы кызның нинди хокуклары бозылган?)

## Тема. «Тигез хокук белән яшик бу җирдә!»

**Бурычлар:**

1. Балаларга дус булырга кирәклеген төшендерү, аларда дуслык, әхлаклылык хисләре тәрбияләү.
2. Фикерләү, игътибарлылык сәләтен, сөйләм телен үстерү.
3. Кеше бер-берсе белән, нинди милләттән булуына карамастан, туганнарча аралашып яшәүгә хокуклы булу төшенчәсен бирү.

**Сүзлек:** хокук, җир шары, дөнья картасы, дуслык, тынычлык.

**Җиһазлар:** глобус, карта, указка, яшел яулык, аудиоязмада «Дуслык җыры» (Ф.Сафин сүзләре, А.Гарифуллина көе).

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку:

Тигез хокук, ирек белән
Ходай биргән безгә гомер.
Сәламәт бул, шатлык белән
Җирдә яшә син бик матур.

2. Глобус (Җир шарының макеты) һәм дөнья картасын карау.
3. Дидактик уен «Белсәң әйт!»

Төрле илләрдә төрле милләт халкы яши. Мәсәлән: Япониядә – японнар, Кытайда – кытайлылар, Россиядә – руслар, Татарстанда – татарлар, Башкортстанда – башкортлар һ.б.

4. Сәламләү: «Сездә ничек, бездә шулай!»

Һәр ил халкы бер-берсен төрлечә сәламли. Мәсәлән: японнар – баш ияләр (поклон), хөрмәтлерәк санаган кешегә башларын ныграк иеп яки тезләнеп, баш иеп сәламлиләр. Кытайлылар кулларын кулга куеп иеләләр. Яңа Зеландиядә борынны борынга тидерү сәламләү дип санала һ.б.

5. Исәнләшү (татарча – «исәнмесез!», башкортча – «һаумыһыгыз – дустар!», чувашча – «лайах!», удмуртча – «чырткемесь!», марича – «пеш сай юлташлак!», мордвача – «здорожи ямат!», русча – «здравствуйте!»).

6. Шигырь уку: Ә.Ерикәй. «Безгә тынычлык кирәк».

Шаулый урман, гөрли болын,
Яфрак яра тал-тирәк.
Яшел бакча төзү өчен,
Безгә тынычлык кирәк.

Тормышны, җирне яңарту –
Безнең беренче теләк,
Зур заводлар салу өчен,
Безгә тынычлык кирәк.

7. Балаларга сораулар:

- Бу шигырь нәрсә турында?
- Тынычлык ни өчен кирәк?

8. Тәрбияче хикәясе:

Бар кеше дә яхшы тормышка хокуклы. Җирдәге тынычлык кешеләрнең үзләреннән тора. Бар халыклар да аңлашып, иркле, тигез хокуклы булып, бер-берсе белән дус булып, аралашып яшәргә тиеш.

9. Җыр тыңлау: «Дуслык җыры» (Ф.Сафин сүзләре, А.Гарифуллина көе).

## Проект. Мин һәм минем сәламәтлегем
### Тема. Шифаханәгә (шәфкать туташы бүлмәсенә) экскурсия. «Шәфкать туташы»

**Бурычлар:**

1. Хезмәт кешесенә ихтирам, хөрмәт тәрбияләү.
2. Сөйләмдә ясалма сүзләр, грамматик формалар куллану

күнекмәләре бирү, баланың истә калдыру сәләтен, хәтерен үстерү.

3. Яңа сүзләрне бәйләнешле сөйләмдә кулланырга өйрәтү.

**Сүзлек:** шифаханә, табиб, шпатель, танометр, фонендоскоп, шприц, дәва, саулык, терапевт, хирург, педиатр.

**Җиһазлар:** «Табиб» рәсеме, «Беренче ярдәм» почмагындагы кирәк-яраклардан ясалган шифаханә, слайдлар яки рәсемнәр.

## Эшчәнлек барышы

1. Шифаханәгә яисә шәфкать туташы бүлмәсенә сәяхәт.

2. Шигырьдән өзек уку. Х.Халиков. «Китап докторы»

Әбиләр дә авырый,
Бәбиләр дә авырый,
Салкын тисә аз гына,
Дару кирәк барсына.

3. Фикер алышу.

- Безгә салкын тисә, ярдәм сорап кая, кем янына барабыз?
- Нәрсә соң ул шифаханә?
- Табиблар авыруны тикшергәндә нәрсәләр кулланалар?
- Шпатель белән нәрсә карыйлар, ул нәрсәгә охшаган?
- Фонендоскоп – ул нинди корал?
- Танометр нәрсәгә кирәк?
- Табибларга ярдәм итүчеләрне ничек атыйлар?
- Балалар бакчасында балаларның сәламәтлеген кем кайгырта?

4. «Кояш, һава һәм су – безнең якын дуслар» уены (туп белән).

- Кояшта булуның файдасы (зыяны) нидә?
- Саф һаваның файдасы турында сөйлә.
- Сусыз ни өчен яшәп булмый?

5. Мәкальләр:

а) Саулык-сәламәтлек – зур байлык.
б) Саф һава – тәнгә дәва.
в) Сакланган – саулыкка туйган.
г) Чирнең тиюе тиз, ә китүе озак.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

6. Дидактик уен «Кем нишли?»

- Терапевт ... (салкын тисә, баш авыртса, тән температурасы күтәрелсә дәвалый)

- Хирург ... (операция ясый)
- Теш табибы ... (теш ала, куя, ямый)
- Балалар табибы ... (балаларны дәвалый)

## Тема. Фикер алышу. «Сәламәтлек – зур байлык»

**Бурычлар:**

1. Чисталыкның сәламәтлек нигезе икәнлеген аңлату, чисталыкка омтылыш тәрбияләү.
2. Игътибарлылык һәм хәтер сәләтен үстерү.
3. Балаларны сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл кулланырга өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** теш щёткасы, сөлге, мунчала, шапшак.

**Җиһазлар:** слайдлар яки рәсемнәр.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Чисталык – сәламәтлек билгесе.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Табышмаклар әйтү:

а) Юеш чакта кулдан ычкынмакчы,
Шуып китә җаны бар кебек.
Мин ваннада шулай утыра торгач,
Күмеп китмәсенме ак күбек!
(Сабын)

б) Иртә торгач кулыңа ал,
Миннән башла эшеңне.
Паста белән мин чистартам
Ап-ак итеп тешеңне. (Теш щёткасы)

в) Тешләре күп – ашамый,
Минсез эшен башламый.
(Тарак)

г) Бит-кулыңны югач,
Сиңа мин кирәк.
Мин нәрсә булам,
Әйт син, тизрәк! (Сөлге)

д) Исе юк, төсе юк,
Аннан башка тормыш юк. (Су)

3. Фикер алышу:

- Шапшак сүзен сез ничек аңлыйсыз?
- Ни өчен шапшак булырга ярамый?
- Шапшак булмас өчен нәрсә эшләргә кирәк?
- Чиста булу өчен безгә нәрсәләр ярдәм итә?
- «Чисталык – сәламәтлекнең нигезе» төшенчәсен аңлатып бирегез.
- Чисталык турында нинди әкиятләр, хикәяләр беләсез?

4. Шигырь уку: М.Фәйзуллина. «Шапшак Гөлшат».

Гөлшатның алъяпкычында
Ике нәни кесә бар.
Чүп-чар салгач, ямьсез булып
Кабарышып торалар.

Анда ни юк: төймә, курчак,
Акбур, көзге кисәге.
Бу шапшаклыгын ташларга
Бармы икән исәбе?

5. Такмак:

Ике шапшак юлга чыккан,
Кулларында чумадан.
Иреннәрен буяганнар,
Ә битләрен юмаган.

6. Шигырь уку: Ф.Яруллин. «Сорау һәм җавап» (слайдлар яки рәсемнәр күрсәтеп шигырь аша табигатьнең кеше сәламәтлеге өчен әһәмиятен аңлату).

Кабатлыйм бер сорауны
Өнемдә һәм төшемдә:
«Кеше булып яшәргә
Нәрсә кирәк кешегә?»
Диңгез әйтә: – Тирәнлек.
Урман әйтә: – Бердәмлек.
Таулар әйтә: – Горурлык.
Юллар әйтә: – Турылык.
Җир эндәшә: – Юмартлык.
Чык суы әйтә: – Сафлык.

Яшен әйтә: – Кыюлык.
Ипи әйтә: – Олылык.
- Гүзәллек, – диләр гөлләр.
- Иркенлек, – диләр җилләр.
- Нык канат, – ди бөркетләр.
- Биеклек, – диләр күкләр.
Һәм шушылар өстенә
Кирәк тагын иң элек
Кешене кеше иткән
Бер нәрсә – сәламәтлек.

## Тема. Хикәянең эчтәлеген сөйләү: В.Монасыйпов. «Шифалы табиблар»

**Бурычлар:**

1. Табигатькә, урманда үсүче үсемлекләргә сакчыл караш, кайгыртучанлык тәрбияләү.

2. Бәйләнешле, эзлекле итеп әсәрнең эчтәлеген сөйләп бирү күнекмәләрен үстерү.

3. Туган ягыбызда үсүче дару үләннәренең файдалы үзенчәлекләре турында мәгълүмат бирүне дәвам итү.

**Сүзлек:** мәтрүшкә, бака яфрагы, песи үләне, үги ана яфрагы.

**Җиһазлар:** дару үләннәре турында слайдлар яки рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова «Балачак аланы», 326 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Слайдлар яки рәсемнәр карау, шигырьләрдән өзекләр уку. «Дару үләннәре».

- Без таныйбыз дус-ишне,
Кара нинди хуш исле,
Тагып йөрерлек түшкә!
Бу бит зәңгәр мәтрүшкә.
Яфрагын һәм чәчәкләрен
Кайнат та эч курыкмыйча.
- Монысы сары мәтрүшкә
Бик күп төрле авыруга
Шифасы бар аның да.
Тамакны да дәвалый ул,
Эчәк авыруларын да.
- Һәркемнең юлдашы –
Бака яфрагы дигән үлән.
Аяк кабардымы юлда –
Аны ябасың.

Җәрәхәтнең төзәлгәнен
Сизми дә каласың.
- Кинәт кенә көтмәгәндә
Авырып китсә йөрәк,
Авыртудан дәваларга
Песи үләне кирәк.
- Бу кычыткан – зәһәр инде,
Чага кулны тидерсәң.
Тик барыбер шифалы ул
Сызласа кул-буыннар.
Яфрагында, сабагында
Яшәү көче – суы бар.
Менә каен җиләге.
Бик тәмле ул, бал гына
Авызыңа ал гына –
күңелегез ачылыр,
Сусавыгыз басылыр.

2. Хикәя уку: В.Монасыйпов. «Шифалы табиблар».

3. Балаларга сораулар:

- Ромашка Гыйлаҗ бабайны нинди авырудан дәвалаган?
- Сәрби әбинең ашказанын нинди үлән төзәткән?
- Мөнәвәрә апаның нервыларын нинди үлән тынычландырган?
- Бака яфрагы Хәйрүш абыйга ничек булышкан?
- Искәндәр дигән малай янына кычыткан нигә барган? Ул авыргангмы?

4. Хикәянең эчтәлеген сөйләү (6 – 7 бала сөйли).

5. Җырлы-биюле уен «Түгәрәк алан» (балалар кулга-кул тотынышып түгәрәктә такмак әйтеп йөриләр).

Бу аланда чәчәкләр күп,
Кыймыйм ләкин өзәргә.
Әминә, Гөлфия,
Әйдә әле биергә.

Бу аланда чәчәкләр күп,
Без аларга тимибез.
Лилия, Гөлия,
Әйдә бергә биибез.

## Проект. Муса Җәлил. Ил сакчылары
### Тема. «Кемнәр алар ил сакчылары?»

**Бурычлар:**

1. Ватанны саклау теләге, әтиләре белән горурлану хисе тәрбияләү.

2. Балаларның уй-фикерләү сәләтен камилләштерү.

3. Балаларга Ватанны саклаучылар турында башлангыч төшенчә бирү.

**Сүзлек:** хәрби, очучы, снайпер, вертолёт йөртүче, парашютчы, танкист, су асты көймәсендә хезмәт итүче, чик сакчысы.

**Җиһазлар:** гаскәрләрнең символлары, киемнәре, хәрби техника, 8 – 10 метр бау, слайдлар, рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 117 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкальләр (эчтәлекләре буенча фикер алышу).

а) Ватанга хезмәт – үзеңә хезмәт.
б) Ил тыныч булса, без дә тыныч.
в) Илдә яшисең икән – илеңә хезмәт ит.
г) Илнең күрке – тынычлык.

2. Тел шомарткыч:

Син – чик сакчысы,
Чын чик сакчысы.
Юл салчы теге
Чиккә чаклы син.

3. Шигырь уку: Ж.Дәрзаман. «Солдат булдым».

4. Балаларга сораулар:

- Кем ул солдат?
- Кемнәр ул ил сакчылары?
- Ил сакчылары нинди була?
- Армия сафларында кем хезмәт итә?
- Әтиең кем булып хезмәт иткән?

5. «Бу хәрби кем?» уены (слайдлар яки рәсемнәр карау).

- Самолётта очучы хәрби – ...
- Вертолётта очучы хәрби – ...

- Төз атучы – ...
- Минаны зарарсызландыручы – ...
- Парашюттан сикерүче – ...
- Танкны йөртүче – ...
- Су асты көймәсендә хезмәт итүче – ...
- Чик буен саклаучы – ...

6. Дидактик уен «Бу символ кайсы хәрбигә туры килә?»

7. Хәрәкәтле уен «Кем тизрәк үзенең танкына барып җитә?»

Уен өчен ике кыска таяк кирәк. Таякка 8 – 10 метр озынлыктагы бау бәйләнә. Бауның уртасына уенчык танк эленә. Ике уенчы таякларны алып, бауны тарттырып кара-каршы басалар. Уйнаучылар тәрбияче сигналы буенча, кулларында тиз-тиз таякны әйләндереп, бауны чорныйлар һәм әкрен генә бер-берсенә каршы баралар. Бауны уртага кадәр беренче булып чорнаган бала җиңүче була.

## Тема. «Муса Җәлил – бөек шагыйребез»
## Сәхнәләштерү: М.Җәлил. «Карак песи»

**Бурычлар:**

1. Балаларда патриотик хисләр тәрбияләү.
2. Шигырьне сәхнәләштерү аша балаларда артистлык күнекмәләрен үстерү.
3. М.Җәлил турында балаларның белемнәрен баету, аның әсәрләре белән танышуны дәвам итү.

**Сүзлек:** дошман, чолан, йомыш, карак, үкенер, либретто.

**Җиһазлар:** М.Җәлил турында слайдлар, рәсемнәр, яулык, алъяпкыч, чуен, песи, тычкан битлекләре.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 68 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: Р. Миңнуллин.

Һәйкәл булып басып тора
Мәйданда Муса Җәлил.
Татарның батырлыгына
Менә кайда ул дәлил.

2. «Шигырьгә исем куй!» уены (балаларның тәкъдимнәрен тыңлау).

3. Тәрбияче хикәясе (слайдлар яки рәсемнәр ярдәмендә).

Муса Җәлил Оренбург өлкәсенең Мостафа авылында туа. Үсә төшкәч, Мусага мәдрәсәгә килергә, тыңлап утырырга рөхсәт бирелә. Алты яшьлек Муса белемне бик тиз үзләштерә. Әтисе Мусаны «Хөсәения» мәдрәсәсенә урнаштыра. Ул бик яшьтән шигърият белән кызыксына. Ун яшеннән үк шигырьләр яза башлый. Балалар журналларында җаваплы редактор булып эшли. Шигырьләр, либреттолар яза. 1939 елны Казанга кайта. Кызы Чулпанга багышлап матур шигырьләр яза. Сугыш башлангач, Муса Җәлил Волхов фронтына хәбәрче булып китә. Каты сугышлар вакытында яраланып, аңсыз, әсирлеккә эләгә. М.Җәлил гомеренең соңгы көненә кадәр дошман белән көрәшүен туктатмый, ялкынлы шигырьләр яза. Туган илнең җиңәчәгенә ышанып яши. М.Җәлилгә Советлар Союзы герое исеме һәм Ленин премиясе бирелә. Ул үзе дошман тозагында батырларча һәлак булса да, туган илгә аның бик күп шигырьләре кайта. Алар арасында балалар өчен язылганнары да бик күп.

4. Табышмак:

Нинди аучы коралсыз,<br>
Тычкан аулый төн буе.<br>
Аннан, мыегын селкетеп,<br>
Йоклап ята көн буе. (Песи)

5. Шигырь уку: М.Җәлил. «Карак песи».

6. Балаларга сораулар:

- Чоландагы ак майга нәрсәләр ияләшкән?
- Ак майны сакларга кемгә кушканнар?
- Нинди сүзләр белән үтенеп сораганнар?
- Каравылдан бушагач, песигә нәрсә вәгъдә иткәннәр?
- Ни өчен песине хыянәтче дип атаганнар?

7. «Мәкальне әйтеп бетер!» уены (эчтәлекләре буенча фикер алышу).

а) Иртәгә үкенерлек эшне ... (бүген эшләмә).

б) Терсәкне бик тешләр идең дә, ... (тешләп булмый).

в) Эш үткәч үкенүдә ... (файда юк).

8. Сәхнәләштерү: М.Җәлил. «Карак песи».

Тәрбияче балалар арасыннан хуҗаны, песине, тычканнарны санамыш белән сайлап ала һәм битлекләр бирә. Тәрбияче шигырь укый, балалар шушы шигырьнең сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар.

## Тема. Шигырь уку: Р.Корбан. «Җәлил турында җыр»

**Бурычлар:**

1. Геройга карата бәяләмә бирү, аның батырлыгына соклану хисләре тәрбияләү.

2. Тәрбияче биргән сорауларга төгәл җавап кайтара белү, логик фикер йөртә белү күнекмәләрен үстерү.

3. Фикер алышу барышында очраган яңа сүзләрнең мәгънәләрен аңлату, сүз запасын баету; матур әдәбият әсәрләре белән танышуны дәвам итү.

**Сүзлек:** дошман, тыл, көрәш, ант, сатмаган, әсир.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Сәгать» җыры (М.Җәлил сүзләре, Ф.Әхмәтов көе).

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 280 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль: «Халык әйтсә – хак әйтә»

Батыр үзе үлсә дә, исеме үлмәс.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Шигырь уку: Р.Корбан. «Җәлил турында җыр».

3. Балаларга сораулар.

- Муса Җәлил турында кайсы китаптан укып беләсез?
- Ул дошман тылында кемнәр белән көрәшкән?
- Туган иленә биргән антын ул ничек саклаган?
- М.Җәлилнең чын герой икәнлеген кайсы юллар күрсәтә?
- М.Җәлил нәрсәләр язган?
- Дошман килгәч, ул нишләгән?
- «М.Җәлилнең батырлыгы, исеме үлемсез» дигән җөмләне ничек аңлыйсыз?

4. Антоним сүзләр. Мәсәлән: батыр – куркак, җиңә – җиңелә,

кыю – кыюсыз, тырыш – ялкау һ.б.

5. Уен күнегүе. «Кем күбрәк әйтә?»

- Үлемсез – мәңгелек.
- Каһарман – бөек, батыр, данлыклы, герой.

6. «Күп мәгънәле сүзләр чылбыры» уены.

- Ак юл, ак бәхет.
- Баш тарту, баш вату.
- Озын сүз, озын тел.
- Түгәрәк сүз, түгәрәк йөз, түгәрәк сәдәф, түгәрәк сәгать.

7. Җыр тыңлау: «Сәгать» (М.Җәлил сүзләре, Ф.Әхмәтов көе).

## Проект. Халыкара телләр көне

### Тема. Фикер алышу: «Дуслык – бөек көч»

**Бурычлар:**

1. Төрле милләт халыкларына хөрмәт, дуслык хисләре тәрбияләү.
2. Балаларның акыл, хәтер, логик фикер йөртү сәләтен үстерү.
3. Идел буе халыклары турында балаларның белемнәрен баету.

**Сүзлек:** дуслык, милләт, чуваш, мари, удмурд, башкорт, алъяпкыч, калфак, камзул, күлмәк, тухчя.

**Җиһазлар:** мари, чуваш халык костюмнары төшерелгән рәсемнәр яки слайдлар, аудиоязмада «Дуслык җыры» (Ф.Сафин сүзләре, А.Гарифуллина көе).

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 110 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Җыр тыңлау: «Дуслык җыры» (Ф.Сафин сүзләре, А.Гарифуллина көе).
2. Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Безнең бакчада».
3. Үстерешле диалог:

- Татарстанда нинди милләт халыклары яши?
- Безнең бакчага нинди милләт балалары йөри?
- Алар бер-берсе белән ничек яшиләр, аралашалар?
- Татарстанның иң зур байлыгы, горурлыгы нәрсә?
- «Исәнмесез» сүзен нинди телләрдә әйтә беләсез? Әйтеп

күрсәтегез әле.

- «Дуслык» бәйрәме дип нинди бәйрәм атала?

4. Дидактик уен «Белсәң әйт!»

Төрле илләрдә төрле милләт халыклары яши: Татарстанда – татарлар, Россиядә – руслар, Башкортстанда – башкортлар, Удмуртиядә – удмуртлар һ.б.

5. Слайдлар яки рәсемнәр карау (төрле милләт халыкларының милли киемнәрен карап чагыштыру).

1) Татар халык киемнәре турында балалар сөйли.

2) Милли чуваш киемен карау. Чувашларның яраткан төсләре – сары һәм кызыл. Сары төс аларда азатлыкка омтылуны аңлата. Кызыл төс – ул байлык, булганлык билгесе. Чуваш халкының кием гадилеге белән аерылып тора. Чуваш кызларының баш кием тәңкә һәм төймәләр белән бизәлгән. Ул тухчя дип атала.

3) Мари киемен карау. Мариларның милли киемнәре бик гади. Ир-егетләр күлмәге чигелгән һәм билбау белән бәйләп куела, ә чалбар балаклары итек эченә тыгылып киелә, башларында – тиредән тегелгән башлык. Ә хатын-кызлар озын чигелгән күлмәк, алъяпкыч, башларына калфак кияләр.

6. Чуваш халкының хәрәкәтле уены «Тили-рам, бездән сезгә кем кирәк?»

Уенда ике команда катнаша. Ике команда бер-берсенә каракаршы басып тора. Беренче команда бергәләп әйтә: «Тили-рам, тили-рам?» (Сезгә кем, сезгә кем?) Ә икенче команда кулга-кул тотынып, беренче командадан бер уенчының исемен әйтә. Исем әйтелгән бала икенче якка йөгереп чыга. Аннан рольләрне алыштыралар. Ахырдан командалар, бер-берсе белән канат ярдәмендә тартышалар.

7. Мәкаль-уен «Башын әйтәм, ахырын әйт!»

а) Кош канаты белән, ... (кеше дуслары белән көчле).

б) Дустың булмаса – эзлә, тапсаң – ... (югалтма).

в) Ялгыз агачны җил ... (сындыра).

г) Күмәк күтәрсә – ... (күлне күчерер).

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

## Тема. Әңгәмә. «Россия – безнең илебез»

**Бурычлар:**

1. Туган илне ярату, аның белән кызыксыну, туган илгә тугрылык сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның хәтерен, логик фикерләү сәләтен, кызыксынучанлыкларын, диалогик сөйләмнәрен үстерү.

3. Балаларның Россия башкаласы Мәскәү, аның символикасы турындагы белемнәрен системалаштыру.

**Сүзлек:** әләм, бөркет, калкан.

**Җиһазлар:** рәсемнәр, символика.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Балыкка – су, кояшка – һава, кешегә туган ил кирәк.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Үстерешле диалог.

- Без нинди республикада яшибез?
- Татарстан Республикасы нинди җирлектә урнашкан? (Татарстан – минем республикам, Россиянең матур җирендә)
- Россиянең башкаласы нинди шәһәр?
- Мәскәү шәһәрендә нинди истәлекле урыннар бар?
- Россиядә тагын нинди шәһәрләр бар?
- Илебезнең президенты кем?
- Россия гимнын кайсы очракларда ишетеп була?
- Гимннарны нинди рәвештә тыңлыйбыз? Ни өчен?

3. Россия символикасын карау (интерактив такта яисә рәсемнәр ярдәмендә).

- Тугра формасы буенча нәрсәне хәтерләтә? (Калкан)
- Анда нинди кош сурәтләнгән?
- Ни өчен ул ике башлы?
- Әләм һәм туграны кайда очратырга мөмкин?
- Тугpаның уртасында нәрсә сурәтләнгән? Ни өчен?
- Россиянең әләмендә нинди төсләр бар?
- Ул төсләр нәрсәне аңлата?

4. Дидактик уен «Рус халык әкиятен беләсеңме?» (рәсемнәргә

карап искә төшерү).

5. Үстерешле уен «Ярминкә» (рәсемнәр, муляжлар белән).

Россиянең милли ризыклары башка милли ризыклардан аерып күрсәтелә.

6. Рус халык уены «Почта».

- Динь-динь-динь.
- Кем анда?
- Почта.
- Кайдан?
- Шәһәрдән.
- Шәһәрдә нәрсә эшлиләр?

Балалар арасыннан алып баручы сайлана, ә калган балаларның кулында – фантлар. Алып баручы итеп сайланган бала сорауларга җавап бирә: бииләр, җырлыйлар, шигырь сөйлиләр һ.б. Алып баручы нәрсә әйтсә, балалар шуны эшли. Алып баручы, дөрес хәрәкәт ясамаган балалардан биш фант сайлап ала. Балалар аны үзләренең тәмле сүзләре белән, кызыклы вакыйгалар сөйләп һ.б. яңадан сатып алалар. Соңыннан икенче алып баручы сайлана.

## Тема. Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Сөйләшсәләр безнеңчә ...»

**Бурычлар:**

1. Балаларда туган телебезгә, туган илебезгә, халкыбызның рухи хәзинәләренә мәхәббәт тәрбияләү.

2. Матур әдәбият әсәрләре кулланып, сүз байлыкларын арттыру, фикер йөртү сәләтен, игътибарлылык һәм хәтердә калу күнекмәләрен үстерү.

3. Балаларның җөмләләрне дөрес төзеп, үзләренең уй-фикерләрен тиешле эзлеклелектә һәм бәйләнешле итеп сөйли белүләренә ирешү, туган телнең матурлыгын һәм аһәңен тоя белергә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** дәрәҗәле, җитлеккән, камилләшкән, затлы.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Туган тел» җыры (А.Хәмзин сүзләре, Ф.Мортазин көе).

**Эшчәнлек барышы**

1. Җыр тыңлау: «Туган тел» (А.Хәмзин сүзләре, Ф.Мортазин көе).

2. Тәрбияче хикәясе:

Татар теле ... Тугач та иң газиз кешеңнән ишетә башлаган, күп гасырлы тарихы булган, җиде миллион халык сөйләшкән дөньяда иң дәрәҗәле ундүрт тел исәбенә кергән, чит илләрдә дә өйрәнелә торган, бүгенге көндә җитлеккән, камилләшкән тел ул. Туган тел төшенчәсе Ватан, туган җир, әти-әни сүзләре белән бер дәрәҗәдә торучы бөек, изге һәм кадерле сүз ...

3. Шигырь уку: Х.Халиков. «Сөйләшсәләр безнеңчә ...».

Җирдә нинди илләр юк,
Нинди генә телләр юк ...
Һәркем сөйли үзенчә,
Сөйләшсәләр безнеңчә
Эреп китәм, май кебек,

Йөзем тулган ай кебек
Яктырганнан-яктыра.
Күңелдә таң аттыра
Балдан да татлы телем,
Нәфис һәм затлы телем.

4. Балаларга сораулар.

- Шагыйрь илләрнең күплеген, телләрнең төрлелеген нинди юллар белән аңлата?

- Татар телендә сөйләшүне ишеткәч, шагыйрьнең кәефе ничек үзгәрә?

- Шагыйрь татар телен ничек тасвирлый?

5. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала сөйли).

6. Җырлы уен «Агыйдел».

Балалар бер-бер артлы басалар. Парсыз калган бала алга чыга.

Агыйдел суларында
Ак чиләгем күмелде.
Әйдә, дустым, безнең якка,
Безнең яклар күңелле.

Кушымтаны җырлаганда балалар, кулларын өскә күтәреп, «капка» ясыйлар.

Зәңгәр чәчәк җыя-җыя,
Зәңгәрләттем кулымны.
Бергә-бергә уйныйк әле,
Бир, дускаем, кулыңны.

Парсыз калган бала капкалардан чыга һәм үзенә ошаган баланы сайлый. Уен дәвам итә.

## Проект. Бүлмә гөлләре
### Тема. Тәҗрибә үткәрү. «Ни өчен орлыкларны, үсемлекләрне балчыкка утырталар?»

**Бурычлар:**

1. Балаларда барлык тереклек ияләренә карата шәфкатьлелек, табигатькә сак караш тәрбияләү.

2. Балаларның тикшерү, тәҗрибә үткәрү эшчәнлеге нигезендә экологик фикер йөртү, иҗади хыял сәләтләрен үстерү.

3. Балаларның туфрак турындагы күзаллауларын киңәйтү, бүлмә гөлләре, экологик бәйләнешләр белән таныштыруны дәвам итү.

**Сүзлек:** туфрак, уңдырышлы, балчык, пычкы чүбе, суалчан, бөҗәк.

**Җиһазлар:** тәҗрибә өчен материал, алдан утыртылган ике гөл, рәсем-схемалар, аудиоязмады «Гөлкәйләрем» җыры (М.Разов сүзләре, В.Агапов көе).

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак:

Патша түгелмен – таҗым бар,

Кешеләргә бирер назым бар. (Чәчәк)

2. Бүлмә гөлләрен күзәтү (бер гөл уңдырышлы туфракка, икенче гөл пычкы чүбенә утыртылган).

- Уңдырышлы туфракка утыртылган гөл ничек үскән? Ни өчен?

- Пычкы чүбенә утыртылган гөл турында нәрсә әйтергә була?

- Бу ике савыттагы гөлләргә карап нинди нәтиҗә ясарга була?

3. Тәҗрибә үткәрү.

- Нәрсә ул туфрак (балчык)? (Ул җирнең уңдырышлы катламы)

- Ул ни өчен кирәк?

- Туфракны ни өчен уңдырышлы дибез? (Үсемлекләр үсү өчен кирәкле матдәләр бар)

- Нинди матдәләр икән ул?

1 нче тәҗрибә: Коры туфрак кисәген суга салу, күзәтү. Бу туфрак кисәгеннән һава куыклары чыга. Димәк, туфракта һава бар.

2 нче тәҗрибә. Туфракны бераз утта җылытабыз һәм өстенә

салкын пыяла куябыз. Пыяла парлана, димәк анда су бар. Туфракта әле төрле бөҗәкләр, суалчаннар яши. Алар туфракны йомшарта.

3 нче тәҗрибә. Балчыкны утта кыздырабыз. Ул кызгач, ис чыгачак. Чөнки анда таркала башлаган үләннәр, яфраклар, агач кисәкләре бар. Алар үсемлекләр өчен туклыклы матдә булып тора.

4. Үстерешле уен. «Кагыйдәне әйт!» (рәсем һәм схемалар ярдәмендә).

- Җирне пычратырга ярамый!
- Үсемлекләр үссен өчен җирне туендырып торырга кирәк.
- Үсемлекләргә һәрвакыт су сибәргә кирәк.
- Үсемлекләрнең төпләрен йомшартып торырга кирәк.
- Үсемлекләр үсәр өчен яктылык кирәк.

5. Җыр тыңлау: «Гөлкәйләрем» (М.Разов сүзләре, В.Агапов көе).

## Тема. Хикәя төзү: «Кактус белән фикус гөлен чагыштыру»

**Бурычлар:**

1. Бер-берсен тыңлый белү, үз фикерләрен башкаларга дөрес итеп җиткерә белү сыйфатларын тәрбияләү.
2. Балаларның игътибарлылыгын, күзәтүчәнлекләрен үстерү.
3. Гөлләр турында эзлекле итеп чагыштыру хикәясе төзи белү күнекмәләрен камилләштерү, табигать объектлары, табигатьтәге бәйләнешләрне күрә белү мөмкинлекләрен арттыру.

**Сүзлек:** кактус, фикус, чүл.

**Җиһазлар:** кактус һәм фикус гөлләре.

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку: Н.Гайсин. «Бүлмә гөлләре».

| | |
|---|---|
| Әни утыртты гөлләр, | Хуш исле нәфис гөлләр |
| Алар үсә зур булып, | Үсәләр биек булып, |
| Утыралар ямь биреп, | Утырырлар ямь биреп, |
| Бөтен өебез тулып. | Бөтен өебез тулып. |

2. Үстерешле диалог:

- Бүлмә гөлләре ни өчен кирәк?
- Бүлмә гөлләре урман, кыр һәм бакча чәчәкләреннән нәрсәләре белән аерылалар?

- Ни өчен аларны «тере» диләр?

- Нинди бүлмә гөлләрен беләсез?

3. Кактус белән фикус гөлен чагыштыру.

- Кактус нинди гөл?

- Фикус турында нәрсә әйтергә була?

- Ни өчен кактусның яфраклары урынында энәләр? Аның сабагы бармы?

- Фикусның яфраклары нинди?

- Сабагы турында нәрсә әйтер идең?

- Аларны ничек тәрбияләргә кирәк?

4. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала хикәя төзеп сөйли).

Үрнәк: Бу кактус, ә бу фикус гөле. Кактус тәбәнәк, шар формасында, ә фикус озын. Кактусның яфраклары энәле, сабагы урынында түгәрәк шар. Ул анда дым саклый, чөнки ул чүлдә, су аз урында үсә. Ә фикусның яфраклары зур, калын, сабаклары озын булып үскән. Ул дымлы урыннарны ярата. Кактусны комлы туфракка утыртырга, суны аз сибәргә кирәк, ә фикус үссен өчен су күп кирәк.

5. Сүзле-җырлы уен «Ал кирәк, гөл кирәк».

Балаларның һәрберсенә гөл исеме бирелә: яран, роза, тамчы гөл, фикус, кына һ.б. Балалар икегә бүленәләр, кулга-кул тотынышып, кара-каршы басалар.

| 1 нче төркем: | 2 нче төркем: |
|---|---|
| Ал кирәк, гөл кирәк, | Сезгә нинди гөл кирәк? |
| Безгә нәфис гөл кирәк. | |

Беренче төркем балалары тиз генә җыйналып, кайсы гөлне чакырасын сөйләшәләр. Аннан тезелеп җырлыйлар:

Ал кирәк, гөл кирәк,<br>
Безгә матур чәчкәле<br>
Тамчы гөле бик кирәк.

Тамчы гөл, каршы якка йөгереп барып, ике бала арасыннан үтәргә, аларның кулларын «өзәргә» тырыша. «Өзеп» чыга алса, ике баланың берсен җитәкләп үзенең ягына кайта. «Өзә» алмаса, үзе шул якта кала.

6. Тизәйткеч ятлау: «Абага гөле». [г] авазы.

Абагага бага, бага,<br>
Башым бәрдем баганага.

### Тема. Шигырь уку: Ә.Габиди. «Минем гөлем»

**Бурычлар:**

1. Балаларда үсемлекләргә карата сак караш, шәфкатьлелек, миһербанлылык тәрбияләү, матур әдәбият аша эстетик тойгылар уяту.

2. Матур әдәбият әсәрләренең эчтәлеген аңлап, сорауларга дөрес җөмләләр белән җавап бирә белү сәләтен үстерү.

3. Бүлмә гөлләрен танып әйтә белү күнекмәләрен камилләштерү; гөлләрне үстерү, карау тәртибе турында белемнәрен ныгыту, кушма сүзләр төзүдә булышлык итү.

**Сүзлек:** Гөлназия, Гөлчирә, Гөлсирин, Гөләндәм, Гөлдәния.

**Җиһазлар:** бүлмә гөлләре төшкән рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** Р.Ш.Халикова. «Раушан көзге», 148 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Әйтем.

Гөлләр – тормыш яме.

2. «Ми чарлау» уены:

- Нинди бүлмә гөлләрен беләсез?
- Гөл нинди өлешләрдән тора?
- Гөл үссен өчен нинди шартлар кирәк?
- Гөлләрне нинди сүзләр белән атарга була?

3. Шигырь уку: Ә.Габиди. «Минем гөлем».

4. Балаларга сораулар:

- Шигырьдә сүз елның кайсы фасылы турында бара?
- Бүлмәбездә нинди чәчәкләр үсә?
- Бүлмә гөлләре ни өчен кирәк?

5. «Исемең матур – кемнәр кушкан?» уены (туп белән).

Балалар бер-берсенә тупны бирәләр һәм «гөл» сүзе кергән исемнәрне әйтә баралар. Мәсәлән: Гөлнур, Гөлнара, Гөлсара, Гөлназ, Гөлназия, Гөлсем, Гөлсинә, Гөлшат, Гөлсөя, Гөлчәчәк, Гөлбану, Гөлчирә, Гөлсирин, Гөләндәм, Айгөл, Гөлсәрия, Гөлдәния, Гөлфия, Гөлгенә һ.б.

6. Сүзле-җырлы уен «Түгәрәк алан».

Балалар кулга-кул тотынышып, түгәрәк буйлап йөриләр. Исеме әйтелгән балалар уртага чыгып бииләр. Уен дәвам итә.

Бу аланда чәчәкләр күп,
Кыймыйм ләкин өзәргә
Гөлгенә, Гөлгенә,
Әйдә әле биергә.

Бу аланда чәчәкләр күп,
Без аларга тимибез.
Айгөл, Айгөл,
Әйдә бергә биибез.

7. Дидактик уен «Бу нинди гөл?»
Балалар рәсемнәргә карап, гөлләрнең исемнәрен атыйлар.

## Проект. Ямьле яз

### Тема. Паркка экскурсия. «Туган якка яз килде»

**Бурычлар:**

1. Табигатькә карата сак караш тәрбияләү.
2. Ситуатив сораулар ярдәмендә балаларның логик фикерләү сәләтен үстерү.
3. Табигатьтәге бәйләнешләрне аңлата белү күнекмәләрен камилләштерү.

**Сүзлек:** нур бөркелде, бөре, күлләвек, гөрләвек, йомычка, җанланган.

**Җиһазлар:** кош рәсемнәре.

### Эшчәнлек барышы

1. «Табышмак әйтәм – җавап тап!»
Яңгырлы да карлы да,
Ә каеннары сулы.
Бөреләре туп-тулы –
Елның кай фасылы? (Яз)
2. Шигырь уку:
Яз килде, кояш көлде,
Дөньяга нур бөркелде.
Агачлар уяндылар,
Барсы да кузгалдылар.
3. Экскурсиядә фикер алышу:
- Табигатьтә нинди ел фасылы?
- Бүген нинди һава торышы?
- Күк йөзе нинди?
- Күктә нинди болытлар йөзә?

- Җыелып торган кар сулары ничек дип атала? (Күлләвек)
- Аккан суларны ничек дип атыйлар? (Гөрләвек)
- Агачларда нинди үзгәрешләр күрәсез?
- Нинди күчмә кошлар беләсез?

4. «Тавышыннан таны!» уены [р], [г], [т], [ч] авазлары.

а) Мин әйтәмен: кар-кар,
Монда кемдер бар, бар.
Танып кара: бар, бар. (Кара карга)

б) Гөлдер-гөлдер, гөлдергү,
Күк күгелҗем, миндер бу. (Күгәрчен)

в) Тук-тук, тук итәм,
Агачтагы кортларны
Юк итәм. (Тукран)

г) Чык-чырык, чык-чырык,
Ник көләсең шырык-шырык? (Чыпчык)

5. Тизәйткеч «Йомычкада кырмыска».

Суда йөзә йомычка,
Йомычкада кырмыска.
Бушатмас бушны-бушка,
Баруыдыр йомышка.

6. Дидактик уен «Агач исемен әйт!» (кәүсә, ботак, бөреләре буенча агачны тану һәм исемен әйтү).

7. Җырлы-хәрәкәтле уен «Там, там, тамчы там».

Уенчылар пар-пар булып, кулга-кул тотынып, бер-бер артлы басалар. Алар күмәкләшеп, хәрәкәтләр ясап, җырлыйлар.

Там, там, тамчы, там,
Тамганыңны яратам.
Тамган тамчыларга карап,
Мин җырларга яратам.

Тамчы тама, тамчы тама,
Тамчы тама түгелме?
Тамчы тамса, матур язлар
Килеп җитә түгелме?

## Тема. Эчтәлекле рәсемнәр сериясе буенча хикәя төзү. «Яз. Сыерчыклар»

**Бурычлар:**

1. Балаларда табигатькә, кошларга карата сак караш, миһербанлылык, кайгыртучанлык тәрбияләү.

2. Балаларның монологик сөйләмен, фикерләрне мөстәкыйль әйтә белү сәләтен үстерү.

3. Балаларның сюжетлы рәсемнәр буенча эзлекле хикәя төзи белүләрен камилләштерү.

**Сүзлек:** бөреләр, фасыл, сыерчык оясы.

**Җиһазлар:** «Яз. Сыерчыклар» рәсеме.

## Эшчәнлек барышы

1. Балалар белән табышмакны искә төшереп кабатлау.

Яңгырлы да, карлы да,
Ә каеннары сулы.
Бөреләр туп-тулы –
Елның кай фасылы? (Яз)

2. Уен «Тәртип буенча тез!»

Балалар «Яз. Сыерчыклар» эчтәлекле рәсемнәр сериясен, эчтәлегенә карап, тәртип буенча тезеп чыгалар.

3. Эчтәлекле рәсемнәр сериясен карау: «Яз. Сыерчыклар».

4. Балаларга сораулар:

- Рәсемдә нинди ел фасылы күрсәтелгән?
- Ни өчен шулай дип уйлыйсыз?
- 1 нче рәсемдә балалар кая килделәр?
- Алар анда нәрсә күрделәр?
- Сыерчык оясы нинди?
- Балалар, моны күргәч, нишләделәр?
- Алдагы рәсемдә алар нишлиләр?
- Нигә алар читкәрәк китеп басканнар?
- Хикәягә нинди исем бирер идегез?

5. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала сөйли).

Мәсәлән: Балалар язгы матур бер көнне паркка килделәр. Алар агачта эленеп торган иске, ватык сыерчык оясын күреп алдылар. Балалар бу ояны мәктәпкә алып кайтып төзәттеләр. Аны алып килеп каенга элеп куйдылар. Сыерчыклар озак көттермәде, алар ояга килеп кундылар да матур итеп җырлый башладылар. Балалар читкәрәк басып аларны күзәтәләр.

6. Эндәш әйтү «Сыерчык».

Сыерчык, сыерчык,

Күк күлмәгең киеп чык;
Үзеңнеке булмаса,
Атаңныкын киеп чык!
Атаңныкы булмаса,
Анаңныкын киеп чык;
Анаңныкы булмаса,
Бабаңныкын киеп чык.

7. Уен «Сүзне дәвам ит!»

Яз – ул кояш, җылы, яктылык, гөрләвекләр, кошлар җыры, чәчәкләр ...

Язгы кар – кара, пычрак, тыгыз, салкын, юеш ...

Күк йөзе – зәңгәр, чиста, матур, якты, ачык ...

Кояш – җылы, якты, назлы, нурлы, иркә, сары һ.б.

### Тема. Шигырь уку: Н.Мадьяров. «Көләч яз»

**Бурычлар:**

1. Язгы табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белү һәм яз килүгә сөенү хисләре тәрбияләү.
2. Балаларда яз турында белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә иҗади куллана белү күнекмәләрен үстерү.
3. Шигырьдә балаларга таныш булмаган сүзләрнең, чагыштыру алымнарының мәгънәләрен аңлату, сүз байлыгын арттыру һәм сөйләмдә кулланышка кертү.

**Сүзлек:** җиһан, мөлдери, туң, көлтә.

**Матур әдәбият:** З.М.Зарипова. «Бал бабай», 111 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Боз һәм кар эреде,
Сулар йөгерде.
Еглап елгалар,
Яшьләр түгелде.

Көннәр озая,
Төннәр кыскара,
Бу кайсы вакыт?
Я, әйтеп кара? (Яз)

2. Шигырь уку: Н.Мәдьяров. «Көләч яз».

3. Балаларга сораулар:

- Ни өчен җиһанга нур тулган?

- Ни өчен сулар агарга юл эзли?
- Агачның бөреләре нишли?
- Үләннәр, чирәмнәр ни өчен туң ярып калкалар?
- Яз килгәч, табигать ничек үзгәрә?

4. Дидактик уен «Бәйләнешле сүзләр әйт!»

Мәсәлән: кар – эри, кими, җиргә сеңә, юкка чыга.

Гөрләвекләр – ...

Кояш – ...

Агачлар – ...

Кошлар – ...

5. Мәкальләр:

а) Яз яме чәчкә белән, көз яме көлтә белән.

б) Язның байлыгы – кояш, көзнең байлыгы – уңыш.

в) Язгы көн ел туйдыра.

Эчтәлекләре буенча фикер алышу.

6. Сүзле уен «Яз килә».

Тәрбияче: Я, балалар, карагыз,
Тышта, әнә, килә яз.

Балалар: Әйе, әйе, күрәбез,
Яз килгәнен беләбез.

Тәрбияче: Миңа якын килегез,
Яз турында сөйләгез.

Балалар: Канат кагып, ерактан
Кошлар кайтты көньяктан.
Тамчы тама тып та тып,
Булмый аны туктатып.
Зәңгәр күктә кояш балкый,
«Тышка чык» дип, безне алдый.
Сикергеч туп кулга алыйк,
Сикереп уйнап карыйк.
Яз бездә озак тормый,
Җәй килер җырлый-җырлый.

### Тема. Күзәтү. «Ак болытлар ага зәңгәр күктә»

**Бурычлар:**

1. Табигатькә аңлы караш, экологик культура тәрбияләү.
2. Балаларның күзаллау, күзәтүчәнлек, фикер йөртү сәләтен үстерү.
3. Фикер алышу вакытында үз фикерләрен ачык, төгәл, аңлаешлы итеп әйтә белергә, катлаулы булмаган нәтиҗәләр ясарга өйрәтү.

**Сүзлек:** каракучкыл, каурыйсыман, өем болыт, катламлы бо-

лыт, болытлылык.

**Җиһазлар:** төрле болыт рәсемнәре.

Эшчәнлек табигатьтә уза.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак.

Йөзәм, ләкин суда түгел,
Йөзәм сезнең өстә мин.
Шат чагында ап-ак булам,
Кайчак кара төстә мин. (Болыт)

2. Мәгълүмати хикәя. «Болыт ничек барлыкка килә?»

Үрнәк: Кояш әледән-әле кыздыра һәм җир өстендәге суны парга әйләндерә. Шунлыктан күзгә күренми торган су парлары һавада һәрвакыт булып тора. Һава суынгач, пардан вак кына су тамчылары хасил була һәм алар томанга әйләнә. Без аны күрә башлыйбыз. Болытлар да – шул ук томан, ләкин алар җир өстеннән бик югары булалар. Чынлап та, күк йөзенә карасаң, болытларның бик биектә икәнлегенә ышанасың. Аларны якыннан да күрергә мөмкин. Әйтик, биек тауларга менгән альпинистлар, самолётта очкан кешеләр болытлар белән күзгә-күз очрашалар. Самолёт оча, аның астында ак болытлар диңгезе күзгә чалына. Менә самолёт үзе дә болыт эченә килеп керә һәм куе томан эчендә кала. Болытлар һәрвакыт хәрәкәт итеп тора. Аларны җил куып йөртә.

3. Фикер алышу:

- Болытлар нинди була?

- Күк йөзенең иң биек өлешендә булган җиңел болытны ничек атыйлар? (Каурыйсыман болыт)

- Түбәндәрәк йөзүче, тышкы күренешләре, формалары белән зур мамык төргәген хәтерләтүче болытлар ничек аталалар? (Өем болытлар)

- Зур-зур катламнардан торган болытларны ничек атыйлар? (Катламлы, катлы-катлы)

- Каракучкыл төстәге болытлар нәрсә алып килә? (Яңгыр)

- Нәрсә ул болытлылык? (Күк йөзенең болыт белән каплануы)

- Болытлы көнне ни өчен һава бераз салкынрак була? (Болытлар кояш нурларын йоталар, ягъни үзләренә сеңдерәләр)

4. Шигырь уку: Л.Шәех. «Болыт».

| | |
|---|---|
| Килеп чыкты | Ихлас инде, |
| Нәни болыт. | Сабый инде. |
| Нәни болыт, | Көлеп тора |
| Бәби болыт. | Ап-ак булып. |
| Үзе шундый | Чиста болыт, |
| Гади инде, | Ап-ак болыт ... |

5. Үстерешле уен «Файдасы, зыяны».

Мәсәлән: болытларның файдасы – кояшлы җәй көннәрендә күк йөзендә йөзеп йөриләр һәм күләгә алып киләләр, ә зыяны – гел болытлы булып торса, үсемлекләр үсми, кояш чыкмый һ.б.

6. «Сүз эчендә энҗе бар».

Болытлау – болыт белән каплану, болыт җыелу.

Болытлы (көн) һ.б.

7. Әңгәмә.

- Күк йөзендә йөзеп йөргән болытларны нәрсәгә охшатасың? Мәсәлән: кайберләре өч башлы аждаһага, каргага, куянга, Зөһрә йолдызга һ.б. охшаган.

8. Хәрәкәтле уен «Болытлар куера».

Балалар су тамчылары була, алар бер-берсенә кушылалар, балалар төркеме зурая. Бер зур төркемгә әйләнгәч, яңгыр яки кар бөртекләре булып, бөтерелеп-бөтерелеп җиргә сибелеп явалар.

## Проект. Исәнмесез, кошкайлар!

### Тема. «Күчмә кошлар безгә яз алып килде»

**Бурычлар:**

1. Балаларда кошларга карата сакчыл караш, мәрхәмәтлелек сыйфатлары тәрбияләү.
2. Балаларның күзәтүчәнлекләрен, кызыксынучанлыкларын, чагыштыра белү күнекмәләрен үстерү.
3. Балаларның күчмә кошлар, аларның үзенчәлекле яклары турындагы белемнәрен камилләштерү.

**Сүзлек:** тургай, сандугач, карлыгач.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Кошлар тавышы», күчмә кошлар рәсемнәре, кроссворд.

## Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку:

Ачылды ак калын юрган,
Исте апрель җилләре.
Кошлар кайта: сагындырган
Туган үскән җирләре.
Көннәрен юлда үткәреп,
Куанышып очалар.
Канатларына күтәреп,
Яз китерә ич алар.

2. Аудиоязма тыңлау: «Кошлар тавышы».

3. Кроссворд.

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | **Т** | у | р | г | а | й | |
| А | к | к | **о** | ш | | | | | |
| С | ы | е | **р** | ч | ы | к | | | |
| | С | а | **н** | д | у | г | а | ч | |
| | | к | **а** | р | л | ы | г | а | ч |

а) Бер кошым бар: тынмый,
Агачта оя кормый.
Өе – җирдә.
Җыры күктә. (Тургай)
б) Күктә оча, суда йөзә,
Муены озын, горур кош.
Кара да була ул, ак та
Исеме аның ... (аккош)
в) Агач башында йорты,
Эчендә яши – җырчы. (Сыерчык)
г) Ары да чут-чут,
Бире дә чут-чут.
Төскә матур булмаса да,
Сайравына тиңнәр юк. (Сандугач)
д) Кулы юк – балчык ташый.
Балтасы юк – оя ясый. (Карлыгач)

4. Дидактик уен. «Сорау – җавап».

- Көз көне җылы якларга китеп, кыш көне кайтучы кошлар ничек дип атала?

- Иң беренче нинди кошлар кайта?

- Нинди кош баласын башка кошлар тәрбияли?

- Сыерчык оясы булмаса, сыерчыклар кая оялый?

- Ни өчен каргалар, сыерчыклар җир сукалаучы трактор артыннан бара?

5. Әйтемнәр.

а) Кош оясын туздырма, башың авыртыр.

б) Кошларга таш атма, күзең сукыраер.

в) Сыерчыкларга оя ясa – эшең уңар.

г) Кош йомыркаларын ватма, күз яшеңне түгәрсең.

6. Җырлы-биюле уен «Ике аккош».

Балалар түгәрәккә басалар, ике бала уртада кала. Алар аккошлар була. Балалар җырлап әйләнәләр.

Очалар ике аккош,
Алар кечкенәләр.
Кара кошкайларым,
Кара күзкәйләрем,
Алар бара торгач,
Утырып ял итәләр.
Кара кошкайларым,
Кара күзкәйләрем,

Алар бара торгач,
Салют бирешәләр.
Кара кошкайларым,
Кара күзкәйләрем,
Алар бара торгач,
Иптәш сайлашалар,
Кара кошкайларым,
Кара күзкәйләрем.

Аккошлар түгәрәктән иптәшләрен сайлап алып, уртага чакыралар, урыннарын алышалар. Уен шулай дәвам итә.

### Тема. Шигырь ятлау: Г.Юнусова. «Кара»

**Бурычлар:**

1. Балаларда матур әдәбият аша кошларга карата мәрхәмәтлелек, сакчыл караш тәрбияләү.

2. Шигырьне ятлау теләге булдыру, хәтер сәләтен үстерү.

3. Шигырьне сәнгатьле укуларына ирешү, шигырьдә еш ишетелгән авазны танып белергә өйрәтү.

**Сүзлек:** сутлы кара туфрак, чем кара.

**Җиһазлар:** кош рәсемнәре.
**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 497 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Әйтенү:
Карга кара, кара карга!
Каррык-каррык каркылдама.
2. Шигырь уку: Г.Юнусова. «Кара».
3. Балаларга сораулар:
- Карга канаты ни төсле?
- Кара төсне белер өчен кая карарга кирәк?
- Тагын чем-кара нинди кошлар туган якка кайтканнар?
4. Шигырьне яттан сөйләү (6 – 7 бала сөйли).
5. Санамыш:
Каенда – карга,
Имәндә – чыпчык,
Җирдә – елан,
Һавада – кош,
Бар син дә оч.
6. Сүзле-хәрәкәтле уен «Әйтеп бирче, үскәнем».

Балалар түгәрәк ясап басалар. Бер бала санамыш ярдәмендә сайланып уртага чыгарыла, калганнары күмәк җырлап әйләнәләр. Уртадагы балага төрле эшләр кушалар. Эшләр кошлар тематикасына багышлана.

- Әйтеп бирче, үскәнем,
Нинди төстә каргалар?
- Кара төстә, кара төстә,
Чем-кара ул каргалар.
- Әйтеп бирче, үскәнем,
Нинди төстә сыерчыклар?
- Яшькелт, кара яшькелт
Бу була сыерчыклар.

## Проект. Урман. Кызыл китап
### Тема. «Нәрсә ул Кызыл китап?»

**Бурычлар:**

1. Балаларда күмәк сөйләшүдә катнашу, бер-береңне тыңлый белү күнекмәләре формалаштыру.

2. Балаларның сорауларга ашыкмыйча, эзлекле итеп җавап бирү сыйфатын, логик фикерләү сәләтен үстерү.

3. Балаларның табигатьне саклау турындагы күзаллауларын киңәйтү, «Кызыл китап» турындагы белемнәрен тирәнәйтү, Татарстанның «Кызыл китабы» турында белешмә бирү, кыска хикәя төзи белүне камилләштерү.

**Сүзлек:** тыюлык, энҗе чәчәк (русча: ландыш), нәүрүз (русча: первоцвет), төнбоек, туй чәчәге, кеш.

**Җиһазлар:** слайдлар, рәсемнәр, фотолар.

**Эшчәнлек барышы**

1. Тәрбияче хикәясе.

Язның матур бер көнендә балалар урманга бардылар. Урман аларны бик шатланып, матур җырлары белән каршы алды. Алан тулы умырзаялар, нәүрүз, энҗе чәчәкләре үсә икән. Балалар күпләп шушы чәчәкләрне җыйдылар, урманда туйганчы уйнадылар. Урман гына никтер тынып, моңсуланып калды. Гүя ул борчулы иде. Балалар өйләренә кайтып киттеләр.

2. Үстерешле диалог.

- Ни өчен урман моңсуланып калган?
- Балалар урманга килгәч, нинди хата җибәргәннәр?
- Нәрсә ул «Кызыл китап?»

3. Табышмак:

Кош-корт, җәнлек, үсемлекләр,<br>
Бетәбез дип торганда,<br>
Бирешмәскә булганнар:<br>
Саклар диеп, яклар диеп,<br>
Аңа кереп тулганнар. («Кызыл китап»)

4. Слайдлар яки рәсемнәр карау. «Кызыл китап».

Тәрбияче: Җир йөзендә бик сирәк очрый торган үсемлекләрне,

хайваннарны, кошларны Кызыл китапка кертәләр. Алар саклауга мохтаҗ. Сирәк калган һәм бетеп баручы үсемлек, җәнлек, кошкортларны саклап калуда тыюлыкларның әһәмияте зур. Анда эшләүчеләр мондагы хайваннарны, үсемлекләрне күзәтеп торалар, санын исәпкә алалар. Безнең республикабызда бик зур Раифа тыюлыгы бар. (Республикабызда Кызыл китапка кертелгән тереклек турында сөйләү). «Кызыл китап» ачылмалы календарьга охшаган. Аның битләрен яңалары белән алыштырырга яисә бөтенләй алып куярга мөмкин. Тыюлыкларда яшәүче хайваннарның, үсемлекләрнең, кошларның һ.б. саны арта, үрчи бара. Әгәр дә без табигатькә зыян салмасак, үсемлекләрне күпләп өзмәсәк, кошларны тотмасак, хайваннарны ауламасак, ул вакытта аларның саны артыр, алар саклауга мохтаҗ булмаслар иде. Шул вакытта аларны «Кызыл китап»тан чыгарырга да мөмкин булыр.

5. Үстерешле уен «Урман кагыйдәләре» (туп белән).

- Чәчәкләрне өзәргә ярамый!
- Кошларның ояларын туздырырга ярамый!
- Агачларны сындырырга ярамый!
- Керпе балаларын өйгә алып кайтырга ярамый! һ.б.

6. «Бирелгән сүзләрдән хикәя төзе!» уены.

Мәсәлән: урман, балалар, кош баласы, оя, шатлана, рәхмәт әйтә, җыр.

Үрнәк: Балалар урманга бардылар. Марат агач төбендә кош баласын күреп алды. Балалар аны оясына менгезеп куйдылар. Әни кош аларга рәхмәт әйтеп, үзенең матур җырын сузды. Балалар ярдәм итә алуларына шатландылар.

7. Сүзле уен «Урманда» (балалар сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар).

Бергәләшеп җыйналып,
Без барабыз урманга.
«Хәерле юл» теләп, безгә
Күктә кояш елмая.
Канатларын җилпи-җилпи,
Күбәләкләр очалар.
Ак каеннар төпләреннән
Без гөмбәләр эзләдек.
Агач башында уйнаган
Тиеннәрне күзләдек.
Кызарган җиләкләрне
Салдык җыеп кәрзингә.
Урман озатып калды,
«Килегез!»- дип иртәгә.

## Тема. Әңгәмә. «Урман – безнең байлыгыбыз»

**Бурычлар:**

1. Балаларда игътибарлылык, әйләнә-тирә табигатькә, урманга карата сакчыллык, миһербанлылык сыйфатлары, экологик культура тәрбияләү.

2. Табигатьтәге үзара мөнәсәбәтләрне күрә белү сәләтен, диалогик сөйләмне үстерү.

3. Татарстан җирлегендә үсә торган урман үсемлекләре турында белемнәрен камилләштерү; үз тәҗрибәсенә, белеменә таянып, агачлар турында кыска хикәя төзүдә күнектерү.

**Сүзлек:** колач, имән, карама.

**Җиһазлар:** аудиоязмада «Урман» музыкасы (Н.Җиһанов, «Кырлай» симфоник поэмасыннан), урман рәсемнәре, агач рәсемнәре, аю битлеге.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак.

Колач җәеп каршы ала,
Сулышларны киңәйтә.
Кайчак ул караңгы, шомлы,
Исемен аның кем әйтә? (Урман)

2. Музыка тыңлау: «Урман» (Н.Җиһанов көе, «Кырлай» симфоник поэмасыннан).

3. Үстерешле диалог.

- Бу музыканы тыңлаганда, сез урманны нинди итеп күз алдына китердегез?
- Урманның нинди төрләрен беләсез? (Ылыслы, яфраклы, катнаш)
- Урман кешегә ни өчен кирәк?
- Кошларга, хайваннарга, бөҗәкләргә урман ни өчен кирәк?
- Урман безгә нинди файда китерә?
- Әгәр урманнарны сакламасак, нәрсә булырга мөмкин?

4. Дидактик уен. «Агачны таны һәм сөйлә!»

Балалар агач рәсемнәре төшерелгән карточкаларны алалар, исемен әйтәләр һәм үзенчәлекләрен сөйлиләр.

1) Имән зур, көчле агач. Алар яктылык ярата. Имәннән йорт

җиһазлары ясыйлар, корабль төзелешендә кулланалар. Аннан кешеләргә дарулар да әзерлиләр. Имәннең себеркесе дә шифалы. Имән бер мең ел үсә ала.

2) Юкә июльдә чәчәк ата, безгә тәмле бал бирә, чәчәге дару була. Аның агачыннан кашыклар, төрле савытлар, йорт өчен кирәк-яраклар ясыйлар һ.б.

5. Җырлы уен «Урманга барам».

Балалар таралышып, салмак хәрәкәтләр ясап, җиләк җыялар һәм җырлыйлар.

Тиз-тиз итеп савытыма
Эре җиләкләр җыям.
Аларны йә киптерәм,
Йә татлы каклар коям.
Монда җиләк күп икән,
Аю-бүре юк микән.

Соңгы сүзне әйтүгә, «аю» килеп чыга һәм балаларны куа башлый.

6. Тизәйткеч ятлау, [ж] авазы.

Урманда җиләк җыйганда
Җиңен ерткан Җамалый.
Елама-елама, Җамалый,
Елап җиңең ямалмый.

7. Сынамышлар.

а) Кыш көне урман шауласа – көн җылыта.

б) Февральдә агачларда бәс күп булса, бал күп була.

в) Чикләвек күп, гөмбә аз булса – кыш салкын һәм карлы була.

г) Имәндә чикләвек күп булса – кыш салкын була.

## Тема. Хикәянең эчтәлеген сөйләү: Р.Төхвәтуллин. «Шомырт нигә елый?»

**Бурычлар:**

1. Әдәби әсәрләр аша балаларда табигатькә сак караш, миһербанлылык, игътибарлылык тәрбияләү.

2. Балаларның монологик сөйләмен, фикерне бер юнәлешкә җыя белү сәләтен, хәтерне үстерү.

3. Әдәби жанрны аера белү күнекмәләрен, әсәрнең эчтәлеген

башкаларга җиткерә белүне камилләштерү.

**Сүзлек:** канат-ботак, әрнү, рәхимсез.

**Җиһазлар:** шомырт агачы рәсеме, туп, «Агачлар да авырый» мультфильмы.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 417 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Уен «Ми чарлау» (туп белән).

- Агач исеме?
- Нинди куаклар беләсез?
- Дару үләннәре?
- «Кызыл китап»ның файдасы нидә?
- Урман төрләрен атагыз.
- «Кызыл китап»ка кертелгән чәчәкләр ниндиләр?
- Файдалы бөҗәкне атагыз.

2. Табышмак.

Иелә, бөгелә,
Ак мамыгы түгелә,
Кара күзе күренә. (Шомырт)

3. Хикәя уку: Р.Төхвәтуллин. «Шомырт нигә елый?»

4. Балаларга сораулар:

- Мин сезгә нәрсә укыдым? (Хикәя, шигырь, әкият)
- Шомырт агачы ни өчен моңаеп басып тора?
- Ни өчен ботакның яфраклары әрнеп, йөзләрен җыерган?
- Шомырт, рәнҗеп, кешеләргә нәрсә дигән?
- Әти белән малай шомыртка ничек ярдәм иткәннәр?
- Көз көне әти белән малай аланлыкка баргач, нәрсә күргәннәр?
- Шомырт нигә елаган?
- Сез шомырт ботагын сындыручыларга нәрсә әйтер идегез?

5. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала сөйли).

6. Мультфильм карау: «Агачлар да авырый».

**Тема. Хикәянең эчтәлеген сөйләү:**
**М.Пришвин. «Алтын болын»**

**Бурычлар:**

1. Әдәби әсәрләр аша балаларда табигатькә карата уңай

мөнәсәбәтләр, бер-берсен тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү.

2. Балаларның табигать, андагы бәйләнешләр турында белергә теләкләрен, кызыксынучанлыкларын үстерү.

3. Әдәби жанрны аера, хикәянең эчтәлеген башкаларга җиткерә белү күнекмәләрен камилләштерү.

**Сүзлек:** тузганак, гаҗәп.

**Җиһазлар:** тузганак рәсеме, аудиоязмада «Табигатьне саклыйк!» җыры (Р.Харис сүзләре, Р.Әхиярова көе).

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 190 бит.

## Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Нечкә яшел сабакта
Юл буенда шар үскән.
Кай арада җил искән,
Ак шар очкан да киткән. (Тузганак)

2. Хикәя уку: М.Пришвин. «Алтын болын».

3. Балаларга сораулар:

- Мин сезгә нәрсә укыдым?
- Тузганак чәчәкләре өлгергән вакытта малайлар ничек итеп уйнаганнар?
- Авылда малайларның тәрәзә каршындагы болынны ничек дип атаганнар?
- Иртә белән малай болынны нинди төстә итеп күргән?
- Төш вакытында болын ничек үзгәргән?
- Кич белән болынның яшелләнгәнен күргәч, малай нишләгән?
- Ул тузганак чәчәкләрен нәрсә белән чагыштырган?
- Ни өчен тузганак малайлар өчен иң кызыклы чәчәк булып киткән?
- Ни өчен язучы болынны «алтын болын» дип атый?

4. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала сөйли).

5. Сүзле-хәрәкәтле уен «Апрель» (сүзләргә туры китереп балалар хәрәкәтләр ясыйлар).

Гөрләвекләр агалар,
Күктә кояш елмая.
Каңгылдашып, торналар
Тезелеп үтте бая.

Инешләрдә коена
Канатланып үрдәк-каз.
Җирне яшәртеп безгә
Гөлләр алып килә яз.

6. Җыр тыңлау: «Табигатьне саклыйк!» (Р.Харис сүзләре, Р.Әхиярова көе).

## Проект. Китап кайдан килә?
### Тема. Китапханәгә экскурсия

**Бурычлар:**

1. Балаларда китапханәче хезмәтенә карата ихтирам, китапханәдә үз-үзеңне тота белү сыйфатлары тәрбияләү.
2. Китапханә белән турыдан-туры таныштыру аша балаларда күзәтүчәнлек, игътибарлылык, эзлекле фикерләү сәләтен үстерү.
3. Балаларга китапханәче һөнәренең мөһимлеген аңлату.

**Сүзлек:** редактор, китап төпләү, китап бастыру.

**Җиһазлар:** «Китапханәче» рәсеме.

### Эшчәнлек барышы

1. Табышмак:

Тавышсыз, кулсыз булса да,
Күп сүзле, күп рәсемле.
Нинди тылсымлы әйбер ул?
Син, дускай, беләсеңме? (Китап)

2. Китапханәгә экскурсия:

- Китапханә ни өчен кирәк?
- Ул нинди заллардан тора?
- Киштәләр нинди бүлекләргә бүленгән? Ни өчен?
- Китапханәдә үзеңне ничек тотарга кирәк?
- Китапханәче нинди эшләр башкара?

3. Мәкаль: Эчтәлеге буенча фикер алышу.

Китап укысаң – белемең артыр, укымасаң – белгәнең дә онытылыр.

4. Зиһен уены «Кайда, нәрсә, ничек?»

- Китапның гомере озын булсын өчен, нәрсә эшләргә кирәк?

- Китапка язар өчен башта нәрсәләр кирәк?
- Язучы, шагыйрь китап өчен нәрсә яза?
- Редактор нишли?
- Кем китап бастыра?
- Китапның битләрен нишләтәләр? (Ябыштыралар, төплиләр)
- Рәссам нишли?
- Кайчан китап әзер була? (Тышлап, исем кушкач)

5. Тел көрмәкләндергеч «Тап».

Тап-тап-тап – кызыклы китап.
Тап-тап-тап – калын китап.
Тап-тап-тап – рәсемле китап.
Тап-тап-тап – бу минем китап.
Тап-тап-тап – миңа бир китап.

### Тема. Бирелгән сүзләрдән хикәя төзү: «Китап кибете»

**Бурычлар:**

1. Балаларда сөйләм әдәбе тәрбияләү.
2. Логик фикерләү, иҗади күзаллау сәләтен үстерү.
3. Балаларда логик кысага сыйган эзлекле хикәя төзи белү күнекмәләре формалаштыру.

**Сүзлек:** таҗ, керле кул, керсез күңел.

**Җиһазлар:** ак чәчәк (ромашка) таҗлары.

### Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль. Эчтәлеге буенча фикер алышу.

Китап – кешенең дусты.

2. Шигырь уку: Х.Шабанов. «Кадерлә син китапны».

Китап – киңәшчең синең,
Дустың, ярдәмчең синең.
Ул хөрмәткә бик хаклы,
Кадерлә син китапны.
Почмакларын бөкләмә,
Битләрен дә ертма син.
Ул яратмый пычракны,
Керне, тузанны, тапны.
Саф, керсез күңелең белән
Бик чиста тот китапны.

3. Бирелгән сүзләрдән хикәя төзү. Мәсәлән: сатучы, китап, касса, акча, кызыклы, рәсемнәр, киштә.

4. План.

- Кибеткә кем белән бардыгыз?
- Кибеттә нәрсәләр сатыла?
- Китап сайлауда кем ярдәм итте?
- Акчаны кайда түләдегез?
- Сезгә нинди тылсымлы сүзләр ярдәм итте?
- Сезнең уй-кичерешләрегез?

5. Балалар эшчәнлеге (6 – 7 бала).

6. «Ак чәчәк» уены. [к], [л] авазлары кергән сүзләр табу (ак чәчәкнең таҗ яфракларындагы иҗекләрне куеп, сүзләр ясау). Мәсәлән: ка - л, ку - л, кы - л, ки - л, кү - л.

### Тема. Шигырь уку: Х.Халиков. «Китап докторы»

**Бурычлар:**

1. Балаларда китапларга сак караш, хөрмәт тәрбияләү.
2. Сорауларга эзлекле, җыйнак, төгәл һәм матур итеп җавап бирә белү күнекмәләрен, логик фикерләү сәләтләрен үстерү.
3. Шигырь жанрын аера белүне камилләштерү, кыска хикәя төзүләренә ирешү.

**Сүзлек:** китап докторы, дәва, чир.

**Җиһазлар:** эчтәлекле рәсемнәр, микрофон.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 161 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмак:

Кечкенә генә сандыкка
Бөтен дөнья сыйган. (Китап)

2. Шигырь уку: Х.Халиков. «Китап докторы».

3. Балаларга сораулар:

- Мин нәрсә укыдым? (Хикәя, әкият, шигырь)
- Китап ничек авырый?
- Китапны ничек дәваларга була?

4. Сүзле уен «Киресен әйт».

Алырга – куярга.
Ачарга – ябарга.
Матур – ямьсез.
Калын – юка.
Кызык – кызганыч.
Яхшы – начар.

5. Зиһен уены «Тәртип буенча тез».

Китап ремонтлау буенча эчтәлекле рәсемнәр бирелә. Балалар шул рәсемнәрне тәртибе буенча тезеп чыгалар һәм сөйләп бирәләр.

6. Уен-интервью (алып баручы бала үзен журналист итеп күрсәтә, микрофон ярдәмендә сораулар бирә):

- Син китап укырга яратасыңмы?
- Нинди китаплар яратасың?
- Нинди әкият (шигырь, хикәя) геройлары сиңа ошый? Ни өчен?
- Китапларны ничек саклыйсың?
- Китап бите ертылса, нишлисең?
- Китапларны каян аласың?
- Китапларны кем яза, кем төпли, сата?

## Проект. Космос

### Тема. «Нәрсә ул Кояш системасы?»

**Бурычлар:**

1. Тирә-юньне, табигатьне аңларга һәм сакларга сәләтле социаль актив, иҗади шәхес тәрбияләү.

2. Балаларның аралашу осталыкларын, вакыйгаларның яңа эзлеклелеген төзи белү күнекмәләрен үстерү.

3. Балаларның Кояш системасы турындагы белемнәрен камилләштерү.

**Сүзлек:** Кояш системасы, галәм – космос, орбита, күк җисемнәре, метеорит.

**Җиһазлар:** күк җисемнәре кергән рәсемнәр, фотографияләр, слайдлар, сюжетлы-рольле уен өчен кирәк-яраклар.

### Эшчәнлек барышы

1. «Зирәкләргә табышмаклар»:

а) Өй башына утырган, җир йөзен нур белән тутырган. (Кояш)

б) Зур палас төбендә йомры калач. (Ай һәм йолдызлар)

в) Төнлә калка, көндез ята. (Ай)

2. Үстерешле диалог.

- Ай, кояш, йолдызларны ничек дип атыйлар? (Күк җисемнәре)

- Тагын нинди күк җисемнәрен беләсез?

- Космос дип нәрсәне атыйлар? (Космос ул – җирдән күренә торган тирәлек: йолдызлар, кояш, планеталар, метеоритлар)

3. Тәрбияче хикәясе (интерактив такта яки рәсемнәр, фотографияләр ярдәмендә):

Кешеләрне элек-электән күк йөзе, йолдызлар, ай, кояш кызыксындырган. Аларны тикшерер өчен галимнәр телескоп уйлап тапканнар. Галәмдә барлыгы тугыз планета бар: Плутон, Нептун, Меркурий, Венера, Марс, Уран, Җир, Юпитер һәм Сатурн. Алар Кояш тирәли әйләнә. Бер-берсенә бәрелмиләр, чөнки һәрберсенең үз юлы (орбитасы) бар. Бу планеталар һәм Кояш Кояш системасы дип атала. Җир планетасы – тереклек булган бердәнбер планета. Кояш – безгә җылылык һәм яктылык бирүче йолдыз.

4. Сүзле уен «Кояш һәм йолдызлар». [з] авазы (сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр башкарыла):

Иртән кояш күренә,
Менеп китә үренә.
Сокланабыз эшенә –
Нур сибә бар кешегә.
Көне буе йоклыйлар да,
Төн җиткәч, уяналар,

Лампочка күк кабыналар,
Җем-җем итеп яналар.
Нәрсә соң ул, балалар?
Без беләбез: йолдызлар.
Бергәләп акрын һәм тиз кабатлау:
«Без-з-з, йолдыз-з-з-лар».

5. Шигырь уку: Г.Гыйльманов. «Чүмеч йолдыз».

Чүмеч йолдыз яши күктә, –
Төнлә чыгып карагыз.
Балкып җемелди башласа,
Гел яхшыга юрагыз!
Бу йолдызның күк йөзендә
Эше җайлы көйләнгән.

Ул һәр таңда сихри суын
Сибеп чыга үләнгә.
«Чык» диләр аны кешеләр,
Чык – суның иң чистасы.
Чүмеч йолдыз – йолдызларның
Иң шәбе, иң остасы!

6. Сюжетлы-рольле уен «Космонавтлар».

### Тема. Әңгәмә. «Космонавтика көне»

**Бурычлар:**

1. Балаларда уен барышында ярдәмләшү, бер-береңә булышу күнекмәләре тәрбияләү.

2. Балаларның кызыксынучанлыгын, алган белемнәрен мөстәкыйль куллана белү сәләтен үстерү.

3. Космонавтика көне турында белемнәрен формалаштыру.

**Сүзлек:** ракета, космонавт, космонавтика көне, скафандр, глобус.

**Җиһазлар:** «Космоска очучы» рәсеме, кәгазьдән киселгән йолдызлар, аудиоязмада «Яшь космонавтлар» җыры (Т.Мөхәммәтшин сүзләре, Ф.Әхмәтов көе), рәсемнәр, фотолар, слайдлар, глобус.

**Эшчәнлек барышы**

1. Җир макеты – глобусны карау.

- Безнең планетабыз нинди?
- Зәңгәр төс нәрсә аңлата?
- Яшел төс нәрсәне билгели?
- Җирнең нинди «туганнарын» беләсез?
- Җир башка планеталардан нәрсә белән аерыла?
- Анда нинди материклар бар?

2. Тәрбияче хикәясе (слайдлар яки рәсемнәр, фотолар ярдәмендә):

Кешеләрне электән үк күк җисемнәре кызыксындырган. Алар галәмгә очу турында хыялланганнар. Галимнәр космик корабль уйлап тапканнар. Галәмгә башта кешеләрне очыртырга курыкканнар. Шуңа күрә иң беренче булып галәмгә этләрне җибәреп караганнар. Ул этләрнең исеме «Белка» һәм «Стрелка» булган. Алар галәмнән исән-имин әйләнеп кайткач, кешеләр үзләре очканнар. Иң беренче булып галәм киңлекләрен яулаган кеше – Ю.А.Гагарин. Шуннан бирле 12 нче апрель һәр елны Космонавтика көне дип билгеләп үтелә. Космонавтлар алар бик көчле, кыю, батыр кешеләр. Космик корабльләр елдан-ел камилләшә бара. Очучылар ачык космоска чыгалар. Аларның киемнәре скафандр дип атала. Башларына шлем, аякларына махсус итекләр кияләр. Космоста очучылар яши торган станцияләр бар. Анда космонавтлар бик озак вакытлар яши алалар.

3. Уен-викторина (туп белән):

- Космоска нәрсә белән очалар?
- Беренче космонавт кем?
- Җир йөзендәге иң тиз транспорт төре нинди?

- Космонавт костюмы ничек атала?
- Сез нинди планеталарны беләсез?
- Галәмдә иң зур һәм иң кызу йолдыз?
- Чын космонавт нинди була?

4. Хәрәкәтле уен «Кем күбрәк йолдыз җыя?»

Тәрбияче:

Күктәге йолдызларны
Тизрәк тотасы килә.
Галәмдәге серләрне
Бик тиз беләсе килә.

(Тәрбияче төрле төстәге йолдызларны идәнгә сибә).

Балалар:

Галәмгә без очарбыз,
Йолдызларны тотарбыз.
Очкан чакта болытларны,
Ак җилләрне кочарбыз.

(Балалар идәндәге йолдызларны җыялар. Кем күбрәк җыя, шул җиңүче була).

5. Җыр тыңлау: «Яшь космонавтлар» (Т.Мөхәммәтшин сүзләре, Ф.Әхмәтов көе).

### Тема. Шигырь уку: Йолдыз. «Сәлам, галәм!»

**Бурычлар:**

1. Әдәби әсәрләрдән кызыклы сюжетлар кулланып, балаларда юмор хисе тәрбияләү.
2. Балаларның хәтерен, логик фикерләү сәләтен, җитезлекләрен үстерү.
3. Балаларның галәм турындагы белемнәрен системалаштыру, диалогик сөйләм формаларын камилләштерү, оригами ысулы белән уенчык ясарга өйрәтү.

**Сүзлек:** сер, метеорит яңгыры.

**Җиһазлар:** планета сурәтләнгән битлекләр, һәр бала өчен кәгазь.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 375 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. «Ми чарлау» уены.

- Күк җисемнәрен атагыз.
- Планета исемнәрен беләсезме?
- Безгә җылылык һәм яктылык бирүче йолдызның исеме ничек?
- Беренче космонавт кем?
- Җир макеты нәрсә ул?
- Галәмгә очучы очкыч ничек атала?
- Безгә нәрсә якынрак: болытлармы, әллә кояшмы?
- Безгә иң якын күк җисеме нинди?

2. Шигырь уку: Йолдыз. «Сәлам, галәм!»

3. Балаларга сораулар:

- Айнур исемле малай кемнәргә хәбәр бирә?
- Ул марсианнарга көз турында нинди сораулар бирә?
- Айнур аларны ничек итеп чакыра?

4. Сүзле уен «Галәм». [ж], [ш] авазлары.

Балалар түгәрәккә басалар. 9 планета битлекләре балаларга таратыла.

Жи- ши- жи-<br>
Шу- жу- шу-<br>
Жу- шу- жу-<br>
Ши- ши- жи-<br>
Космонавт булырбыз,<br>
Галәм буйлап очарбыз.<br>
Галәмдәге серләрне<br>
Сезгә кайтып сөйләрбез,- дип түгәрәк буйлап йөриләр. «1, 2, 3» сүзләренә битлекләр кигән балалар Кояш системасында урнашу тәртибен саклап тезелергә тиешләр: Кояш – Меркурий – Венера – Җир – Марс – Юпитер – Сатурн – Уран – Нептун – Плутон (планеталарны киметеп алырга да була).

5. Космик табышмаклар:

а) Зәңгәр яулык буйлап сары шар тәгәри. (Күк йөзе, Кояш)<br>
б) Яктырта, ләкин җылытмый. (Ай)<br>
в) Нинди яңгыр чылатмый? (Метеорит яңгыры)<br>
г) Ул булса көн, ул булмаса төн. (Кояш)<br>
д) Үзе ялтырый, үзе калтырый. (Йолдызлар)

е) Тау аркылы ук аттым,
Аткан угым югалттым. (Йолдыз атылу)

6. Балалар эшчәнлеге – оригами (балалар белән кәгазьдән бөкләп ракеталар ясау).

## Проект. Спорт

### Тема. «Казанда Универсиада»

**Бурычлар:**

1. Балаларда спортка карата уңай караш, сәламәт яшәү рәвеше тәрбияләү, сәламәтлек өчен файдалы һәм кызыклы эшчәнлеккә өстенлек бирү омтылышы булдыру.

2. Спорт уеннары, күнегүләре, спортка бәйле вакыйгалар белән кызыксынуларын үстерү.

3. Татарстан спортчыларының физкультура һәм спорт өлкәсендә ирешкән кайбер уңышлары, Казанда үтәчәк Универсиада турында мәгълүмат бирү.

**Сүзлек:** Универсиада, символ, континент, чемпион.

**Җиһазлар:** Универсиаданың символы, флагы, йолдызы, уен өчен рәсемнәр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырьдән өзек уку: Г.Морат. «Физкультура».

Көн дә күнегүләр ясыйм:
Гер күтәрәм, туп тибәм ...
Шаккатмассыз, әгәр мәшһүр
Чемпион чыкса миннән.

Көчле, нык булып, чыныгып
Үсәсем килә тизрәк.
... Туган телне сакларга да,
Туган телне якларга да
Сәламәт акыл кирәк.

2. Балаларга сораулар:
- Спорт кешегә ни өчен кирәк?
- Иртән күнегүләр ясыйсызмы?
- Аларның кеше организмына нинди файдасы бар?
- Спорт белән дус булмаган балалар нинди булалар?

3. Тәрбияче хикәясе (Универсиада флагы тоткан Юни рәсеме күрсәтелә).

Бу 2013 елда Казанда үтәчәк Универсиада символы барс ма-

лае Юни рәсеме. Универсиада – спорт ярышлары һәм уеннары. Бу уеннар үткәрелә башлауга 50 елдан артык вакыт үткән. Биш төстәге йолдыз Универсиада флагын бизи. Бу ярышларда биш континенттан килгән студентлар катнаша. Биш төстәге йолдыз биш континентны аңлата. Европа – зәңгәр, Азия – сары, Африка – көрән, Австралия – яшел, Америка – кызыл төс белән бирелгән. Бу спорт ярышлары аша төрле континент кешеләре арасында дуслык ныгый. Универсиада программасында спортның 13 төре бар: җиңел атлетика, футбол, баскетбол, нәфис гимнастика, фехтование, йөзү, су полосы, теннис, өстәл теннисы, волейбол, суга сикерү, дзюдо, спорт гимнастикасы.

Татарстан спортчылары барлык спорт ярышларында катнашалар һәм призлы урыннарны алалар. Мәсәлән: 2008 елда Пекинда уздырылган Олимпия уеннарында Татарстаннан 12 спортчы катнашты. Аннан 7 спортчы бүләкләр алып кайтты. Шуларның өчесе алтын медаль иде. Чаллы кызы Гөлнара Галкина-Сәмитова җәйге Олимпиада уеннарында чемпион булды. Безнең республикабызда биш дөнья чемпионы яши. Татарстанның барлык шәһәр һәм авылларында спорт белән шөгыльләнүчеләр өчен төрле шартлар тудырыла, чөнки спортның кеше тормышында әһәмияте бик зур (тәрбияче хикәясен слайдлар, фотолар, рәсемнәр ярдәмендә сөйли).

4. Сүзле уен «Шаян балалар» (балалар ирекле басалар, сүзгә туры китереп, хәрәкәтләр ясыйлар).

Бигрәк шаян инде без,
Тик тормыйбыз бер дә без.
Кулларны күтәрәбез,
Аннары төшерәбез.
Чүгәлибез, торабыз,
Башны уңга борабыз.

Аннан сулга карыйбыз
Һәм сикерә башлыйбыз.
Шул арада иелеп,
Басарга өлгерәбез.
Тирән итеп сулыйбыз,
Ял итәргә туктыйбыз.

5. Дидактик уен «Бу нинди спорт төре?»

Тәрбияче спорт өчен кирәк – яраклар төшерелгән рәсемнәр күрсәтә, балалар спорт төрен атыйлар. Мәсәлән: шайба, кәшәкә – хоккей, кимоно – карате, туп – футбол, шар, ракетка – өстәл теннисы һ.б.

## Тема. Рәсем буенча хикәя төзү. «Спорт мәйданчыгында»

**Бурычлар:**

1. Балаларда бер-берсен тыңлый, кирәк вакытта башкаларның җавапларын тулыландыра белү сыйфатлары тәрбияләү.

2. Балаларның хәтерен, иҗади күзаллауларын, логик фикерләү сәләтен үстерү.

3. Тәрбияче тәкъдим иткән рәсем буенча зур булмаган күмәк хикәяләр төзеп сөйләү күнекмәләрен камилләштерү; сәламәтлекнең мөһим булуын төшендерү.

**Сүзлек:** гайрәт.

**Җиһазлар:** «Спорт мәйданчыгында» рәсеме, спорт җиһазлары төшерелгән рәсемнәр.

### Эшчәнлек барышы

1. Санамыш:

Бер, ике, өч,

Бездә гайрәт, бездә көч!

2. Фикер алышу.

- Бу санамышны нинди балалар әйтә?
- Алар көчне ничек җыярга мөмкин?
- Сез үзегезне көчле, гайрәтле дип әйтә аласызмы?

3. Рәсем карау: «Спорт мәйданчыгында» (тәрбияче балалар җавабын схема ярдәмендә тактага төшереп бара).

- Рәсемдә елның кайсы вакыты?
- Балалар кайда?
- Спорт мәйданчыгына алар нигә килгәннәр?
- Аларның кулларында нәрсәләр күрәсез?
- Рәсемнең алгы өлешендәге кыз белән малай нишлиләр?
- Алар янындагы кыз нәрсә белән шөгыльләнә?
- Арткы планда балалар нишли?
- Ничек уйлыйсыз, бу балалар нинди булып үсәләр?
- Сез нинди спорт төрләре белән шөгыльләнергә яратасыз?

4. Тәрбияче хикәясе:

Җәйге матур көндә балалар спорт мәйданчыгына килделәр. Алар спорт белән шөгыльләнергә яраталар. Балалар кулларына

спорт кирәк-яраклары тотканнар. Мәйданчыкта һәр бала үзенең яраткан спорт төре белән шөгыльләнә. Рәсемнең алгы өлешендә кыз белән малай кыршау белән гимнастика ясый. Алар янында кыз сикергечтә сикерә. Рәсемнең арткы өлешендә малай белән кыз туплы уйный. Бер малай баскычтан өскә үрмәли, ике малай тасмалар белән күнегүләр ясый. Бу балалар көчле, кыю, җитез, сәламәт булып үсәләр.

5. Балалар эшчәнлеге.

6. Сүзле-хәрәкәтле уен «Эзләп тап».

Балалар түгәрәккә басалар. Бер бала читкә китеп күзен йома. Тәрбияче, алдан әзерләнгән спорт җиһазлары яисә рәсемнәре арасыннан берне сайлап, балаларга күрсәтә. Читтә торган баланы чакырып уртага бастыралар. Балалар:

Без әти белән кибеткә бардык,<br>
Әйт әле, Азат, без нәрсә алдык? – диләр.

Түгәрәктәге балалар тәрбияче күрсәткән спорт җиһазы турында сөйлиләр. Мәсәлән: ул түгәрәк, сикерә, суда батмый, аны тибеп, чөеп уйныйлар, тәгәри, төрле төстә була (Туп); ул агачтан эшләнгән, озын, кыш көне кирәк, кардан бара, таяклары бар (Чаңгы) һ.б. Уртадагы бала җавабын белсә, рәсемнәр арасыннан табып күрсәтә.

### Тема. Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Зарядкага бас»

**Бурычлар:**

1. Матур әдәбият аша балаларда көндәлек хәрәкәт эшчәнлегенә ихтыяҗ формалаштыруны дәвам итү, спорт белән шөгыльләнү теләге тәрбияләү.

2. Балаларның хәтер сәләтен, бер-берсен тыңлый белүләрен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

3. Шигырь аша кеше тормышында спортның әһәмияте турындагы белемнәрен камилләштерү.

**Сүзлек:** җиләс.

**Җиһазлар:** зарядка ясаучы балалар рәсемнәре.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 307 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Мәкаль:

Сәламәт тәндә – сәламәт акыл.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Шигырь уку: Г.Юнысова. «Зарядкага бас».

3. Балаларга сораулар:

- Урыныңнан торгач, нишләргә кирәк?
- Кайчан чыныгып үсеп була?
- Чыныгуда безгә нәрсәләр ярдәм итә?

4. Балалар эшчәнлеге (5 – 6 бала яттан сөйли).

5. Сүзле-хәрәкәтле уен «Шаян балалар» (кабатлап уйнау).

Бигрәк шаян инде без,
Тик тормыйбыз бер дә без.
Кулларны күтәрәбез,
Аннары төшерәбез.
Чүгәлибез, торабыз,
Башны уңга борабыз.

Аннан сулга карыйбыз
Һәм сикерә башлыйбыз.
Шул арада иелеп,
Басарга өлгерәбез.
Тирән итеп сулыйбыз,
Ял итәргә туктыйбыз.

## Проект. Габдулла Тукай иҗаты

### Тема. Әдәби викторина. «Мультфильмда кунакта»

**Бурычлар:**

1. Г.Тукай әкиятләре, шигырьләре аша балаларда матур әдәбият белән кызыксыну, аларны укырга теләк тәрбияләү.

2. Балаларның игътибарлылыкларын, хәтерләрен, фикерләү сәләтен үстерү.

3. Таныш әдәби сюжетлар буенча балаларның Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен камилләштерү.

**Сүзлек:** сайрый, әгъза, гайрәтле, шәкерт.

**Җиһазлар:** «Гали белән кәҗә», «Җил һәм яңгыр», «Кызыклы шәкерт» мультфильмнары.

**Эшчәнлек барышы**

1. Шигырь уку:

- Һич сине куркытмасыннар
Шүрәле, җен һәм убыр.

Барчасы юк сүз – аларның
Булганы юктыр гомер!

2. Балаларга сораулар:

- Сез бу шигырь юлларын ничек аңлыйсыз?
- Бу геройларны кайда очратырга була?
- Бу геройлар кайсы әкияттә яши?
- Әкият геройларын кайда күреп була?
- Бу әкиятләрне кем язган?
- Сез бу язучы турында нәрсәләр беләсез?

3. Әдәби викторина: «Г.Тукай шигырьләрен беләсеңме?»

- Кайсы шигырьдә куян яшь балага үзенең хәсрәтен сөйли? («Бичара куян»)
- Тын да алмыйча, шауламыйча, кошлар сайравын тыңлый. («Кошларга»)
- Г.Тукайның кайсы җырын басып тыңлыйбыз һәм ни өчен? («Туган тел»)
- Кайсы шигырьдә песи гаилә әгъзасы булып санала? («Безнең гаилә»)
- Авызы белән балчык ташып, матур итеп оя ясаучы кош... («Карлыгач»)
- Көчле сарык белән гайрәтле кәҗә кайсы әкияттә яши? («Кәҗә белән сарык әкияте»)

4. Тизәйткеч: [а] авазы.

Аз-маз алдап өйрәнгәч,
Алдарны да алдаган.
Алдап, алты адым да
Алга китә алмаган.

5. Зиһен үстерү уены «Яхшы – начар». Мәсәлән: мультфильмнар карау яхшы – күңелне күтәрә, яхшы гадәтләргә өйрәтә, үзең өчен яңалыклар ачасың; мультфильмнар озак карау начар – вакытны ала, уйнарга вакыт калмый, озак утырып торырга кирәк һ.б.

6. Мультфильмнар карау (заманча итеп эшкәртелгән Г.Тукай әсәрләреннән эшләнгән мультфильмнар карау. «Гали белән кәҗә», «Җил һәм яңгыр», «Кызыклы шәкерт» һ.б.).

## Тема. Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Кызыклы шәкерт»

**Бурычлар:**

1. Балаларның Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен гомумиләштерү һәм балаларда шигърият белән кызыксыну тәрбияләү.

2. Телнең сәнгатьлелеген камилләштерү, хәтер сәләтен үстерү.

3. Шигырьдәге төп фикерне аңларга, әсәрне сәхнәләштерергә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** шагыйрь, язучы, ятим, аума, газаплыйсың, ауныйсым килә, маэмай, яшьләй, җайсыз, каткач буыннар, уңайсыз.

**Җиһазлар:** магнитофон, эт битлеге, «Шагыйрьнең балачагы» поэмасы буенча слайдлар яки рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 389 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Җыр җырлау: «Туган тел».

2. «Г.Тукайның балачагы» поэмасыннан өзек уку (слайдлар яки рәсемнәр ярдәмендә).

3. Балаларга сораулар. «Г.Тукайның тормыш юлы».

- Тукай кайсы айда туган?
- Әти-әнисе турында нәрсәләр беләсез?
- Сез аның нинди шигырьләрен, экиятләрен беләсез?
- Ни өчен Г.Тукай иҗатын без бүгенге көндә дә өйрәнәбез?
- Г.Тукай әсәрләре безне нәрсәгә өйрәтә?

4. Шигырь уку: Г.Тукай. «Кызыклы шәкерт».

5. Балаларга сораулар:

- Малай Акбайны нәрсә эшләргә өйрәтә?
- Акбай ничек итеп җавап бирә?
- Малай Акбайны ни өчен ачулана?
- Шигырь нәрсәгә өйрәтә?

6. Шигырьне сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Кызыклы шәкерт».

7. Дидактик уен «Табышмакның җавабын әйт – кайсы әсәрдән икәнен бел!»

а) Мыегы бар, сакалы юк,

Туны бар, чапаны юк. («Безнең гаилә»)
б) Сакаллы килеш туа,
Берәү дә гаҗәпләнми аңа. («Гали белән кәҗә»)
в) Чуар, йомшак күлмәге,
Тотсаң уңа бизәге.
Тоттырмый, китә очып,
Я кала җирдә посып. («Бала белән күбәләк»)
г) Туннарга киендерә,
Җылыта, сөендерә.
Тоягы була ярык,
Исеме аның ... (сарык). («Кәҗә белән сарык әкияте»)
д) Урманнан чыгар, үзе чабар. («Бичара куян»)
е) Нәкъ кеше кебек үзе,
Бар маңгаенда мөгезе.
«Былтыр кысты»,- дип акыра,
Туганнарын чакыра. («Шүрәле»)
ж) Кычкырадыр: «Качма! Качма! Тукта, тукта и карак!» («Су анасы»)

**Тема. Шигырь уку: Г.Тукай. «Эш беткәч, уйнарга ярый»**

**Бурычлар:**

1. Матур әдәбият аша балаларда тырышлык, игътибарлылык, сабырлык кебек сыйфатлар тәрбияләү.
2. Балаларның әдәби әсәрләрне тыңлый һәм аңлый белү сәләтен, эчтәлеге буенча сорауларга тулы җавап бирә белү күнекмәләрен үстерү.
3. Балаларның Г.Тукай иҗаты турындагы белемнәрен баету һәм камилләштерү.

**Сүзлек:** заман, сабыр, ихлас, дәрт.

**Җиһазлар:** рәсем-иллюстрацияләр, аудиоязма, «Эш беткәч, уйнарга ярый» мультфильмы.

**Эшчәнлек барышы**

1. Мәкаль:

Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Шигырь уку: Г.Тукай. «Эш беткәч, уйнарга ярый».

3. Балаларга сораулар:

- Мин сезгә нәрсә укыдым? (Шигырь, әкият, хикәя)
- Шигырь хикәядән ничек аерыла?
- Җәйге көндә өстәл янында сабый нишли?
- Кояш аны тышка нинди сүзләр белән чакыра?
- Кояшның сүзенә каршы баланың җавабы нинди?
- Өй түрендә сандугач ни дип сайрый?
- Сандугачка каршы биргән җавабында бала нәрсә ди?
- Бакчадагы алмагач тышка сабыйны ничек итеп чакыра?
- Сабый алмагачка нәрсә дип җавап кайтара?
- Дәресен тәмамлагач, бала нишли?
- Кояш, алмагач, сандугач, агачлар малайны ничек каршы ала?

4. Мультфильм карау: Г.Тукай «Эш беткәч, уйнарга ярый».

5. «Мәкальне дәвам ит!» уены (туп белән; эчтәлекләре буенча фикер алышу).

а) Хөрмәтнең төбе – ... (хезмәт).

б) Хезмәт иясе – ... (хөрмәт иясе).

в) Уңган кеше – ... (алтын кеше).

г) Тырышкан табар – ... (ташка кадак кагар).

д) Сүзең белән мактанма – ... (эшең белән мактан).

е) Бетми калган эш – ... (пешми калган җимеш).

6. Сүзле уен «Булышу». [з], [д] авазлары (балалар сүзләргә туры китереп хәрәкәтләр ясыйлар).

Тышка чыктык,
Ике кулга пычкы тоттык.
Утын кистек:
Зиң-зиң, зиң-зиң.

Ике кулга балта тоттык,
Утын ярдык:
Дддак-дддак, дддак-дддак.
Өйгә кайттык.

**Тема. «Г.Тукай һәм балалар»**

**Бурычлар:**

1. Балаларда бер-берсен тыңлый белү сыйфаты, татар шагыйре Г.Тукай иҗатына кызыксыну тәрбияләү.

2. Балаларның шигырьләрне сәнгатьле сөйләм осталыкла-

рын, логик фикерләү сәләтен үстерү.

3. Балаларның үзләре уйлап тапкан табышмаклар аша уй-фикерләрен башкаларга җиткерә алуларына, сәнгатьле итеп таныш шигырьләрен сөйләүләренә ирешү.

**Сүзлек:** зирәк, тел остасы.

**Җиһазлар:** рәсемнәр, атрибутлар, «Кәҗә белән сарык» мультфильмы.

### Эшчәнлек барышы

1. Шигырь уку:

Табышмакларның җавапларын
Эзләмә әллә кайдан.
Уйласаң әгәр тырышып,
Тиз табарсың Тукайдан.

2. «Зирәкләргә табышмак» (Г.Тукай әсәрләрендәге геройлар турында балалар табышмаклар уйлап әйтәләр).

3. Дидактик уен «Кайсы әкият кирәк-яраклары?» (атрибутлар, рәсемнәр: тарак, капчык, күбәләк тоткыч, түбәтәй, балта, салам һ.б.).

4. Конкурс «Нәни тел остасы» (балалар әти-әниләре белән берлектә ятлаган шигырьләрне яттан сөйлиләр).

5. Җыр җырлау: «Бишек җыры» (Елак кыз Әнвәрәне бишек җыры белән йоклату).

6. Мультфильм карау: «Кәҗә белән сарык».

## Проект. 9 май – Җиңү көне

### Тема. Ветераннар белән очрашу. «Алар безгә Җиңү бүләк итте»

**Бурычлар:**

1. Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.

2. Туган ил һәм дөньядагы вакыйгалар белән кызыксынучанлыкларын үстерү.

3. Ветераннарыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында белемнәрен киңәйтү.

**Сүзлек:** Бөек Ватан сугышы, Җиңү көне, парад, ветеран, батыр, патриот.

**Җиһазлар:** Бөек Ватан сугышы геройлары турында стенд, «Хәтер» китабы, аудиоязмада «Җиңү көне» җыры (А.Гайнетдинова сүзләре һәм көе), чәчәкләр.

**Эшчәнлек барышы**

1. Җыр тыңлау: «Җиңү көне» (А.Гайнетдинова сүзләре һәм көе).

2. Стенд карау: «Бөек Ватан сугышы каһарманнары».

3. «Хәтер» китабы белән танышу.

4. Фикер алышу (солдатларның батырлыклары, үз илен яратучы чын патриот булулары турында сөйләшү).

- Сугышта һәлак булганнарны ничек атыйлар? (Геройлар, батырлар)
- Бөек Ватан сугышында Җиңү яулап кайткан сугышчыларны хәзер ничек дип йөртәләр? (Ветераннар)
- Ветераннар белән кайда һәм нинди очракларда очрашканыгыз бар?
- Безнең Бөек Ватан сугышында һәлак булган геройларның исеме кайсы китапта язылган?
- Хәтер китабын ни өчен илебезнең горурлыгы дип атыйлар?

5. Бөек Ватан сугышы ветераны чыгышы.

6. Балалар эшчәнлеге: «Җиңү көне»нә багышланган шигырьләр сөйләү.

7. Бөек Ватан сугышы ветераннарына чәчәкләр бирү.

8. Һәйкәлгә чәчәкләр кую.

## Тема. Хикәянең эчтәлеген сөйләү. Л.Кассиль «Күңелләрдә мәңге сакланыр»

**Бурычлар:**

1. Балаларда Ватанга мәхәббәт, патриотик хисләр, кыю һәм батыр булу теләге тәрбияләү.

2. Хикәянең эчтәлеге буенча сорауларга төгәл, һәркем ишетерлек һәм аңларлык итеп, грамматик яктан дөрес җөмләләр

белән җавап бирү күнекмәләрен үстерү.

3. Бирелгән хикәя аша сугышчыларыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турындагы белемнәрен киңәйтү.

**Сүзлек:** Кремль стенасы, гранит йолдыз, мәңгелек ут, ант, Ватанга тугрылык, пионер.

**Җиһазлар:** слайдлар яки рәсемнәр.

**Матур әдәбият:** Ф.Ю.Юсупов. «Гөлбакча», 121 бит.

### Эшчәнлек барышы

1. Слайдлар яки рәсемнәр карау. «Бөек Ватан сугышы геройлары» (аларның батырлыклары турында сөйләшү).

2. Хикәя уку: Л.Кассиль. «Күңелләрдә мәңге сакланыр».

3. Балаларга сораулар:

- Батыр солдат кабере кайда?
- Аны ничек хөрмәтлиләр?
- Ул солдат ничек һәлак булган?
- Нәрсә ул мәңгелек ут?
- Яшь солдат батыр каберенә карап нәрсә уйлый?
- Пионерлар Билгесез солдат каберендә нинди вәгъдә бирәләр?
- Ни өчен «Тынычлык булсын!» дип телибез?
- Мәңгелек ут янына барганыгыз бармы, анда баргач нинди тойгылар кичерәсез?

4. Хикәянең эчтәлеген сөйләү (6 – 7 бала сөйли).

5. Мәкальләр, әйтемнәр (эчтәлекләре буенча фикер алышу).

а) Ил тыныч булса, без дә тыныч.

б) Батыр иле өчен үләр.

в) Ир егет үзе өчен туа, иле өчен үлә.

6. Хәрәкәтле уен «Кем җитез?»

Командалар алдында старт сызыгы, 1 метр ара билгеләнә. Старт сызыгыннан 3,5 метр ара калдырып, һәр команда каршысына идәнгә кыршау яткырып куела. Сигнал буенча командада беренче торучылар ком тутырылган кечкенә капчыкларны өчәр тапкыр ыргыталар да команданың артына барып басалар. Чираттагы уенчылар шуны кабатлыйлар. Кыршауга капчыкларны

күбрәк төшерә алган команда җиңүче була.

## Проект. Хуш бакчам, исәнме, мәктәп!
### Тема. «Без барабыз мәктәпкә»

**Бурычлар:**

1. Балаларда белем алуга омтылыш уяту.
2. Сөйләм телен, фикерләү сәләтен, танып белү активлыгын үстерү.
3. Балаларның мәктәп турында күзаллауларын киңәйтү.

**Сүзлек:** кыңгырау, әсбап, сумка сөйрәлер.

**Җиһазлар:** «Укытучы» рәсеме, таблица, уку әсбаплары, бозгыч, карандаш, китап, дәфтәр, уенчыклар, аудиоязмада «Хуш, сөекле бакчабыз» җыры (Ә.Бикчәнтәева сүзләре, Н.Лотфуллина көе).

**Эшчәнлек барышы**

1. Табышмаклар бакчасы.

а) Арттан калмас иярер,
Начар булсаң – сөйрәлер. (Укучы сумкасы)
б) Бары тик сине тыңлый,
Башыңда нинди уй –
Ул шуны җырлый. (Каләм)
в) Каләм, кара аласың,
Ак юлына язасың. (Дәфтәр)
г) Үзе укый белмәсә дә,
Гомере буе яза. (Ручка)
д) Бер тартмада алты дус,
Алтысында алты төс.
Ләкин алар барсы да
Башкаралар бер үк эш. (Буяу карандашлары)
е) Юк аягы, юк күзе,
Сөйли, өйрәтә үзе,
Телгә аннан оста юк,
Аннан якын дус та юк. (Китап)
ж) Кара кыр буйлап

Ак куян чаба. (Акбур)

з) Сумка тотып керәсең,
Белем алып чыгасың. (Мәктәп)

2. Үстерешле диалог «Без мәктәпкә барабыз».

- Көз җиткәч, балалар кая баралар?
- Мәктәпкә баручы балаларны кемнәр дип атыйлар?
- Укырга, язарга, җир, табигать, тормыш серләрен аңларга кем ярдәм итә?
- Кыңгырау тавышы нәрсә турында хәбәр итә?
- Укучыларның сумкасында нәрсәләр бар?
- Мәктәптә үзеңне ничек тотарга кирәк?

3. «Кем тизрәк мәктәпкә җыена?» уены (уку әсбапларын укучы сумкасына тутыру).

4. Уен-реклама.

Алып баручы балаларга уку әсбаплары сайлап алырга куша. Һәр бала үз әсбапларына реклама ясарга тиеш. Иң күп билгеләр әйтеп мактый алган бала җиңүче була.

5. Дидактик уен «Сүз яса һәм җөмлә төзе!» [м] авазы.

М- ... (ал)        М- ... (арт)
М- ... (ул)        М- ... (арс)
М- ... (ич)        М- ... (арш)

6. Җыр тыңлау: «Хуш, сөекле бакчабыз» (Ә.Бикчәнтәева сүзләре, Н.Лотфуллина көе).

Хуш, сөекле бакчабыз,
Сау булыгыз, апалар!
Кала курчакларыбыз,
Безне көтә парталар.
Кушымта: Парталар, парталар,
Үзләренә тарталар.

Мәктәпләр дә матурлана,
Нурлар сибеп таң аткач.
Бик күңелле була икән,
Китапларны яраткач.
Кушымта: шул ук.

**Тема. Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Һәркем эштә»**

**Бурычлар:**

1. Балаларда театр сәнгате аша эстетик зәвык тәрбияләү.
2. Образлар аша баланың күзаллау сәләтен, фантазиясен, сөйләм телен үстерү.

3. Әкиятне сәхнәләштергәндә балаларны образга керергә, авазларны, сүзләрне ачык, дөрес итеп әйтергә өйрәтүне дәвам итү.

**Сүзлек:** сабак, булдыклы, гадел, тугры, шөшле.

**Җиһазлар:** туп, театр киемнәре.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 401 бит.

## Эшчәнлек барышы

1. Мәкаль:

Уйнавын уйна, эшең турында да уйла.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

2. Әкият уку: Г.Тукай. «Һәркем эштә».

3. Балаларга сораулар:

- Әкият кем турында бара?
- Борһанетдин ни өчен сабакка бармый?
- Борһанетдин атка нәрсә тәкъдим итә?
- Ат ни өчен уйнаудан баш тарта?
- Борһанетдинның ничек итеп күңел ачасы килгән?
- Умарта корты ничек җавап бирә?
- Кош Борһанетдин үтенечен ни өчен кабул итми?
- Малайның нәрсә уйлаганын беләсезме?

4. Әкиятне сәхнәләштерү.

5. Тел төзәткеч [ш] авазы.

Көчле кеше очлы шөшле белән
Шушы төшне тиште.

6. Дидактик уен «Сүзләр чылбыры» (туп белән).

Эшчән кешегә нинди сыйфатлар хас икәнлеген әйтү. Мәсәлән: уңган, булган, тырыш, эшчән, булдыклы, ярдәмчел, төгәл, сәләтле, җаваплы, тәртипле, гадел, чыдам, түзем, тугры һ.б.

## Тема. Шигырь ятлау: Б.Рәхмәт. «Мәктәпкә»

**Бурычлар:**

1. Балаларда башкаларны игътибар белән тыңлый белү сыйфаты тәрбияләү.

2. Баларның хәтерен, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен үстерү.

3. Балаларның шигырь эчтәлеге буенча сорауларга тулы

җавап бирүләренә ирешү, укырга теләк уяту.

**Сүзлек:** тормышка юл.

**Җиһазлар:** курчак, җиләк, кармак төшерелгән рәсемнәр яки уенчыклар.

**Матур әдәбият:** К.В.Закирова. «Балачак аланы», 533 бит.

**Эшчәнлек барышы**

1. Тел шомарткыч. [ш] авазы.

Беләсеңме?
Үзе яхшының
Эше дә яхшы,
Үзе яхшыга
Кеше дә яхшы.

2. Мәкаль:

Мәктәп – белем йорты.

Эчтәлеге буенча фикер алышу.

3. Шигырь уку: Б.Рәхмәт. «Мәктәпкә».

4. Балаларга сораулар:

- Кулга чәчәкләр тотып без кая барабыз?
- Әтиләр ничек катлый?
- Әниләр нәрсә әйтә?
- Дәү әтиләр, дәү әниләр нинди теләк телиләр?

5. Шигырьне яттан сөйләү (5 – 6 бала сөйли).

6. Арифметик табышмак:

Без, без, без идек,
Без 5 кенә кыз идек.
Килеп керде Хәдичә, –
Без инде хәзер ничә? һ.б.

7. Әйлән-бәйлән уены (балалар теләге буенча).

# Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр
## (зурлар төркеме)

| Танып белү | Аралашу | Матур әдәбият уку |
|---|---|---|
| - транспорт төрләрен кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне белү;<br>- предметның төсе, күләме, формасы, зурлыгы, авырлыгы, нинди материалдан эшләнгән булуы турында сөйли алу, аларны төркемләү;<br>- төрле һөнәрләр (төзүчеләр, авыл эшчәннәре һ.б.) турында белү;<br>- туган шәһәрең (авылың), туган илең, аның башкаласы, юл йөрү кагыйдәләрен белү;<br>- үз туганнары, үзе турында сөйли алу, өй адресын әйтү;<br>- табигать күренешләрен күзәтеп, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алу, кайбер закончалыкларны белү. | - сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллану, туры һәм кыек сөйләмнән файдалану;<br>- үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзү;<br>- әкиятләрнең ахырын тәмамлау, зур булмаган әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә интонацияләрдән дөрес файдалану;<br>- сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллану;<br>- мәгънәдәш сүзләр һәм капмакаршы сүзләр куллану;<br>- аралашуда актив булу, теләп катнашу. | - әсәрнең жанрын билгели алу (әкият, хикәя, шигырь);<br>- зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерү, рольләргә бүлеп шигырьләрне сөйләү;<br>- яраткан язучыларны атый белү;<br>- укыту методик комплектында күрсәтелгән 2 – 3 шигырьне сөйләү, табышмак, мәкальләрне искә төшереп әйтү;<br>- әдәби персонажның кылган гамәлләре турындагы фикерләрен башкаларга сөйләү;<br>- үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белү. |

## Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече
## *(зурлар төркеме)*

### Танып белү

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне таный һәм әйтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында сөйли, аларны төркемли белә. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында белә. Юл йөрү кагыйдәләрен дөрес әйтә. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында сөйли, адресын әйтә. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны белә, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тулысынча сөйләми, исенә төшергәч, өстәп сөйли белә, төркемли ала. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматны тулысынча биреп бетерә алмый. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә. Үз туганнары, үзе турында аз сөйли, сораулар биргәч, үзлектән тулыландыра. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлатканда, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгарганда кыенлыклар кичерә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре (төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тәрбияче ярдәменнән башка сөйли белми, төркемли алмый. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматы юк. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында әйтә белми. Үз туганнары, үзе турында тәрбияче ярдәмендә сөйли. Адресын белми. Табигатьтәге кайбер закончалыкларны аңлата,

үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алмый.

### Аралашу

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллана белә, туры һәм кыек сөйләмнән файдалана. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә, иҗади хикәяләр төзегәндә интонацияләрдән дөрес файдалана. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллана белә. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне дөрес әйтә белә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда теләп катнаша. Үстерешле аралашуда катнашу дәрәҗәсе камил.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр кулланганда хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белә. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә, бик үк мөстәкыйль түгел. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген тулы бирми, иҗади хикәяләр төзегәндә иҗади түгел. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда, ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйткәндә хаталар җибәрә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы камил дәрәҗәдә түгел.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала сөйләмдә гади җөмләләр куллана, үз тәҗрибәсеннән чыгып, начар сөйли, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген план буенча сөйли белми, иҗади хикәяләренең эчтәлеге гади, интонацияләрдән файдаланмый. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләрне аз куллана. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтми. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда сирәк катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы юк дәрәҗәдә.

### Матур әдәбият уку

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша, тиз истә калдырып, яттан сөйли.

Язучыларны таный һәм атый, әсәрләрен белә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сөйләмдә мөстәкыйль куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйләп бирә ала.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аерганда ялгышлыклар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда активлык күрсәтми, ләкин катнаша. Язучыларны таный, әсәрләрен әйтүдә кыенлыклар кичерә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сирәк куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя биргәндә, хаталар җибәрә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга тулы итеп сөйләми.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера алмый. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда катнашырга теләге юк. Язучыларны танымый, әсәрләрен әйтә алмый. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны кулланмый. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя бирә белми. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белми.

# Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр
## (мәктәпкә әзерлек төркеме)

| Танып белү | Аралашу | Матур әдәбият уку |
|---|---|---|
| - сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллау;<br>- экологик бәйләнешләрне аңлата алу, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белү;<br>- табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматлы булу;<br>- предметларны үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары буенча аерып ала һәм төркемли белү;<br>- үзе, әти-әнисе турында сөйли белү (фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, адресын, телефон номерын әйтә алу), өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфат-лары турында мәгълүматлы булу. | - күмәк сөйләмдә катнашу (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле һәм аңлаешлы итеп сөйли);<br>- сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл куллану;<br>- сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белү күнекмәләре булу;<br>- предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, иҗади хикәяләр төзи белү;<br>- тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белү. | - әсәрнең жанрын билгели алу (әкият, хикәя, шигырь);<br>- китап геройларының хәленә керә белү, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирү, үз мөнәсәбәтен белдерү;<br>- шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйләү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белү;<br>- иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен тану;<br>- китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлау. |

## Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече
## *(мәктәпкә әзерлек төркеме)*

### Танып белү

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый. Экологик бәйләнешләрне аңлата ала, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә ала. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, аларны төркемли белә. Үзе, әти-әнисе турында сөйли белә (фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, адресын, телефон номерын әйтә ала), өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфатлары турында мәгълүматы бар.

**Уртача дәрәҗә (2 балл)**. Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында баланың күзаллавы җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Экологик бәйләнешләрне күрүдә авырыксына, тәрбияче яки балалар ярдәмендә үзе җавап бирә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматы бар, дөрес итеп тәрбияче ярдәмендә аңлата. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйләгәндә хаталар җибәрә, төркемләгәндә хаталар җибәрсә, үзлектән төзәтә белә. Үзе (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы тулы түгел.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында бала күзалламый. Экологик бәйләнешләрне, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысы турында әйтә белми. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә алмый. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, әмма аларны төркемләми. Үзе (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы аз.

### Аралашу

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Бала күмәк сөйләмдә актив катнаша (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле, аңлаешлы

итеп сөйли). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл куллана ала. Сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төзи белә. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә. Бәйләнешле сөйләме чиста, грамматик яктан дөрес.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Бала күмәк сөйләмдә катнаша (сорауларны аз бирә, сорауларга җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып иҗади хикәяләр төзегәндә, хаталар җибәрә, тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала күмәк сөйләмдә катнашмый (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара алмый; вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белми). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төземи.

### Матур әдәбият уку

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Әсәрнең жанрын билгели ала (әкият, хикәя, шигырь). Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен белдерә. Шигырьләрне, сәхнәләштерелгән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таный. Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Әсәрнең жанрын билгеләүдә (әкият, хикәя, шигырь) хаталар җибәрә. Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен аңлата алмый. Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә, сәнгатьлелек җитми. Эчтәлеге буенча сорауларга җавап биргәндә, хаталар җибәрә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә

карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, хаталар җибәрә, күп очракта үзлектән төзәтми. Китаплар белән кызыксына, мөстәкыйльлеге чамалы.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала әсәрнең жанрын (әкият, хикәя, шигырь) тәрбияче ярдәменнән башка билгели алмый. Китап геройларының хәленә керә белми, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә алмый, үз мөнәсәбәтен дөрес аңлата алмый. Шигырьләрне тиз истә калдырмый, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә, сәнгатьлелеге, иҗадилыгы юк. Эчтәлеге буенча сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә яки бирә алмый. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, күп хаталар җибәрә. Китаплар белән кызыксынмый.

# Кулланылган әдәбият

1. Әдәп – матур гадәт: балалар бакчалары тәрбиячеләре, татар телен өйрәтүче тәрбиячеләр, башлангыч сыйныф укытучылары өчен методик кулланма / Төз.: *З.М.Зарипова.*- Яр Чаллы, 2009.

2. Әхлак белеме: кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары, ата-аналар, укытучылар, сыйныф җитәкчеләре, балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм педагогик уку йортлары студентлары өчен хрестоматия / Төз.: *В.С.Казыйханов.*- Яр Чаллы, 2000.- 188 б.

3. Бала бишеге – гомер ишеге: башлангыч сыйныф укытучылары, балалар бакчаларында, милли төркемнәрдә тәрбиячеләр, ата-аналар өчен халык авыз иҗаты әсәрләре җыентыгы / Төз.: *Ф.Зарипова,* иҗади төркем.- Яр Чаллы: Идел-йорт, 2000.- 130 б.

4. Балалар бакчасы: ата-аналар һәм татар балалар бакчалары өчен хрестоматия / Төз.: *Ф.Ю.Юсупов.*- Казан: Раннур, 2002.- 650 б.

5. Балалар бакчасында татарча сөйләм үстерү дәресләре: балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен методик кулланма / Төз.: *З.М.Зарипова, А.И.Касыймова.*- Казан, 2010.

6. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / М.А.Васильева, В.В.Гербова, Т.С.Комарова ред.; 4 нче русча басмадан *К.В.Закирова, Р.Ә.Кадыйрова, З.Г.Ибраһимова, Г.Р.Гыйләҗетдинова, Ф.Җ.Җәләлетдинова* тәрҗ.- Казан: Мәгариф, 2006.- 286 б.

7. Бал бабай: балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр, башлангыч сыйныф укытучылары өчен кулланма / Төз.: *З.М.Зарипова, И.М.Хәмитов.*- Яр Чаллы, 2000.- 167 б.

8. Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / Төз.: *К.В.Закирова, Р.А.Борһанова.*- Казан: Хәтер, 2000.- 192 б.

9. Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм әти-әниләр өчен хрестоматия / Төз.: *К.В.Закирова.*- Казан: РИЦ, 2011.- 560 б.

10. Белем бирү һәм тәрбия процессында милли төбәк компоненты: балалар бакчалары тәрбиячеләре, татар телен өйрәтүче тәрбиячеләр, башлангыч сыйныф укытучылары өчен методик кулланма / Төз.: *З.М.Зарипова,* иҗади төркем.- Яр Чаллы, 2000.- 70 б.

11. *Бородич А.М.* Методика развития речи детей.- Москва: Просвещение, 1981.- 255с.

12. Гөлбакча (балалар бакчалары өчен хрестоматия): балалар бак-

чаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма / Төз.: *Ф.Ю.Юсупов, З.Ф.Камалова, Р.А.Борһанова.*- Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.- 254 б.

13. *Закирова К.В., Гаффарова С.М.* Әткәм-әнкәмнең теле: балалар бакчасы тәрбиячеләренә кулланма.- Казан: Мәгариф, 1997.- 152 б.

14. *Закирова К.В.* Уйный-уйный үсәбез (балалар бакчасында уеннар): балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма.- Казан: Мәгариф, 2005.- 175 б.

15. *Зиннурова Ф.М.* Үз илемдә, үз телемдә: логопедлар, тәрбиячеләр һәм укытучылар өчен методик кулланма.- Казан: Мәгариф, 2009.- 167 б.

16. Иң матур сүз: ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия / Төз.: *К.В.Закирова.*- Казан: Мәгариф, 2000.- 335 б.

17. *Исәнбәт Н.* Балалар фольклоры.- Казан: Татар. кит. нәшр., 1984.- 488 б.

18. *Казыйханов В.С.* Әхлак дәресләре: укытучылар, сыйныф җитәкчеләре һәм тәрбиячеләр өчен дәрес эшкәртмәләре.- Яр Чаллы, 1998.- 240 б.

19. *Кашапова М.Ф.* Балалар бакчаларында телдән сөйләмгә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре: монография.- Казан: РИЦ «Школа», 2009.- 160 б.

20. *Кашапова М.Ф.* Иң гүзәл тел – туган тел: балалар бакчасында сөйләм телен үстерү буенча методик кулланма.- Казан: РИЦ «Школа», 2009.- 200 б.

21. *Кашапова М.Ф.* Иң татлы тел – туган тел: балалар бакчалары өчен сөйләм үстерү буенча методик кулланма.- Казан: Мәгариф, 2004.- 446 б.

22. *Кашапова М.Ф.* Уйныйк әле, балалар: 1 нче китап.- Казан: РИЦ, 2011.- 216 б.

23. Көч һәм рух тамырлары: ата-аналар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен хрестоматия / Төз.: *К.В.Закирова, Р.А.Низамов.*- Казан: Мәгариф, 1998.- 223 б.

24. П*одрезова Т.И.* Материалы к занятиям по развитию речи.- Москва: Айрис-пресс, 2006.- 256 с.

25. Программа по обучению детей русскому языку / Сост.: *З.М.Зарипова, Л.З.Галиуллина, Д.Г.Мансурова, С.Г.Хисамутдинова, А.М.Лотфуллина, Г.Х.Сулейманова, Р.М.Алексеева, Е.И.Муллахметова,*

*Л.З.Касаева.*- Набережные Челны, 2004.- 111 с.

26. Раушан көзге (татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия): педагогика училищеларының мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү бүлеге өчен кулланма / Төз.: *Р.Ш.Халикова.*- Казан: Мәгариф, 1993.- 255 б.

27. Табигатькә сәяхәт: милли балалар бакчаларында, башлангыч сыйныф укытучыларына дәресләр үткәргәндә, ата-аналарга бала тәрбияләүдә куллану өчен методик эшләнмә / Төз.: *Г.М.Хәкимова.*- Яр Чаллы, 2007.- 103 б.

28. Татар халык табышмаклары.- Яр Чаллы: Идел-йорт, 2000.- 96 б.

29. Татар халык уеннары / Төз.: *Р.Ягъфәров.*- Казан: Мәгариф, 2002.- 159 б.

30. Театр уйнап үсәбез: балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр өчен ярдәмлек / Төз.: *А.Т.Хуҗина.*- Яр Чаллы, 2009.- 58 б.

31. Туган телем – бөек анам теле: татар балаларын ана теленә өйрәтү өчен тәрбиячеләргә методик кулланма / *З.М.Зарипова* җитәкчелегендә.- Яр Чаллы, 2004.- 127 б.

32. *Ушакова О.С.* Развитие речи дошкольников.- Москва, 2011.- 237 с.

33. *Ушакова О.С., Струнина Е.М.* Диагностика речевого развития дошкольников.- Москва: Академия, 1999.- 160 с.

34. *Шәех Л.* Җил каян килә: урта яшьтәге мәктәп балалары өчен фәнни-популяр басма.- Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.- 80 б.

35. *Шәехова Р.К., Закирова К.В.* Иҗат баскычлары: мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләре тәрбиячеләренә, башлангыч сыйныф укытучыларына һәм әти-әниләргә тәкъдим ителә.- Казан: РИЦ «Школа», 2001.- 61 б.

36. Юлда йөрсәң, уяу бул: балалар бакчасында эшләүче тәрбиячеләр өчен методик кулланма / Төз.: *Ф.Л.Гыйниятуллина.*- Яр Чаллы, 2008.- 64 б.

37. *Ягъфәров Р.Р.* Ал кирәк, гөл кирәк (уеннар китабы): укытучылар һәм балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен кулланма / Р.Р.Ягъфәров.- Казан: Мәгариф, 1995.- 126 б.

38. *Ягъфәров Р.Р.* Кәҗә-мәкәрҗә: балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен кулланма.- Казан: Мәгариф, 1994.- 110 б.

# Эчтәлек

**Аңлатма язуы.......................................................................3**
**Тәрбиячегә ярдәмлек йөзеннән**
**сөйләм үстерү методикасы...................................................6**
**Комплекслы-тематик план...................................................8**
**Зурлар төркеме........................................................................8**
**Минем бакчам.........................................................................13**
Балалар бакчасы буйлап сәяхәт.................................................13
Рәсем карау һәм хикәя төзү: «Балалар бакчасында».................14
Шигырь ятлау: М.Фәйзуллина. «Өлкән группага күчкәч».......15
**Мин яратам сине, Татарстан...............................................16**
Әңгәмә: «Туган ил кайдан башлана?».......................................16
«Башкалабыз – Казан»...............................................................17
Шигырь уку: Р.Рәкыйпов. «Мин яратам сине, Татарстан».........18
**Яхшы сүз – җан азыгы.........................................................19**
Өстәл театры. «Өч кыз». Татар халык әкияте............................19
Хикәянең эчтәлеген сөйләү: Ә.Бикчәнтәева. «Тәмле сүз».........20
**Абдулла Алиш иҗаты...........................................................21**
«А.Алиш – балалар язучысы».....................................................21
Хикәя уку: А.Алиш. «Каз белән аккош».....................................22
**Хуш киләсең, ямьле көз!......................................................23**
Бакча тирәли сәяхәт. «Җәйләр үтте, көзләр җитте»..................23
Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге табигать»...............................24
Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Көз»..............................................25
**Көз күчтәнәчләре...................................................................26**
Яшелчәләр күргәзмәсенә сәяхәт. «Көзге могҗиза»....................26
Сәхнәләштерү: В.Хәйруллина. «Яшелчәләр бәхәсе»................28
Шигырь ятлау: Х.Гарданов. «Түтәлләрдә үсте яшелчә»............29
**Икмәк – яшәү терәге.............................................................30**
«Игенче хезмәте белән танышу».................................................30
Әңгәмә. «Икмәк – тормышның нигезе».....................................31
Әкият уку: «Икмәк». Төрекмән халык әкияте...........................32
**Минем гаиләм, өем, йорт җиһазлары.................................33**
Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Безнең гаилә»..............33
«Әби-бабайларны хөрмәтлик»...................................................34
Шигырь ятлау: Ә.Бикчәнтәева. «Дәү әнием»............................36

«Һәркемнең үз йорты бар»........................................................37
Әңгәмә. «Йорт җиһазлары»........................................................38
Шигырь уку: Ә.Ерикәй. «Әти йорт төзи»....................................40
**Табын янында........................................................................41**
Савыт-саба кибетенә сәяхәт......................................................41
Чагыштырма хикәя төзү. «Чәйнек белән самавыр»...................42
Әңгәмә. «Мин кунак яратам»......................................................43
Хикәя сөйләү: «Тәлинкәнең төбе нинди?»...................................45
**Киемнәр дә безне бизиләр........................................................46**
Кием-салым кибетенә сәяхәт......................................................46
Әңгәмә. «Милли киемнәр»..........................................................47
**Саулык – зур байлык................................................................49**
«Су, һава һәм кояш – безнең белән гел юлдаш!».........................49
Сәхнәләштерү: А.Алиш. «Куян кызы» әкияте............................50
Шигырь ятлау: Ә.Ерикәй. «Чисталык сөябез»............................51
**Исеменә күрә – җисеме............................................................52**
Әңгәмә. «Исемең матур, кемнәр куйган?»...................................52
«Без дә хокуклы»..........................................................................54
**Салкын кыш. Кышкы уеннар....................................................56**
Әңгәмә. «Без суыктан курыкмыйбыз»..........................................56
Тәҗрибә. «Предметның бер хәлдән икенче хәлгә күчүе"..........57
Рәсем буенча хикәя төзү. «Кышкы уеннар»................................58
Хикәя уку: К.Ушинский. «Кыш әбинең шуклыгы».....................60
**Бездә кышлаучы кошлар..........................................................61**
Балалар бакчасы тирәли экскурсия.
«Җимнәр сибәм кошларга»...........................................................61
Рәсем карау. «Кошлар килгән җимлеккә»....................................63
Шигырь ятлау: Д.Гарифуллин. «Песнәк»....................................64
Шигырь уку: Г.Лотфи. «Балалар ярдәм итә»................................65
**Кыргый хайваннар.....................................................................66**
«Зоопаркка сәяхәт». Төркемдә уен оештыру. ..............................66
Рәсем буенча хикәя төзү. «Куяннар»...........................................67
Әкият уку, сәхнәләштерү.
«Төлке белән бүре». Татар халык әкияте.....................................69
Әкият уку: «Бүре аларны нигә ашаган».
Болгар халык әкияте.....................................................................70

**Йорт хайваннары һәм кошлары........................................71**
Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү. «Ишегалдында»............71
Рәсем карау. «Песи һәм песи балалары»....................................72
Хикәянең эчтәлеген дәвам итеп сөйләү.
Г.Мөхәммәтшин. «Ак песи».........................................................73
**Транспорт.......................................................................................74**
«Җир өсте, һава, су транспорты»................................................74
Чагыштырып тасвирлау хикәясе төзү.
«Йөк машинасы һәм җиңел машина»..........................................76
Хикәя уку: И.Дәүләтшин. «Алпамыш шәһәргә килде».............77
**Юл йөрү кагыйдәләре...................................................................78**
«Машина йөртүче һәм җәяүлене кисәтүче
куркынычсызлык билгеләре»......................................................78
Әңгәмә. «Велосипед – минем дустым»......................................80
Шигырь ятлау: Ш.Галиев. «Светофорның өч күзе»..................81
**Хезмәт төбе – хәзинә.....................................................................82**
Төзелеш булган җиргә сәяхәт яки рәсем карау.
«Хезмәткә хөрмәт»........................................................................82
Әңгәмә. «Кем булырга?»..............................................................83
Хикәя уку: К.Ушинский. «Иртәнге нурлар»...............................84
**Кунак булсаң – тыйнак бул!........................................................85**
Әңгәмә. «Сүз эчендә энҗе бар»...................................................85
Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Табын кагыйдәләре»..................86
**Россия – зур дәүләт.......................................................................88**
«Татарча да яхшы бел, русча да яхшы бел ...»..........................88
Әңгәмә. «Теле барның – иле бар»...............................................89
**Батырлыкта – матурлык...............................................................90**
«Җирне, күкне һәм диңгезне саклаучылар»...............................90
Шигырь уку: Ж.Дәрзаман. «Солдат булдым»............................92
**Заманча әкиятләр...........................................................................92**
«Винни-пух кунакка бара» – минем яраткан мультфильмым»...92
**Кояш гомере телим мин, әнием, сиңа!........................................93**
Әңгәмә. «Әни кирәк»....................................................................93
Шигырь ятлау: Н.Гайсин. «Әни гөлләре»...................................95
**Без язны яратабыз.........................................................................96**
Балалар бакчасы тирәли максатчыл күзәтү...............................96

Рәсем буенча хикәя төзү. «Яз»....................................................97
Татар халык иҗаты аша язны тасвирлау..........................................98
Шигырь ятлау: М.Мазунов. «Яз килә»........................................100
Тәҗрибә үткәрү. «Суган утырту»................................................101
**Безнең канатлы дусларыбыз..................................................102**
Терәк сораулар буенча рәсемгә карап, чагыштырма хикәя төзү.
«Сыерчык белән карга яз килүгә шатлана»...............................102
Уен-викторина. «Кошлар – безнең дусларыбыз!»......................103
Шигырь уку: Г.Тукай. «Карлыгач»............................................105
**Хәрәкәттә – бәрәкәт.................................................................106**
«Минем яраткан спорт төре».......................................................106
Шигырь уку: В.Хәйруллина. «Туплар»......................................107
**Су яшәү чыганагы...................................................................108**
Әңгәмә. «Яңгыркаем, яу, яу!».....................................................108
Тәҗрибә. «Суның үзенчәлекләре»..............................................110
**Уттан саклан!............................................................................111**
Әңгәмә. «Янгын куркынычсызлыгы!»........................................111
Шигырь уку: Г.Гыйльманов. «Ярый әле»...................................112
**Бүлмә гөлләре.............................................................................114**
«Хуш исле нәфис гөлләр».............................................................114
Тәҗрибә. «Кояш, су һәм һаваның
үсемлекләр өчен әһәмияте»..........................................................115
**Галәм киңлекләре.....................................................................117**
Уен. «Планетарийга сәяхәт».........................................................117
**Г.Тукай иҗаты.............................................................................118**
«Г.Тукайның тормышы һәм иҗаты»...........................................118
Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Бала белән күбәләк».........................120
Шигырь ятлау: З.Туфайлова. «Тукай абый»..............................121
**Урман – җиребезнең матурлыгы, байлыгы..........................122**
Урман почмагына экскурсия........................................................122
«Камканы күзәтү»...........................................................................124
«Кызыл китап» нәрсә ул?.............................................................125
Әкият эчтәлеген сөйләү: Ф.Зариф. «Татлы җәй».......................126
**Җиңү алып килде май..............................................................128**
Сугыш ветераннары белән очрашу. «Бөек Җиңү»...................128
Шигырь уку: Э.Шәрифуллина. «Минем бабай»........................128

**Чәчәкләр – тормыш яме ........................................................129**
Уен-викторина. «Чәчәкләр – тормыш яме»...............................129
**Алдакчы, саран булма...........................................................131**
Хикәя уку: Н.Фәттах. «Велосипедлы Мөнир»........................131
**Комплекслы-тематик план..................................................133**
**Мәктәпкә әзерлек төркеме...................................................133**
**Белем бәйрәме........................................................................137**
Мәктәпкә экскурсия. «Исәнме, мәктәп!»...................................137
Әңгәмә. «Белем бәйрәме»...........................................................137
Хикәя уку: М.Хәсәнов. «Сара мәктәпкә бара»..........................149
**Аралашу әдәбе.........................................................................140**
Әңгәмә. «Тәмле сүз – җан азыгы»..............................................140
Хикәя эчтәлеген сөйләү: В.Осеева. «Тылсымлы сүз».............142
**Туган ягым – яшел бишек.....................................................143**
«Минем туган җирем»...............................................................143
Әңгәмә. «Минем гүзәл халкым»................................................144
«Туган ягым язучылары»...........................................................145
«Татарстан буйлап сәяхәт»........................................................146
Әңгәмә. «Чал тарихлы Казаным»..............................................148
Шигырь уку: Ә.Синегулов. «Татарстан җирләре»...................150
**Абдулла Алиш иҗаты............................................................151**
А.Алиш иҗаты белән танышу..................................................151
Әкиятнең эчтәлеген сөйләү. «Сертотмас үрдәк».....................153
**Алтын көз!..............................................................................154**
Урман почмагына экскурсия......................................................154
Рәсем буенча хикәя төзү. «Алтын көз».....................................155
Шигырь ятлау: М.Җәлил. «Көз җитте»....................................156
**Яшелчә, җиләк-җимеш..........................................................158**
«Бакчада көзге эшләр»..............................................................158
Үз тәҗрибәсеннән чыгып хикәя төзү.
«Мин уңыш җыйдым»................................................................159
Шигырь уку: Х.Халиков. «Дәү әнием – бакчачы»...................160
«Көз күчтәнәчләре»....................................................................162
Рәсем буенча хикәя төзү. «Көзге эшләр»..................................163
Шигырь уку: Н.Мадьяров. «Балан».........................................165
**Икмәк – яшәү терәге ..............................................................166**

«Игенченең тырышлыгы кырларыннан күренә»....................166
Картина карау: И.Шишкин. «Арыш басуы»..............................168
Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Ашлар солтаны»..............................169
**Гаилә һәм йорт җиһазлары......................................................171**
«Минем өем, өй җиһазлары»......................................................171
Әңгәмә. «Нәрсә ул электр һәм электр җиһазлары?»...............172
Иҗади хикәя төзү: «Тату гаилә»..............................................174
Шигырь уку: З.Туфайлова. «Минем гаиләм»...........................175
**Ашамлыклар һәм савыт-саба...................................................177**
Ашханәгә экскурсия..................................................................177
Әңгәмә. «Кунак чакырдык»......................................................179
Хикәянең эчтәлеген сөйләү.
С.Сәүбәнова. «Ботка нигә тәмле?».........................................180
**Милли киемнәр...........................................................................182**
Танышу уены. «Әбиемнең серле сандыгы»............................182
Чагыштырып хикәя төзү. «Кием кешене бизи».......................184
Шигырь уку: Р.Вәлиева. «Кәләпүшем, кәләпүш»...................185
**Кыш. Кышкы уеннар.................................................................186**
Паркка экскурсия. «Килеп җитте матур кыш»........................186
Әңгәмә. «Паркта минем күргәннәрем».....................................188
Шигырь ятлау: Г.Латыйп. «Кыш килде»..................................190
«Боз һәм бозлыклар»................................................................191
Иҗади хикәя төзү. «Кышкы уеннар».......................................192
Язма сөйләм. «Кыш бабайга хат»............................................194
**Кыргый хайваннар...................................................................195**
«Кайда, ничек кышлыйлар?»....................................................195
Рәсем буенча хикәя төзү. «Кыш. Тиеннәр»............................197
**Кышлаучы кошлар....................................................................198**
Кошларны күзәтү. «Безнең канатлы дусларыбыз»..................198
«Кошларга ярдәм итик»...........................................................201
Калмык халык әкиятен уку:
«Күңелле чыпчык белән күңелсез карга»...............................202
**Йорт хайваннары һәм кошлары..............................................204**
«Авылда ишегалды»..................................................................204
Картина буенча хикәя төзү.
«Йорт хайваннары. Ат белән колын».......................................205

Әкиятнең эчтәлеген сөйләү. «Үрдәк беренчелекне алган».....206
**Транспорт. Юл йөрү кагыйдәләре........................................208**
«Транспорт төрләре белән танышу»........................................208
Әңгәмә. «Юл йөрү кагыйдәләре кирәк безгә һәркөнне».........210
Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Светофор»..................................211
**Һөнәрләр..........................................................................................213**
Балалар бакчасы буйлап сәяхәт.
«Безне җырларга кем өйрәтә?»..................................................213
Әңгәмә. «Әти-әниләр һөнәре»....................................................215
Шигырь уку: Э.Мөэминова. «Фокусчы».................................216
Укытучы хезмәте белән таныштыру. «Укытучы»...................218
**Мультфильмда кунакта.....................................................................220**
Әкиятне дәвам итеп сөйләү. «Көчтәнәч»тә кунакта».............220
Әңгәмә. «Әкиятләр иленә сәяхәт»............................................221
**Мин дөньяның бер кешесе.................................................................223**
Әңгәмә. «Мин бәхетле – мин хокуклы»....................................223
«Тигез хокук белән яшик бу җирдә».........................................225
**Мин һәм минем сәламәтлегем..........................................................226**
Шифаханәгә (шәфкать туташы бүлмәсенә) экскурсия.
«Шәфкать туташы».....................................................................226
Фикер алышу. «Сәламәтлек – зур байлык».............................228
Хикәянең эчтәлеген сөйләү.
В.Монасыйпов. «Шифалы табиблар»........................................229
**Муса Җәлил. Ил сакчылары.............................................................231**
«Кемнәр алар ил сакчылары?»...................................................231
«Муса Җәлил – бөек шагыйребез»
Сәхнәләштерү: М.Җәлил. «Карак песи».................................232
Шигырь уку: Р.Корбан. «Җәлил турында җыр».....................234
**Халыкара телләр көне.......................................................................235**
Фикер алышу. «Дуслык – бөек көч»..........................................235
Әңгәмә. «Россия – безнең илебез»............................................237
Шигырь ятлау: Х.Халиков. «Сөйләшсәләр безнеңчә...»..........238
**Бүлмә гөлләре....................................................................................240**
Тәҗрибә үткәрү. «Ни өчен орлыкларны,
үсемлекләрне балчыкка утырталар».........................................240
Хикәя төзү. «Кактус белән фикус гөлен чагыштыру»............241

Шигырь уку: Ә.Габиди. «Минем гөлләрем»..........................243
**Ямьле яз.........................................................................244**
Паркка экскурсия. «Туган якка яз килде»...............................244
Эчтәлекле рәсемнәр сериясе буенча хикәя төзү.
«Яз. Сыерчыклар»...................................................................245
Шигырь уку: Н.Мадьяров. «Көләч яз»....................................247
Күзәтү. «Ак болытлар ага зәңгәр күктә»..................................248
**Исәнмесез, кошкайлар!.......................................................250**
«Күчмә кошлар безгә яз алып килде»......................................250
Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Кара».........................................252
**Урман. Кызыл китап...........................................................254**
«Нәрсә ул Кызыл китап?»........................................................254
Әңгәмә. «Урман – безнең байлыгыбыз»..................................256
Хикәянең эчтәлеген сөйләү:
Р.Төхвәтуллин. «Шомырт нигә елый?»....................................257
Хикәянең эчтәлеген сөйләү: М.Пришвин. «Алтын болын»...258
**Китап кайдан килә .............................................................260**
Китапханәгә экскурсия............................................................260
Бирелгән сүзләрдән хикәя төзү. «Китап кибете»....................261
Шигырь уку: Х.Халиков. «Китап докторы»..............................262
**Космос..................................................................................263**
«Нәрсә ул Кояш системасы?»..................................................263
Әңгәмә. «Космонавтика көне»................................................264
Шигырь уку: Йолдыз. «Сәлам, галәм!»...................................266
**Спорт.....................................................................................268**
«Казанда Универсиада».........................................................268
Рәсем буенча хикәя төзү. «Спорт мәйданчыгында»................270
Шигырь ятлау: Г.Юнысова. «Зарядкага бас» ..........................271
**Г.Тукай иҗаты......................................................................272**
Әдәби викторина. «Мультфильмда кунакта»..........................272
Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Кызыклы шәкерт»..........................274
Шигырь уку: Г.Тукай. «Эш беткәч, уйнарга ярый»..................275
«Г.Тукай һәм балалар»...........................................................276
**9 май – Җиңү көне.................................................................277**
Ветераннар белән очрашу. «Алар безгә Җиңү бүләк итте»....277

Хикәянең эчтәлеген сөйләү:
Л.Кассиль. «Күңелләрдә мәңге сакланыр»................................278
**31. Хуш бакчам, исәнме, мәктәп!..........................................280**
«Без барабыз мәктәпкә»..............................................................280
Сәхнәләштерү: Г.Тукай. «Һәркем эштә»...................................281
Шигырь ятлау: Б.Рәхмәт. «Мәктәпкә»......................................282
**Ел ахырында үзләштерелергә**
**тиешле белем һәм күнекмәләр.**
**Зурлар төркеме............................................................................284**
**Мәктәпкә әзерлек төркеме.........................................................288**
**Кулланылган әдәбият..................................................................292**

**Туган телдә сөйләшәбез**

5 – 7 яшьлек балаларны
туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча
методик ярдәмлек

Тышлык рәссамы: В.В.Семенова
Компьютерда биткә салучы: А.С.Рубцов
Корректоры: А.М.Сәгыйтова

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 29.10.2012.
Форматы 60×90 1/16
Шартлы басма табагы 19,0.
Тиражы 6000 д.
Заказ № 23807.

«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды.
420111 Казан, Профсоюз урамы, 17в.
Тел./факс: (843) 292-27-25.